PRESSA.RU

1926–1991 елларда АЗАТ ХАТЫН



2017 СЕНТЯБРЬ № 9

Сөембикә

ISSN 0869-1398

БАЛАЛАР ЮГАЛА
ваемсыз булмыйк

КИЯҮ КЕЛӘТЕ
«ишек бавы – бер алтын»


ЗИНИРА ҺӘМ РИЗАТ РАМАЗАНОВЛАР СЫЙЛЫЙ
бөтнекле бәрән ите

Айназ ШАЙНУРОВА:

«УРТАК ТАБЫНДА БЕЗНЕҢ ӨЛЕШ ТӘ БАР»



PRESSA.RU





2017 ГОД ЭКОЛОГИИ В РОССИИ

И-и ямьле туган ягым!



Эльмира ЗАКИРОВА
Фото: Алмаз ЗАКИРОВ

Әллә кайдагы Түбән очлар аша күпергә чыгып та тормыйбыз, күлмәк итәкләрен тездән югары күтәреп, сай урынны сайлап, Сөнне кичәбез. Башта – комлык, аннан – үги ана яфраклары үскән уйсу җир, бераз арырак – торналар төшә торган камышлы, төнбоеклы күлләр, иген басулары, уңда – Байсардан Чиялеккә, сулда – Чишмәбашка алып менә торган юллар... Ә без туп-туры Алкаби тавына таба юл алабыз. Сөн акчарлагы Тимер Тырнак әрәмәләренә кадәр озата бара... Югарыдан, Алкаби тавыннан гаҗәеп манзара ачыла. Түбәндә бормаланып Сөн ага, Актаныш районының Чуракай, Җылан, Яңа Байсарлары уч төбендәгедәй күренә; кул сузымында гына – Башкортстан, Илешнең Төкәй авылы. Алкаби тавы турында бездә әллә никадәр риваятьләр сөйлиләр. 1380 елларда монда арбалы атлар белән керерлек зур тау куышы булган, диләр. Әби патша шунда яшәгән, аның зур алтын алкалары булган. Имеш, ул алкалар шул мәгарә эчендә калган... Икенче риваять буенча, бу җирләр Алка бинеке булган. Борынгы заманнарда бай кешене дә, гаскәр башлыгын да би дип йөрткәннәр...

Роберт МИҢНУЛЛИН

Сөн буена чакыру

*Әйдә безгә – Сөн буена
Кунакка барасыңмы?
Ак чәчәкләр өзеп бирсәм,
Түшеңә кадарсыңмы?*

*Сөн буеның бөрлегәнен
Авыз итеп карарсың.
Су кергәндә, Сөнгә карап,
Чәчләреңне тарарсың.*

*Кичләрен Сөнгә җыелган
Йолдызларны күрерсең.
Аланнардан чәчәк җыеп,
Такыялар үрерсең.*

*Әйдә безгә – Сөн буена
Кунакка барасыңмы?
Тик онытма Сөн буенда
Гомергә каласыңны!*

Сөй гомерне, сөй халыкны, сөй халыкның дөньясын!



© «Сөембикә» 2017

1926 елдан башлап «Азат хатын» исеме белән чыкты. 1991 елда «Сөембикә» итеп үзгәртелде. Хатын-кызларның бөтентатар айлык әдәби-нәфис журналы 1913–1918 елларда чыккан «Сөембикә» журналының дәвамчысы.

Ежемесячное литературно-художественное и культурно-просветительское электроннное периодическое издание на татарском, русском языках для женщин и семьи.

Территория распространения: Российская Федерация, зарубежные страны

Элемтә, мәгълүмати технологияләр һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендәге күзәтчелек буенча Федераль хезмәтендә (Роскомнадзор) 2015 елның 18 маенда «Сююмбике» дип теркәлгән. Теркәү таныклыгы Эл № ФС 77-61814

Язмалар авторның тулы адресы күрсәтелеп, паспорт мәгълүматлары, пенсия иминияте таныклыгы, ИНН таныклыгының ксерокс күчермәләре белән бергә җибәрелгәндә генә кабул ителә.

Кульязмаларга бәя бирелми, алар кире кайтарылмый.



Җитәкче-баш мөхәррир
Ләйсән Рәфикъ кызы ЮНЫСОВА

Редколлегия:
Зилә Вәлиева, Нәбирә Гыйматдинова, Эльмира Зарипова, Кадрия Идрисова, Сәрия Сабурская, Айрат Сибагатуллин, Иркия Төхвәтуллина, Нурия Һашимова, Гөлназ Шәйхи, Эльвира Әхмәтова.

Редакциянең гомуми телефоны 222-09-77
Җитәкче урынбасары
Рәмзия Кашапова 222-09-78
Баш мөхәррир урынбасары
Гөлнур Хәсәншина 222-09-78
Җаваплы сәркатип
Лариса Маликова

Сайт мөхәррирләре:
Сөмбел Гаффарова
Камилә Димөхәммәтова

Автор фикере редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин.

Реклама текстлары аны бирүчеләр җаваплылыгында.

Редакциянең язмача рөхсәтеннән башка материалларны «Сөембикә»дән күчереп басу тыела.

Дизайн-макет:
«ASAFIN GROUP»
Верстка:
Лариса Маликова

Тышлыкта:
Айназ Шайнурова
Фото: Ксения Богданова

Бүлек мөхәррирләре:
Мәдинә Авзалова
Лилия Гәрәева
Эльмира Закирова
Асия Юнысова
Фәнзилә Мостафина
Фотокорреспондент
Ксения Богданова
Корректор
Фирдәвес Исмәгыйлева
Гамәли хезмәткәрләр:
Нәфисә Әскәрова
Ленар Хәкимов

Формат: 225x290 мм.
Күләме 64 бит.

Басарга кул куелды: 8.09.2017 ел.
Заказ А-2178.
Тираж 5163.

Учредитель: Акционерное общество «Татмедиа»



ТР «Татмедиа» Матбугат һәм массакүләм коммуникацияләр республика агентлыгы ярдәме белән чыгарыла.

Редакция адресы: 420066, Казан, Декабристлар урамы, 2 нче йорт.
www.syuyumbike.ru
E-mail: suumbike@tatmedia.com
ssuum@yandex.ru
тел./факс: (843) 222-09-77
Язылу индексы:
П2204 (ПАП рәсми каталогы буенча)
73002 («Роспечать» каталогы буенча)

Банк реквизитлары:
Филиал АО «ТАТМЕДИА»
«Редакция журнала «Сююмбикэ»
Расч/счет 40702810600020010309
кор/сч 30101810000000000805
в ПАО «АК БАРС» БАНК г. Казань
ИНН 1655144950
БИК 049205805
КПП 165802002



PRESSA.RU

Салисә ГӘРӘЕВА


Өр-яңа көз

Өр-яңа көз текә тауга менеп бара,
Май йомгагы – ягымлы җәй сүнеп бара...
Тау битендә ят учаклар яна балкып.
Каеннарны чорнап алган сары ялкын!

Торналарга карадым да болгадым кул:
– Китәсез дәмени инде? Хәерле юл!
Килер язга кире кайтсын барчагыз да!
Сандугачлар кайтарыгыз бакчабызга!

Оча яфрак җил иркендә талгын гына,
Сулып барган үләннәргә яулык булып.
Алда – кышлар. Без көтәбез яңа язны –
Күрешергә насыйп итсен саулык булып!

Өр-яңа көз тәрәзәмә яфрак сона.
Сары яфрак – тере ялкын төсендә ул!
Имин булсын дөнья!
Тормыш гөрләп торсын:
Җирсеп яшәр, янып язар өчен дә ул!






Фото: Көз җилләре. Рабис Сәлахов эше.

Ленар ШӘЕХ

Сентябрь иртәләре

*Җәйдән искән җылы җилкәй
Битемне иркәләде.
Урамнарда әле һаман
Сентябрь иртәләре.*

*Яфраклар да һаман шул ук,
Шул ук ис һәм яшеллек.
Якты кояшка бер багып:
«Җәем!» – диеп дәшәрлек.*

*Соңгы җырлар җырланмаган,
Соңгы көй уйналмаган.
Көзгә керү баштан чыккан,
Әлегә уйланмаган.*

*Кошлар һаман сайрап йөри
Җәйнең матур моңнарын.
Мин тоям һәрбер үләндә,
Һәр яфракта моң барын.*

*Шундый рәхәт, шундый җылы
Сентябрь иртәләре...
Кояшлы яңгыр сибәли –
Көзләргә иртә әле!..*

PRESSA.RU



БЕЗНЕҢ ТЫШЛЫКТА



16 САБА ЮЛЫ КИЛӘЧӘККӘ ИЛТӘ
М. Авзалова

ЗАМАН ҺӘМ БЕЗ



8 БАЛАЛАР ЮГАЛА
М. Авзалова

ТАТАР ДӨНЬЯСЫ



24 «ҮЗ ҖИРЕМӘ ДИП КИЛДЕМ...»
Г. Сафиуллина



12 «КИНОГА ТӨШҮ – ХЫЯЛЫМ ИДЕ»
Э. Закирова



28 КАЮМ БАБАЙ «МӘГАРӘСЕ»
Л. Гәрәева

ЭЧТӘЛЕК

МӘДӘНИ ТОРМЫШ 



34 **КҮЗЛӘРЕ СОП-СОРЫ...**
Р. Рахман

ЯШӘЕШ 



46 **МИЛӘҮШӘНЕКЕЛӘР**
Г. Сафиуллина



50 **ОЛА, ИСПАНИЯ!**
А. Әхмәтгалиева

ШУЛАЙ УК: 

40 **«КЫЗ» ЙОЛДЫЗЫ – МИНЕМ ЙОЛДЫЗ**
Э. Закирова

44 **САГЫНДЫРЫР ТАНЫШ ЧЫҢЛАВЫ**
Л. Сабирова-Гыймадиева

ХАТЫН-КЫЗ ГАЛӘМЕ 



60 **ЮРГАНЫМ – БОМБОН**

КИЛӘСЕ САННАРЫБЫЗДА: 

ТӘРБИЯГӘ... ӘБИ АЛАМ.
МӘРХӘМӘТКӘ – МӘРХӘБӘ.

ЫРЫМНАРГА ЫШАНЫРГАМЫ, ЮКМЫ.
ӘНИ БУЛУ ҖИҢЕЛМЕ.

«СИН КЕМ КЫЗЫ?»
ЛЮЦИЯ ӘБЛИЕВА. ХИКӘЯ.

УЕНЧЫГЫМНЫ СӘЯХӘТКӘ ОЗАТТЫМ.
ХОББИ ТАРИХЫ.



PRESSA.RU

Кадерле «Сөембикә» редакциясе!



Мин үзем Саба районы Югары Утар авылында туганмын. Гаиләдә беренче бала идем.

Балачагым, үсмер елларым матур табигатьле авылымның болыннарында җиләк җыеп, инешендә су коенып үтте. Әтием колхозда тракторчы булды, әнием гомере буе балалар йортында эшләде. Без күбрәк әби белән булдык. Аның алтын киңәшләрен хәзер дә кулланам. «Кызым, – ди иде ул, – токмачка дигән камырны 90 тапкыр басарга кирәк, шулай итсәң, шулпада изелми торган була». Җиденче сыйныфны тәмамлагач, мин дә Югары Утар балалар йортына кер юучы булып урнаштым. Ул вакытта хәзерге уңайлыклар юк иде әле. Язмыш кыерсыткан шул балаларны кызганып, үзгәем өзгәләнә иде. Балачагымнан ук сәламәтлекнең нинди зур байлык булуын аңладым.

Кечкенәдән тегүче буласым, матур-матур күлмәкләр тегәсем килә иде, мәктәпне тәмамлагач, Казанга тегүчелеккә укырга керергә дип киттем. Ләкин анда группалар тупланып беткән булып чыкты. Авылга кире борылып кайтып булмый, дип, пальто тегү цехына урнаштым. Бу вакытта Эзмә авылы егете белән дуслашып йөри идек. Тагын бер ел очрашып йөргәннән соң, Эдуард мине урлап алып кайтып китте. Ул чорларда кыз урлау гадәте бар иде шул. Туйлар үткәреп, матур гына яшәп киттек. Инде балаларыбыз зурлар. Кызыбыз Миләүшә Казанда эшли, улыбыз Айзат – икенче курс студенты.

Тормышка чыккач, мин Югары Утар балалар йортында санитарка булып эшли башладым. Төрлесен күрдек, авыру балаларны карау җиңел эш түгел. Сабырлыгымны җыеп, күңел җылымны биреп эшлим. Хезмәтемнең нәтиҗәсе итеп, быелның гыйнвар аенда «Татарстанның атказанган халыкны социаль яклау хезмәткәре» дигән исем бирделәр.

Гөлүсә НӘБИУЛЛИНА.
Саба районы, Югары Утар авылы.

Шушы матурлыкны үзебезнең хатын-кызлар тудырган бит дигән уем, мине «Сөембикә» редакциясенә алып килде. Аларның тырышлыкларын бар дөньяга танытасым, шушылай итеп тә эшләп булганын башкаларга да җиткерәсем килде.

Бу оешма турында беренче тапкыр Казанда хастаханәдә ятканда ишеттем мин. Юк, алай дип әйтү дә дөрес үк булмас. Башта мин аларның бик матур стена календарьларын күрдем әле. Казанда күп катлы йортлар белән идарә итүче «Уютный дом» компаниясе белән танышлыгым әнә шулай башланды. Хастаханәнең тирә-юнендәге матурлыкка аңынчы да игътибар иткән идем, баксаң, бу матурлыкны да шушы компаниядә эшләүчеләр тудырган булып чыкты. Хастаханәдән чыккач, алар идарә иткән йортларның ишегалларын махсус барып карадым. Белмим, анда кемнәр эшлидер, ничек эшлидер, әмма һәр ишегалындагы чәчәк түтәлләре, агачтан ясалган матур-матур сыннар, балаларга атынгычлар, олыларга утырыр өчен эскәмияләр мине хәйран итте. Юри санап чыктым: 158 ишегалдын матурлаганнар. Казанның мин яшәгән районында мондый матур, нур бөркеп торган ишегаллары юк.

Кызыксынуым шулкадәр көчле иде, беркөнне, җыенып, компаниядә эшләүчеләр белән танышырга киттем. Монда фантазиягә бай, алтын куллы кешеләр эшләгәне ишек төбеннән үк абайлана. Мин барган көн гашыйклар көне иде. Шул уңайдан стенага бик матур композиция ясап элгәннәр. Ишек төбендә телеграммалар тартмасы тора. Компания карамагындагы йортларда яшәүчеләр бер-берләрен котлап, шул тартмага телеграммалар салып калдыралар да, оешманың хезмәткәрләре аны тәгаенләнгән ияләренә таратып та чыга икән. Бездә халык өчен берәр нәрсә эшлисе булса, акча юклыкка килеп төртелә. Ишегалдын рәткә китерер өчен акча юк, балаларга яңа таганнар элер өчен акча юк, эскәмияләрне рәтләргә тагын шул акча юк. Башкаларда юк та, бер сездә генә ничек бар икән соң ул дип сорадым компаниянең генераль директоры, Россиянең һәм Татарстанның атказанган торак-коммуналь хуҗалыгы хезмәткәре Марат Нуриевтан. «Төрле грантлар отабыз», – дип җавап бирде ул. Ә бит аларның карамагындагы йортлар саны гына да 552 гә җитә икән. Һәр иртәдә йөзләгән хезмәткәр Яңа Савин районы ишегалларын тәртипкә китерергә дип, эшкә чыга. Себерке белән ике сә-

гатьтә чаж-чож китереп, ишегалды себереп кайту гына түгел аларның эшләре. Һәркайсы үз территориясен тагын да матурларга, бизәргә омтыла. Ул матурлыкны алар үз куллары белән тудыра бит, мине әнә шунысы сокландырды. Кул астындагы агач, калай кисәкләреннән матур-матур клумбалар, сыннар, эскәмияләр, балалар мәйданчыгын бизәү өчен кечкенә генә коелар, машиналар, поезд вагоннары... ниләр генә уйлап чыгармыйлар. Аларны эшли торган остаханәләренә кадәр кереп карадым.

Тагын бер мөһим әйбер: алар бу тырышлыклары белән тирә-юньне генә матурлап калмый, халыкны да тәрбияли. Ялт итеп торган ишегалдына беркемнең дә чүп капчыгын ыргытып калдырасы килми шул. Алай гына да түгел, шушы йортларда яшәүчеләр үзләре үк ишегалларының күршедәге йортныкыннан матуррак, күркәмрәк булуын тели, шуңа үзеннән өлеш тә кертергә омтыла башлаган. Киләчәктә шәһәребездәге мәдәни һәм социаль климатның нинди булачагы балаларыбызның бүген нинди ишегалдында үсүенә дә бәйле. «Уютный дом»да эшләүчеләрнең моны аңлап эш итүләре бик куанычлы. Казанның Яңа Савин районында гына түгел, башка районнарында да ишегаллары шушындый булса икән.

Җәмбилә АХМЕДОВА.
Казан.



Ул еллардан соң күпме вакыт узса да, әниемнең чөгендер сабагы, кычыткан кушып пешергән ашының, өшегән бәрәңгедән әзерләгән кәлҗемәнең тәме әле дә авызымда торган сыман.

Ул вакытта без моннан да тәмле ризык юктыр дип уйлый идек. Әтиебез сугышка киткәч, бер әнкәй җилкәсендә калган дүрт балага ул каян тапсын инде тәм-том? Болай да ачлыктан саклап калган инде безне әнкәй.

Әткәй сугышка киткәндә миңа әле 3 кенә яшь була. Туган йортыбыз ул чакта элекке «Авангард» кинотеатры янында иде. Ул йорт әле дә исән, аның яныннан узганда мин хәзер дә дулкынланам, тамакка төер тыгыла. Әлеге йортта яшәгәндә кечкенә булсам да, тәрәзә каршыннан яшүсмерләрнең рәт-рәт тезелеп, «Вставай, страна огромная!» дип җырлап узулары – бүген дә исемдә. Ул чакта мин бу җырның мәгънәсен аңламаганмын, әлбәттә.

Беренче сыйныфка мин, сугыш тәмамлангач, 1946 елда кердем. Мәктәптә кышын котып суыклары иде. Язу карасы ката. Дәфтәр юк, гәзитне дәфтәр итеп тегеп, юл араларына язабыз. Өченче сыйныфта ике ел укыдым. Юк, укуым яхшы иде, ләкин өстемә кияргә булмагач, кышын мәктәпкә йөри алмадым. Әле ярый күршебез – бик тә мәрхәмәтле Сабирҗан абый Мөстәхимов бар иде. Ул безне мунчага чакыра, кулыннан килгәнчә булыша иде.

Әти сугыштан кайтканда тормышыбыз бик ярлы, авыр булгандыр инде. Ул безне ачлыктан саклап калу өчен, йортыбызны мунчага охшаганрак бер йортка һәм берничә капчык онга алыштырды. Ул йорт сазлыкта иде, җәен идән астында бакалар сайрый. Әти дә кайткач, сыерыбыз да булгач, тормышлар бераз рәтләнгән кебек булды. Ләкин өскә-башка кияргә юк иде. Кышын мәктәпкә аягымны чолгауга урап, резин итек белән йөрдем. Мәктәптә аяк тирли, салкынга чыккач ката. Аяк бармакларымны өшеткән чаклар да булды. Кайбер укытучылар, кызганып, киез итекләрен киеп торырга бирәләр иде. Өстә сырма, башта әни катлап бәйләткән чүпрәк. Бияләйнең нәрсә икәнен соңрак кына белдем. Салкында кызарган кулларымны күреп, нигә кулыңа кимисең, дисәләр, «туңмый» ди торган идем.

Әти кайткач, гаиләбез ишәйде. Без сигез бала үстек. Гаиләгә бераз ярдәмем тисен, дип, 13 яшемнән җәен тимер юл ОРСы филиалына эшкә урнаштым. Ә аннан безне Тирсәгә көлтә бәйләргә җибәрделәр. 1 сентябрьдә мәктәпкә барырга кирәк, колхоз рәисе Миңнемулла абый Йосыпов җибәрми. «Мин укудан тагын калам инде», – дип елый башлагач кына Әгерҗегә кайтарып җибәрде. Унынчыны тәмамлагач, Әгерҗедәге «Интернационал» колхозына үзем эш сорап бардым. Әти — сугыш инвалиды, әни өйдәгесен карый, эне-сеңелләрне аякка бастырырга булышмый булмый бит. Шулай итеп, колхоз басуында эшли башладым. Менә бу фото да шул вакытта басуда эшләгәндә төшкән фото. Аякта әтинең 41 нче үлчәмле кирза итеге. Фотога төшкәндә мин аны итәгем белән каплаганмын.

Басуда эшләр тәмамлангач, ат арбасына төяп, безгә бәрәңге һәм яшелчә бирделәр. Аларны өйгә алып кайтканда ничек шатланганымны белсәгез... Кыр эшләреннән соң, Дәүләт банкына өйрәнчек булып эшкә урнаштым. Читтән торып Казан хисап-кредит техникумын тәмамладым. 41 ел буе, эшемне яратып, шушы банкта алтмы шым тулганчы эшләдем. Ирем Рафаэль (урыны оҗмахта булсын) белән тату гомер итеп, өч кыз, җиде онык үстердек.

Без күргән авырлыкларны сөйләгәндә алар тын да алмый тыңлыйлар. Теләгем бер генә: без кичергәннәрне, ачлыкны аларга күрергә язмасын Бүген, ялкау булмасаң, башыңны эшләтсәң, менә дигән итеп яшәргә була.

Римма ЯППАРОВА.
Әгерҗе шәһәре.

Хөрмәтле укучыларыбыз! Сездән хатлар көтеп калабыз. Безнең адрес: Казан, Декабристлар урамы, 2. e-mail: ssuum@yandex.ru

PRESSA.RU



ЮГАЛГАН БАЛАНЫҢ ГОМЕРЕ САНАУЛЫ МИНУТЛАР БЕЛӘН ИСӘПЛӘНӘ.

БАЛАЛАР ЮГАЛА



Мәдинә
АВЗАЛОВА

Бала югалганнан соңгы беренче өч сәгать... Татарстан Республикасы буенча Эчке эшләр министрлыгының Җинаятьләрне ачу идарәсе бүлек җитәкчесе урынбасары Альберт ЮСУПОВ әйткәнчә, качкыннарның күбесен санаулы сәгатьләр эчендә, кайнар эздән табып алалар. Бу бик мөһим. Чөнки мондый бәла-казага юлыкканда, баланың кая китүен берәү дә әйтә алмый. Бәлкем, ул үзе өйдән чыгып киткәндер, бәлкем ул, Аллам сакласын, маньяк кулына эләккәндер... Болай дигәндә, моннан өч ел элек Чаллы шәһәрендә булган фаҗига искә төшеп куя: 10 яшьлек Василиса мәктәптән кайтканда юкка чыга. Кызны бөтен мир белән эзлиләр, аны эзләүгә күтәрелмәгән оешма калмый. Хокук саклау органнары, МЧС хезмәткәрләре, волонтерлар эшкә алына. Табалар, әмма инде соң була. Адәм актыгына үлем җәзасы сораган әти-әнинең хәлен бик аңлыйм. Баланы югалтудан да ачы хәсрәт юк бит ул дөньяда.

Кая китәләр? Нигә югалалар?

Саннарга караганда, хәлләребез бер дә әйбәт түгел. Уйлап кына карагыз: ел саен 40 мең бала югалсын инде. Дөрес, аларның 80 проценты исән килешме, үлгән килешме табыла табылуын. Һич уйламаганда, һич көтмәгәндә, балалар мәйданчыкларыннан, бакчалардан, мәктәптән кайтышлый юкка чыккан кыз һәм малайлар турында бары бер генә нәрсә уйлыйсың: алып киткәннәр, урлаганнар... Берәүгә дә сер түгел: бүген бөтен дөнья күләмендә бала сату белән шөгыльләнүче меңләгән оешма бар. Балаларны кешелексез ритуал-ырымнарда файдаланучы секталар да урлый. Җинаятьчеләр яше, төс-кыяфәте белән туры килгән балаларны бик тиз эзләп табалар. Аларны интернетка әти-әниләре үзләре куя. Шөкер, бу афәт безгә кагылмый. Әлегә кагылмый. Югалганнарны эзләүдә сират күпере кичкән оста белгечебез Альберт Әкрәм улы Юсупов, елына югалучыларга кагылышлы 4 мең гариза алынуы, шуның 210 сы балалар булуы хакында сөйли. «Югалган балаларның 90 проценты табыла», – ди ул. Ә калган 10 проценты? Алары ничек? Аларын үлгән килеш йә судан табып алалар, йә урманда адашып үлә, бик сирәк очракта маньяк кулына эләгә. Югалган 11 бала буенча җинаять эше кузгатылган да инде. Бу исә 11 баланың үзен дә, гәүдәсен дә тапмаганнар, дигән сүз.

Көн саен җинаятьләр эзләү бүлегенә югалган кешеләр хакында белешмә кереп тора. Хәбәр минуты-сәгате белән интернет, ватсап аша районнарның әлеге эш белән шөгыльләнүче бүлекчәләренә, Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы хезмәткәрләренә, волонтерларга барып җитә. Әнә ул: «Игътибар! Яшел Үзәннән Бажитов фамилияле яшүсмер югалды!» дип, телефонынннан чаң суга. Әйтүенә караганда, качкыннарның күбесе интернатларда, балалар йортларында тәрбияләнүче кыз һәм малайлар икән. Белгеч, шул арада урманга кереп, үз-үзенә кул салган 17 яшьлек яшүсмер турында да сөйләп ала. Сәбәбе – яраткан кызы ташлаган.

Ничек якларга? Ничек сакларга?

Һәркемне җитди уйланырга мәҗбүр итәрдәй сорауларга җавапны «Лиза Алерт» исемендәге коткару отрядының региональ оешмасы кураторы Айгүзәл Рөстәм кызы Хәйриева белән бергәләшеп эзлибез. Бу отрядның оешуына тиздән җиде ел тула. 2010 елның сентябрендә әбисе белән урманга гөмбә җыярга чыгып киткән 5 яшьлек Лиза Фомина югала. Шәһәр көне белән артык мавыгып киткән милиция, ул чагында «үтергәннәрдер» дип, беркемгә дә урманга керергә рөхсәт итми. «Шул чагында эзләгән булсалар, баланы коткарып калырга да мөмкин булыр иде», – ди Айгүзәл, ачынып. Бу вакыйгадан соң, югалганнарны үзләре теләп эзләүгә алынган отряд барлыкка килә. Лиза – югалган кыз исеме, Алерт – хәвеф дигәнне аңлата.

– Күбесе безнең оешма турында белмиләр дә, – ди Айгүзәл. – Башларына төшкәч, соң була. Без – бер арттырусыз әйтәм – профессиональ эзләүчеләр. Нидән башларга, ничек эзләргә икәнен ишетеп кенә белмибез. Эшләү дәверендә бик күпне күрергә туры килде. Элек бит полиция, кеше югалуга өч тәүлек узмыйча, якыннарыннан гариза да кабул итми торган иде. Хәзер башкача. Без гел әйтә, кисәтә киләбез: кеше югалганнан соңгы беренче өч сәгать бөтенесен хәл итәргә мөмкин. Шуңа күрә баласы югалуга ук ата-ана, монда гына йөридер, кайтыр әле, дип тормаска, кичекмәстән, полициягә, безгә хәбәр итәргә тиеш. Бары шул чагында гына уңышка өметләнергә була. Кайчак балалар үзләрен тапмауны тели. Аларның яшеренеп ята торган урыннары була. Алар шунда төн куна, яши, ашарга таба. Мондый очракта, әгәр дә аларның фоторәсемнәрен игълан такталарына элеп куябыз икән, бала тагын да ныграк яшеренергә, «төпкә» китәргә, нәтиҗәдә, үзе белмәгән мохиткә килеп эләгергә мөмкин. Кайтаргысыз, куркыныч хәлләр килеп чыкмасын өчен, безгә мөрәҗәгать итсеннәр, безнең белән киңәшләшсеннәр иде. Һәр очракның – үз эзләү методикасы, дип әйтәсе килә. Купшы сүзләр генә түгел бу. Моңа җитди карарга кирәк.

> *Ел саен бер безнең илдә генә дә 40 меңләп бала югала. Шуларның 10 проценты табылмый.*

Белгечнең әйтүенчә, әти-әни, баласын югалтуга ук, күршеләрен, танышларын ярдәмгә чакырырга, иң элек сулыклар тирәсен йөреп чыгарга тиеш. Чөнки югалган ун баланың тугызы батып үлүчеләр исәбендә. Бала-чаганың бер ялгызын күлләр, елгалар, буалар янына якын да җибәрмәскә кирәклеге турында күпме генә әйтмә, күлгә чумуның ахыры ни белән бетәсен балалар күз алдына да китермиләр. Психологларның әйтүенә караганда, 7-10 яшьлек балада курку хисе дә шуның кадәрле генә.

Әти-әнисенә үпкәләп, өйдән чыгып китү очракларына караганда, бәхетсезлеккә юлыгып югалучылар саны күбрәк. Алар урманда, паркта, метрода – әнисе белән кулга-кул тотынышып барган җирдән югала. Айгүзәл сөйләгәнчә, хәтта эскәмиядә утырган җирдән...

– Әбисе бәләкәй оныгын эскәмиядә утыртып калдырып, азга гына фатирына – күзлеген алырга кереп китә, – дип сөйли ул. – Шул вакыт күршесе чыга, баланың ялгыз булуын күрә һәм өенә чакыра. Балага чәй эчерткән арада, урамда ыгы-зыгы башлана. Күрше-күлән, анда чабышып, монда чабышып, бәләкәчне эзли. Шулай да була.

Ул чагында мин Чаллыга – сыйныфташларым белән очрашуга кайткан идем, – ди Айгүзәл,

Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU

Василиса белән булган хәлне исенә төшереп. Бала шушы коточкыч хәлгә очрап, соңгы сулышын алган чагында без гөрләп бәйрәм ясап ятканбыз икән, дидем. Шулкадәр йөрәк әрнеде. Шуннан бирле бер генә минутка да тынгылык күргәнебез юк. Безнең эзләү масштабы бик киң, үзебездә генә түгел, башка регионнарга да чыгабыз. Йөрергә машина гына булсын. Бик кирәк булганда, самолет белән дә очабыз. Әле күптән түгел генә Белорецкида булып кайттык. Казан белән Туймазыдан өчәр кеше, Мәскәүдән биш кеше барды. 9 яшьлек кыз бала мәктәптән кайтканда юкка чыга. Сәгате-минуты белән эзләүгә керешүебез, зур активлык күрсәтүебез тикмәгә булмады. Җинаятьче, тотышы белән, үзен сиздерергә мәҗбүр булды. Агуланырга, биек катлы йорт тәрәзәсеннән сикерергә азапланды. Шундый хәлгә без аны активлыгыбыз, аның артыннан эзгә-эз баруыбыз белән китереп җиткердек. Ул җәзасын алды алуын, бала гына юк. Бала гомерен бернинди җәза белән дә бәяләп булмый.

Айгүзәлнең киләчәккә планнары зурдан. Укулар башлангач, волонтерларның мәктәпләргә йөрисе, бала-чага белән кисәтү эшләре, әңгәмәләр үткәрәсе бар әле. «Игелекле эшләр кыласы килгән кешеләр, рәхим итеп, безгә мөрәҗәгать итсеннәр», – дип тә куя ул. Чөнки төп эшеннән соң гомерен гаять четерекле булган тагын бер эшкә багышлаучы кешеләр күп түгел. «Арабызда кайчак хәтта йөкле хатыннар, инвалидлар да булгалый», – ди ул горурланып. Ул үзе дә бик җаваплы эштә. «Лиза Алерт» отряды кураторы белгечлеге буенча архитектор-дизайнер икән.

Качкыннарны эзләүче волонтерлар төркеме «Лиза Алерт»ның эшләре турында бүген бөтен ил белә.

Тапканчы эзлиләр

Татарстанның Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы матбугат җитәкчесе Андрей Родыгин: «Эзләү чаралары районнардагы Башкарма комитет һәм полиция хезмәткәрләреннән башлана, – дип аңлата. – Аннары гына, кирәк дип табылган очракта, безнең хезмәткәрләр, волонтерлар кушыла. Полициянең кинология хезмәте – махсус өйрәтелгән этләре бар. Алар да эшкә җигелә. Мондый вакытта бер генә мөмкинлекне дә кулдан ычкындырырга ярамый». Әле күптән түгел Зәй сусаклагычында булган фаҗигале вакыйгадан гыйбрәт алсак икән. 8 яшьлек малайның суга батып үлүе очраклы түгел. Ике метрлы киртә аша сикергәндә, өлкәннәр кайда булган? Үтеп баручы бер ир кеше күргән күрүен. Тик малай инде ул чагында су төбенә киткән була. Түбән Кама районында, егете белән сүзгә килеп, күпердән елгага сикергән 17 яшьлек кызны да водолазлар ике сәгатьтән соң гына табып алалар. Бала ул беркайчан да кая барасын әйтеп йөрми. Чыгып китә дә югала. Бәлкем, ул дус малае янындадыр, бәлкем, күрше урамда гынадыр, ә бәлкем, шул минутта ул инде су төбендәдер.

Шундый хәлләр булмасын өчен, Татарстанда бала хокукларын яклау буенча вәкаләтле вәкил Гүзәл Удачина әйткәнчә, ата-ана баласы белән кул сузымында булырга тиеш! Ул аның нинди уйлар белән яшәвен белергә, нәрсә теләгәнен аңларга, аңларга һәм һәрвакыт якларга, хупларга тиеш. Ә иң мөһиме: бала таныш булмаган кешеләргә якын килмәсен. Чөнки ул әле хакыйкатьне ялганнан аера алмый. Олы кеше сүзенә ышана. Күп вакыт аларның чит кеше машинасына утырып китүләре дә шуның белән аңлатыла. Ничек инде абый кеше аны алдасын?! Ничек инде ул шул бәләкәй кызга, йә булмаса, малайга начарлык кыла алсын?! Шул чагында каты итеп кычкырып, тирә-юньдәгеләрне үзенә каратса... Сабыйларыгызга дөньяда яхшы кешеләр генә түгел, начар кешеләр дә барлыгын аңлатыгыз. Эш узгач: «Нинди аңгыра бу балалар? Полиция кая караган?» – дип йөрүдән мәгънә юк.

Инде кат-кат әйтелгән гади бер хакыйкатьне онытмыйк: бала еш кына әти белән әнисе арасындагы бетмәс-төкәнмәс ызгыш-талашларны ишетмәс, күрмәс өчен чыгып китә, бу хәлләрнең шаһиты буласы килми. Ир белән хатын аерылышкан вакытта таякның иң авыр башы янә балага төшә. Мондый очракта бала, өйдән чыгып китеп, игътибарны үзенә юнәлтмәкче, шул рәвешле, әти-әнисен килештермәкче була. Еш кына баланың игелекле теләге зур бәлаләр белән тәмамлана.

Шулай итеп, психологлар бала югалуның төп сәбәпләре дип, түбәндәгеләрне атыйлар:

- гаиләдә килеп чыккан низаг;
- ата-ананың баласы проблемаларын күрәсе-ишетәсе килмәве;
- тәрбия җитмәү;
- вакытында психологик ярдәм күрсәтмәү;
- сукбайлыкка хирыслык.

Ә инде балагыз югала икән, кичекмәстән, 112 яисә 88007005452 телефоны буенча шалтырата аласыз. Югалган баланың гомере – сезнең һәм безнең кулларда булуын исегездән чыгармагыз!

«Түбән Камага барырга җыенып беткән идек инде, – ди елмаеп Айгүзәл Хәйриева. – 7 яшьлек малай югалды, дип хәбәр иттеләр. Без аяк киемнәрен кигәнче, табылган». Гел шулай булсачы...

Үземнең дә урамда йөргәндә күзем иң беренче булып бала-чагага төшә. Хәзер мин аларга башкачарак – Айгүзәл сыман карыйм: адашмаганнармы, югалмаганнармы?! Безнең балалар, чит илләрдәге шикелле, җиргә утырып, игътибарны үзләренә юнәлттерә белмиләр бит алар.

КҮЗ УҢЫНДА ТОТАБЫЗ

Киңәшләребезне гап-гади нәрсәдән башлыйбыз: бала куркынычсызлыгы өчен һәм югалганда аны тиз табып алу өчен киеменең эчке ягына исемен, фамилиясен күрсәтеп, билге тегеп куярга кирәк. Кибетләрдә махсус беләзекләр дә сатыла.

GPS-ТРЕКЕРЛАР (GPS-БЕЛӘЗЕКЛӘР, GPS-СӘГАТЬЛӘР)

Беләзекләргә һәм брошкаларга урнаштырылган андый җайланмалар мобиль кушымталар белән бәйле. Бала ул беләзекне тагып йөрткәндә, аның кайдалыгы сезнең смартфоныгыз картасында чагылачак. Моннан тыш, «опекуннар» системасына туганнарыгызның, дусларыгызның телефонын да өсти аласыз. Бәлкем, бала бәлагә тарыганда, алар якында гына йөридер. Алар телефонына да афәт сигналы киләчәк.

Трекер – ул билгеләмәсе буенча кәрәзле телефонга охшаган санлы кабул итү җайланмасы. Кагыйдә буларак, аның составында сим-карта, микрофон, тукландыру элементлары һәм афәт төймәсе бар. Бу җайланма төрле формаларда булырга мөмкин: әйтик, брелок, кул сәгате яисә гадәти бер тартма рәвешендә... Әгәр балага куркыныч яный икән, ул шул төймәгә баса, бер үк вакытта әти-әни телефонына да сигнал килә. Кирәк икән, әти-әни турыдан-туры трекерга шалтыратып, баласын микрофон аша тыңлый ала. Әлегә бу иң нәтиҗәле җайланмаларның берсе булып санала.

Классик трекерлар сим-карта белән бер комплектта сатыла. Алар батарейкада эшли. Әти-әниләргә сигнал программа куелган телефонга яисә компьютерга килә. Трекерны баланың йөрү маршрутына көйләргә дә була.

Шунысын да исегезгә төшерәбез: җинаятьчеләр иң элек корбаннарының телефоннарын юк итәргә ашыга. Чөнки телефон буенча баланы эзләп табарга мөмкин булуын алар яхшы белә. Шунлыктан, трекерны күзгә күренми торган урынга беркетергә кирәк. Кулонга, мәсәлән... Балагыз белән әледән-әле җайланманы ничек кулланырга кирәклеге турында инструктаж үткәреп алыгыз, өйрәтегез, исенә төшерегез! Трекерның сим-картасы «МТС», «Билайн», «Мегафон» операторларыныкы булса, тагын да яхшырак.

РАДИОМАЯК

Баланың кайдалыгын радиомаяк та бик тиз билгели. Ул әти-әнигә дә, балага да куела. Сабый өйдән ераклаша башлады исә, үзеннән-үзе сигнал килә башлый. Дөрес, бу инде искерә башлаган җайланма. Хәзер аңа алмашка башка санлы җайланмалар, Bluetooh һәм кәрәзле элемтә килә.

ЛОКАТОР

Бу – мобиль элемтәсенең гадәти оператор сервисы. Ул кәрәзле телефонны трекер сыйфатында файдаланырга мөмкинлек бирә. Моны янә «МТС», «Билайн», «Мегафон» операторлары тәкъдим итә. Моннан тыш, «МТС»ның «Бала күзәтү астында» дип аталган мобиль хезмәте дә бар. Әти-әниләрнең күбесе бу алымны хуплый. Чөнки ул уңайлы гына түгел, экономияле дә.

NIMB

Әле күптән түгел генә кулланыла башлаган бу җайланма бөҗра рәвешендә. Аның ярдәмендә якыннарыңа, туганнарыңа хәбәр бик тиз арада килеп ирешә. Чит илдә аннан еш файдаланалар. Аның бәясе якынча 5 мең сум тора.

ISWIMBAND

Әлеге җайланма – ул Apple Iphone өчен эшләнгән. Балагызны суга батудан саклый, баткан очракта табып алырга булыша. Үзе тасма шикелле. Йөзгәндә аны йә башлыкка, йә күзлеккә, йә булмаса, кулга киясең. Әгәр дә су коенучы су астында билгеләнгән вакыттан озаккарак кала икән, җайланма шундук әти-әнигә бу хакта хәбәр итә. Бу гаджет бигрәк тә АКШта киң кулланыла.

ФИКСИКЛАР

Бу сәгать һәм беләзекләр трекерлар сыман эшли. Аның эчендә – сим-карта. Баланың кулыннан беләзекне салдырганда, шундук сигнал эшли башлый.

Әлеге электрон җайланмаларның өстенлеге бик зур булса да, иң үтемлесе: бала белән гел сөйләшеп – элемтәдә тору. Ул һәрнәрсәдә мәгълүматлы булырга, яхшыны яманнан аера белергә тиеш! Әти-әниләр бу хакта бер генә минутка да исләреннән чыгармасыннар иде.



Фото интернеттан алынды

PRESSA.RU



«КИНОГА ТӨШҮ – ХЫЯЛЫМ ИДЕ»







ТИЗДӘН ТЕЛЕВИДЕНИЕНЕҢ I КАНАЛЫНДА «АЛТЫН УРДА» СЕРИАЛЫ КҮРСӘТЕЛӘЧӘК.

Татарстан Республикасының атказанган артисты Эльмира КӘЛИМУЛЛИНА «Алтын Урда» сериалында төп рольләрнең берсен уйный. Тарихи блокбастерда Зәйнәп образын тудырган актриса белән кастинг, кинога төшү, дубльләр, рольләр турында сөйләшәбез.

Эльмира, сине тиздән экраннарда «Алтын Урда» сериалында Зәйнәпролендә күрәчәкбез. Кыяфәтеңне инстаграмда күреп, аптырабрак та калдык. Чумадан калган җөйләр, җилдә ярылып беткән иреннәр, зәңгәрләнгән күз төпләре... Аңлашыла инде, грим шулай «бизәгәндер». Шундый чибәр Эльмира тамашачыга әнә шундый кыяфәттә күренергә риза булганмы? Кәефе кырылмаганмы?

– Бу – кино дөньясы. Мин үземне драматик рольдә сынап карый алуыма бик шат. Биредә хисләр, эмоцияләр, кылган гамәлләр, каршылыклар – барысы да чынчынлап, барысы да тормыштагыча. Ә грим ярдәмендә теге яки бу эффектны тагын да көчәйтергә мөмкин. Сценарий буенча, героинямның чәчләрен чума вакытында кисеп ташларга тиешләр. Ризалаштым. Әмма картина режиссеры Тимур Алпатов эшне мондый кискен чаралардан башка гына дәвам иттерергә булды.

Ә ул гримны ничегрәк салдылар, бу процесс озакка сузылдымы?

– Образны грим белән костюм бергә булдыра, берсе икенчесеннән башка мөмкин түгел. Гримлау процессына бер 40 минут кына вакыт киткәндер – профессиональ гримерлар үз эшләрен бик тиз башкардылар. Әмма минем өчен бу үзе бер серле йола, могҗиза иде. Һәрбер тәфсил, һәрбер штрих – барысы да бик мөһим. Авырулар чатырындагы образны тудыру өчен грим ярдәмендә җәрәхәтләр ясадылар. Аларны ясау өчен махсус җилем һәм грим өчен төсләр палитрасы кирәк. Һәр яраны мөмкин кадәр пөхтә итеп, алдагы кадр белән төгәл туры килерлек итеп җентекләп ясадылар. Әйтик, җилдән ярылган иреннәрне ясау өчен ак тональ крем, җилем, телгәләнгән мамык кисәкләре кирәк булды. Иреннәргә юка итеп крем катламы сөртелде. Шуның өстенә бер катлам махсус җилем, вакланган мамык беркетелде, аннары яңадан клей белән ныгытып куелды. Килеп чыккан «композицияне» төрле буяулар ярдәмендә тән төсенә керттеләр. Күз төпләрендәге күгәргән, кара янган урыннарны ясау – иң җиңеле. Кайчагында йокы туймаудан алар кадрда аеруча табигый күренәләр иде.

Үзең уйный торган героең Зәйнәп белән якынрак таныштыр әле. Кем ул? Бу рольгә сине кем чакырды? Кайчан булды бу хәл? Син ничек кабул иттең?

– Бу көнне бик яхшы хәтерлим. 2016 елның 27 марты иде. «Пирамида»да узачак беренче сольный концертыма әзерләнеп йөргән көннәрем. Кибеттә концертта чыгыш ясарга дип күлмәк сайлыйм. Шулчак миңа директорым Анна шалтырата. Телефон трубкасын алуга ук: «Эльмира Рамилевна, син утырып торасыңмы?» – дип сорый. Ә мин күлмәк киеп маташам. «Сөйләшә алмыйм», – дим. «Зинһар, дип әйтәм, утыр!» – дип ялына директорым. Нәрсә инде бу?! Ярар, утырдым. Ә ул: «Сине «Алтын Урда»га кастингка чакырдылар!» – димәсенме! Бу хәбәр башыма сыймады! Ничек?.. Кайчан?.. Ни өчен мине?.. Минем исемем «Мосфильм»ның кино кастинглары картотекаларына кертелмәгән бит... Искә төшерсәм, хәзер дә каз тәннәре чыга. Гомер буе кинода төшәргә хыялландым бит! Бигрәк тә хәзер популяр булган сериал жанрында! Концертымнан соң Мәскәүгә очтым. Кастинг... Рольгә сайлап алулар... Ике айдан соң миңа шалтыраталар: «Сез сайлауларны үттегез. Зәйнәп роле – сезнеке», – диләр. Бәхетем эчемә сыймады. Кинода төшәргә әзерләнә башладым. Образымны, һәрбер күренешне актер Дмитрий Калязин белән берлектә эшләдек. Аның актерлык осталыгы буенча үз лабораториясе бар. Мин аңа бик рәхмәтле. Зәйнәп образы тышкы яктан гына түгел, ә иң беренче чиратта эчке дөньясы белән матур ул. Ул үзенең эчкерсез хисләренә тугры калган көчле рухлы ятимә кыз. Аның көче – чиксез мәхәббәт. Башкалар бәхете өчен ул мәхәббәтен корбан итә. Зәйнәп – ханның яраткан җәмәгате Айҗанның хезмәтчесе. Зәйнәп тә, Айҗан да бер үк каһарманга гашыйк... Хәер, бу урында туктап торыйк әле. Бөтен серләрне дә ачып бетермик. Барысын да үзегез күрерсез.

Кинога беренче төшкән көнне кычкырып елыйсым килде!

Ярый, Эльмира, килештек. XIII гасыр, ханнар, Алтын Урда чорын күз алдына китерү өчен тарихтан үзеңә дә эзләнергә туры килгәндер инде, әйеме?

– Рольгә әзерлек барышында мин шул чор тарихы белән таныштым. Бик кызыклы, мавыктыргыч процесс. Героинямның үз-үзен тотышына, гадәтләренә дә кайбер сыйфатлар өстәдем.

Эльмира, костюмнар турында да берничә сүз әйтсәң икән...

– Шул чорга туры килсен өчен костюмерлар тукыма, фурнитура, бизәнү әйберләрен төрле илләргә йөреп сатып алдылар. Әйтик, Зәйнәпнең алкалары Һиндстан базарында сатып алынган. Ул чорда моданы Кытай билгеләгән бит. Шул сәбәпле, сериал костюмерлары костюм тарихын бик тәфсилләп өйрәнделәр. Минем костюмым исә купшы детальләрсез, бик гади иде. Зәйнәп бит чыгышы белән үзе дә гади халыктан.

Бу яңа амплуада үзеңне ничек хис иттең? Ниләр кичердең? Сиңа нәрсә көч бирде?

PRESSA.RU

– Әйткәнемчә, кинода уйнау – минем күптәнге хыялым иде. Бик кызыклы роль, искиткеч актерлар составы, сериал командасы – зур бер гаилә кебек. «Алтын Урда»да төшү зур тәҗрибә һәм уңыш мәктәбе булды ул. Кешеләр еллар буе училищеларда, театр вузларында укып, еллар буе роль алырга хыяллана. Шуңа күрә «Алтын Урда» язмыш бүләге булды минем өчен. Эш барышында миңа барысы да бик булыштылар. «Марс-медиа»ның креатив продюсеры Елена Денисевичка аерым рәхмәтемне җиткерәсем килә. Монтаж вакытында сайлау мөмкинлеге булсын өчен, һәрбер дубльне кызыклырак башкарырга тырыштым. Беренче тапкырда ук килеп чыкмады, әлбәттә. Тез буыннарым калтырый, телем көрмәкләнә. Минем беркайчан да шундый хәлдә калганым юк иде әле. Дулкынланам, нәрсәнедер дөрес эшләмәдем кебек тоела. Ничек уйнаганымны белмим бит. Аны режиссер һәм оператор гына күрә! Кичен ашханәдә утырганда Дина Тасбулатова (ул ханша Айҗанны уйный) кәефем юклыкны шундук чамалап алды. Минем бер нәрсә дә барып чыкмый бугай, дим. «Ә син беренче дубльдән соң ук бөтенесе ал да гөл була дип белдеңме әллә?! Бөек актерлар да бер генә дубль ясамыйлар!» – ди!

Түземсезлек белән сериалның экраннарга чыгуын көтәм.

Фильмда төшкәндә иң кыены нәрсә иде? Рәхәт мизгелләр булып күңелеңә кереп калган кадрлар кайсылары?

– Кино төшерү мәйданында иң авыры – игътибар туплау. Актердан тыш, кино төшерү процессында дистәләгән кеше катнаша. Актер үз игътибарын төшерелә торган күренешкә генә тупларга тиеш! Камера тавышы да, кешеләр көлүе дә, яктыртылышның туктаусыз үзгәреп торуы да – берсе дә аны читкә юнәлдерми, борчымый. Бары тик монда һәм хәзер! Күренешнең шул мизгеленнән башка актер өчен бернәрсә дә юк. Бер күренештән икенчесенә күчү бер дә җиңел булмады, әлбәттә. Чөнки сериал күренешләре – ул төрле вакыт аралыклары, вакыйгалар, героинямның төрле хис-тойгылары, кичерешләре. Әмма барысы да тәҗрибә туплагач килә икән.

Сериалда йолдызлы исемнәр дә шактый бугай...

– Сериалның актерлар составы бик көчле иде. Киң җәмәгатьчелеккә таныш булмаган яшь актерлардан тыш, талантлы, исемнәре билгеле артистлар да уйнады. Юлия Пересильд, Александр Устюгов, Артур Иванов, Санжар Мади, Владимир Веревочкин, Сергей Пускепалис, Дина Тасбулатовалар... Ләкин алар берсе дә үзен йолдыз кебек тотмады. Һәркайсы гади, ихлас, ярдәмчел иде. Үзебезнең Камал театры актрисасы Нәфисә Хәйруллина белән дә төштек фильмда.

Съемкалар кайларда узды, Эльмира? Шактый өлеше Кырымда төшерелгәнен беләбез.

– Кинога төшерү Мәскәү тирәсендәге Поши утравында, Кырымда һәм «АМЕДИА» павильоннарында барды. Бу процесс ярты елга сузылды. Минем белән төп кадрлар Кырымда төшерелде. Сентябрьнең беренче атналарында анда бик җылы иде. Ләкин октябрь якынлашкан саен, үзәкләргә үтәрлек, хәтта зур декорацияләрне аударырлык җилләр исә башлады. Көчле яңгырлар кино төшерергә комачаулады. Салкыннан иреннәр дерелди, сүз дә әйтәлмәс хәлгә җитә идем...

Сиңа, күчмә кабилә кызы буларак, атка атланып, ук, җәя күтәреп йөрергә дә туры килгәндер, бәлки?

– Юк, миңа атта атланып йөрергә туры килмәде. Кино төшерү көне тәмамлангач, теләсәк, атта да йөри ала идек анысы.

Фильмда казакъ артистларының күпләп катнашуын ничек аңлатасың?

– Бу – халыкара проект. Шуңа күрә казакъ актерларының катнашуы безнең сериалның алыштыргысыз бер өлеше иде. Өстәвенә, тышкы кыяфәтләре, фактуралары белән алар үзләре уйнаган образларга туры килеп торалар.

Үзең тудырган образдан син канәгать калдыңмы? Эльмирадагы кайбер сыйфатлар Зәйнәптә чагылдымы?

– Нәтиҗәне күрмичә, үземнең халәтем турында әйтүе кыен. Әмма эшемнән канәгать калдым. Тәнкыйть күп буласын да беләм, ләкин бу – котылгысыз. Сериалда уйнау – кинода беренче адымым. Режиссер, продюсерлар миңа ышаныч белдерделәр – иң мөһиме шул. Ә Зәйнәп образы үзенең эчке тавышына һәм йөрәгенә колак салуы белән якын миңа.

Җырчы буларак, актриса амплуасына күчү кыен булмадымы? Режиссер кушканны үтәү һәм башкалар?

– Җырчы һәм актриса булу – минем өчен бербөтен. Сәхнәдә җырлаганда син тамашачы алдында мини спектакль уйнаган төсле. Әлбәттә, кинода башка механизмнар да бар: анда берничә дубль ясарга, кирәкле хис-халәтне сайларга мөмкин. Әмма сәхнәдә дә, кинода да иң мөһиме – ихлас булу. Һәр хәрәкәт, һәр караш табигый булырга тиеш. Тамашачы фальшьны, кылануны шундук сизәчәк. Чын күңелдән чыккан хисләр генә тамашачы һәм режиссер көткәнне җиткерә ала.

Без синең талантыңа, ихласлыгыңа, башкару осталыгыңа ышанабыз, Эльмира! Һәм түземсезлек белән фильмны көтеп калабыз!

Әңгәмәдәш – Эльмира ЗАКИРОВА.



БЕЗДӘН БАШКА БУЛАМЫНИ?!



5–11 сентябрь көннәрендә Казанда Халыкара мөселман киносы фестивале узды. Бусы – унөченчесе. Көз башының бизәгенә әйләнгән фестиваль бу юлы да күп милләтле, күп телле булды, дөнья мәдәнияте үрнәкләрен бер табынга җыйды. Яратабыз без бу фестивальне, күз күремен, рухи офыкларны киңәйткән өчен яратабыз. Аны бигрәк тә хатын-кызлар ярата. Чөнки фестиваль безнең хакта – хатын-кызлар хакында сөйли. Елый-елый, чаң кага-кага сөйли, ә кайвакыт көлә-көлә...

Асия ЮНЫСОВА

Фестивальнең беренче көнендә үк «менә шундый, 16 серияле фильм булачак» дип, алдан ымсындырып кую өчен генә тәкъдим ителгән «Алтын Урда» фильмы да, алдана күрмәгез, тарихи фильм түгел, бәлки, отышлы брендны файдаланып калырга тырышу гына.

«Бренд» дигән модный сүзгә килгәндә исә, аны әле тагын кулланмакчы булам. «Тапшырылмаган хатлар» фильмына карата. Бу фильм «Гадел Кутуй әсәренә нигезләнеп» түгел икән ләбаса. Баш каһарманнарның исем-фамилияләре генә Кутуйдан. Ярый, ул кадәресе мөһим дә түгел. Ә болай кинофильм үзе дә, артистлар уены да әйбәт кенә. Режиссер Рөстәм Рәшитов әйтәсе килгән фикерен әйтү өчен новаторлык күрсәткән. Гадел Кутуй белән Галимә Кутуева яшәгән заманда да мәхәббәт – мәхәббәт дип, хыянәт хыянәт дип аталган. Галия белән Искәндәрнең һәм дә тагын Вәлинең (Гүзәл Сибгатуллина, Айдар Сөләйманов, Ришат Әхмәдуллин) мәхәббәте рәвешендә укучыга тәкъдим ителгән аларның үз тарихлары безне җитмеш елдан артык тетрәндереп, хисләндереп, сокландырып торуы да хак бит. Кайнар хисләрнең шаһиты булган вуз биналары да исән. Саф күңелле яңа студентлар исә инде яңа гашыйкларның мәхәббәтенә шаһит. Галиянең фидакарьлеген, сагышларын күргән татар авылы гына, фильм авторлары фаразлавынча, элеккечә – михнәтләнеп, алгарыштан тибәрелеп яшәп ята. Вакыт эчендә китә-кайта йөрүләрнең үзенә күрә бер интригасы да бар: заман үзгәрә, әмма кешеләр, аларның табигате үзгәрешсез кала. Тугрылык, түземлелек, тырышлык, эчкерсезлек кебек сыйфатлар һәр заманда да кирәк. Үзеңне югалтмау өчен кирәк. Сынмау өчен кирәк.

Татар кызы турындагы мин караган фильмның икенчесе дә әнә шул сыйфат – сынмау хакында! «Айсылу» дигән бу фильмның да бер режиссеры Рөстәм Рәшитов. Икенчесе – Солтан Сөнгатуллин. Ике култык таягы ярдәмендә – сәнгать дөньясында күрелмәгән хәл – музыкаль олимпны яуларга хыялланган Айсылу тарихын фестиваль тамашачысы үтә дулкынланып, йөрәгә аша кичереп карады. Мин үзем дә битараф кала алмадым. Чөнки быел гына шундый язмышка дучар булган – авариядән соң имгәнеп калган, бөтен гомерен ике култык таягына таянып уздырган ханым турында язган идем. Инде менә шундый ук язмышка дучар булган кыз – экранда. Мин язган ханым да, Айсылу да бик чибәрләр. Тик менә Айсылу бик матур җырлый да икән. Җырлаган күңелдә, әлбәттә, хыял яши. Әле ул андый хыялы барлыгын үзе дә белми. Тик сандыктагы «җенне» уятучы, җырчы кызның, Казанга килсә, һичшиксез, йолдыз булачагына ышандыручы табыла. Айсылу роленә Кариев театрының бик чибәр һәм бик матур җырлый торган талантлы артисткасы Гөлназ Галимуллина сайлап алынган.

Бу фильмда Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Венера Ганиева, Татарстанның халык артисты Римма Ибраһимова кебек шәхесләр дә җәлеп ителү – экрандагы тамашаның ышандыру көчен бермә-бер арттыра. (Ә менә Камал театры артисты Фирая Әкбәрова, гомумән дә, экран артистына әйләнеп беткән – ике фильмда да судагы балык кебек йөзде.) Инде хәзер тамашачы Айсылуның «Татар моңы» бәйгесендә катнашуына да ышанды, чөнки кул чабып утырган тамаша залы реаль иде. Алай гына да түгел, тамашачы Айсылуның «Татар моңы» бәйгесендә җиңеп чыгуын көтә. (Гөлназ Галимуллинаның үзенә дә, героинясы эзеннән – эстрадага килергә кирәкми микән әле? Бигрәкләр дә өздереп, моңлы итеп җырлый бит.) Шуңа күрә сценарий авторы Алексей Барыкин фильмның дәвамын төшерергә вәгъдә бирми булдыра алмады.

PRESSA.RU

САБА ЮЛЫ КИЛӘЧӘККӘ ИЛТӘ



Мәдинә АВЗАЛОВА

ЧИТ КЕШЕ КУЛЫНДА СЫЕР «БОЗЫЛА» ДИП, ЯЛГА ДА КИТМИ БИТ АЛАР. ШУЛАЙ ИТЕП ЯРАТКАНДА ГЫНА МАЛ ӘҖЕРЕН ИКЕЛӘТӘ КАЙТАРА.

Их-х, кызганыч, җәйләр бик кыска безнең якларда. Ә быел ул булмады да диярлек. Койды да койды яңгыр, чиләкләп койды. Җир үзенә кирәген тәмам алды. Быел уңыш та әллә ни булмас инде дип уйлап йөргән идек. Ә юк... Сабаның йомырка тәгәрәтердәй юлларыннан очып кына авылдан авылга йөргәндә фикер үзгәрде. Безне бер дә авырсынмыйча көнозын озата йөргән юлдашыбыз – агропромышленность комплексы авыл хуҗалыгы хезмәткәрләренең профсоюз комитеты рәисе Дания Муллануp кызы Галимуллина алдан ук тынычландырып куйды. «Өлгереп җитә алмас дигән идек, кукурузы да күкрәп үсте әнә, печән дә шәп быел, игеннәр дә шәп...» – дип, рухланып, куанып сөйләгән юлдашыбызга карап, безнең дә кәеф күтәрелеп китте. Нурлы йөзен бик сирәк күрсәткән кояш та бүген кыздырыпмы-кыздыра. Безнең әле дөбердәтеп эшләгән, гөрләтеп яшәгән ике матур гаиләдә буласыбыз бар. Уйлаган уйлары, эшләгән эшләре нинди икән аларның? Кызык бит! Алдан баручылар бит алар!

«Әллә каян таныйлар»

Ул, үзе әйтмешли, бизәнеп-ясанып өстәл артында утыра торган кешеләрдән түгел. Урта мәктәпне тәмамлап, Казандагы секретарь-референтлар әзерли торган лицейга барып кергәндә, бу хакта уйлап та карамаган. Ә хәзер әнә: «Кәгазьләргә күмелеп утыру – минем эш түгел, мин моны бик тиз аңладым», – ди. Шулай бит ул. Ни телгәнеңә тора-тора, яши-яши төшенәсең. Аның каруы, ул юлдан инде син беркайчан да һәм берничек тә тайпылмыйсың. Чөнки син моны йөрәгең кушканга эшлисең.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Рәхмәт хаты иясе, былтыр «Һөнәре буенча иң яхшы» бәйгесендә 2 нче урынны яулап, «Иң яхшы терлекче – бозау караучы» исемен яулаган Айназ Рафаэль кызы Шайнурова белән керсәң әйләнеп чыкмаслык зур өйләрендә күргәннәребездән хәйран булып йөргәндә дә, каерылып үскән печән басуыннан кул сузымында гына урнашкан Курсабаш хуҗалыгы фермасында бәләкәч бозауларның ялтырап торган сыртларын сыйпап кинәнгәндә дә әледән-әле шул сөйләшүгә әйләнеп кайттык.

Авылның киләчәге бу төбәкнең тигез-шома юлларыннан, робот-фермалардан, калай түбәле зур-төзек йортлардан башлана.

Дөресен әйткәндә, ул башкалардан бер ягы белән дә аерылып тормый. Әйтүенә караганда, 7 яшькәчә Казанда яшәгән. Әтисенең туган нигезе бушап калгач, шушы якларга кайтып, шәһәр кызыннан авыл кызына әйләнгән. Шушында булачак ире Илнар белән танышкан. Бер-бер артлы туган балалары – Илфар, Айсинә, Ильяс та инде бүген кайсы – мәктәптә, кайсы – бакчада. 150 хуҗалыклы кечкенә генә авыл булса да, биредә балалар бакчасы да, урта мәктәбе дә, кибете дә, Мәдәният йорты да бар. Иң мөһиме: яннарында алар өчен өзелеп торган, эштән кайтуларын табын тулы ризык белән сагынып көтеп ала торган әниләре бар. Айназ кайнанасына, яратып, үз итеп, «әни» дип дәшә.





PRESSA.RU



■ Гөлгенә Хатыйп кызы Фәләхова:
– Ял итсәң, сыерлар бозыла, – ди ул. – Чит кешене якын китерми бит алар. Бер савымга саварга бирмәсә, өч савылышта имчәге шешә. Мал ул барын аңлый. Яратсаң, алар да сине ярата. Кайчак ялгыш аягыма басалар да, кызлар: «Ник берне эләктереп алмыйсың?» – диләр. Миңа басам дип басмады ич ул, дим. Кызганам хайванны. Көлсәм дә, еласам да – шулар арасында».

«Ул әйбәт, – ди килен кеше, – аңа башкача әйтеп тә булмый». Ике сүзнең берендә «кызым», «кызым» дип торган кайнанасы, әле табын тирәсендә кайнаша, әле оныклары белән... бер генә минут та тик тормый. «Аякларым гына сызлый, – ди 35 ел фермада эшләгән данлыклы сыер савучы Ания ханым. Димәк, килennнең үрнәк алырдай кешесе янәшәдә генә...

Саба районының республикада алдынгылардан булуы бер дә гаҗәп түгел: халкы нинди бит аның!

Һәм... ире дә янында гына. Алар икесе бер фермада эшли. «Эшлисе килгән кешегә авылда эш җитәрлек», – дип сөйләгән Илнарның тормыштан зарланырлыгы юк. Гомумән, эштән башканы күрмәгән, ел әйләнә эшләгән авыл кешесе зарлана белми ул. Аның гел әйбәт булыр. Шайнуровларның да шөкер генә кылырлык. Әнә бит нинди уңган хатын, нинди күндәм, акыллы килен...

– Ничек таныштыгыз, каян табыштыгыз? – дип кызыксынам, иңгә-иң терәлеп, диванда утырган ир белән хатынга карап.

– Башта телефоннан шалтыратты. «Ой, ялгыш шалтыраттың», – дим. «Юк, ялгыш түгел. Кичен бакча башына төш», – ди бу миңа. Төшеп барам шулай. Ә безнең бакча башында зур миләш агачы үсеп утыра. Ул шуның янына чүгәләп утырган да уйга чумган. Яныннан тиз генә үтеп китмәкче идем, туктатты бу мине. Миләш төбеннән башланды безнең танышлык. Озак йөрмәдек. Ул минем укып бетергәнемне генә көтеп торды да туй ясадык. Тугыз ел инде бергә, – ди ул, иренә назлы караш ташлап.

Ул ничек итеп беренче мәртәбә фермага сыер саварга төшүен, бер елдан бозаулар карарга алынуын җентекләп сөйли.

Эт оясыдай бәләкәй зәңгәр куышларда кайсы битараф кына безне күзләгән, кайсы сыртын куеп йокымсырап яткан нәни бозауларның һәркайсына дәшеп, шулар арасында мәш килгән Айназ: «Алар мине әллә каян таныйлар», – дип куана. Танымаска, әни ич инде ул аларга! Көненә 6-7 литр сөтен эчерә. «Шешәдән» төшкәннәренә сенажын, фуражын сала, асларын чистарта, бәби карагандай карый. Шулай тырышсаң гына була ул. Ни дисәң дә, җаваплы аларның эшләре. Алны-ялны белмәгән бу хезмәт тынгылык күрсәтми. Ферма белән өй арасын гына да ничә тапкыр әйләнеп кайталар икән алар?! Шуңа да: «Кайда ял итәсез?» дигән тинтәк сорауны биреп торма инде син. Көләчәк кенә алар синнән. «Нинди ял ул?! Нәрсә сөйлисез?! Сыерлар, бозаулар нишләр?» Ихластан шулай дияр алар. 365 көннең бер көне шул мәшәкатьләрдән башка узса икән?! Әгәр дә Айназ бүген 135 бозау карыйм дип әйтә икән, ул бит аны авырсынып әйтми, горурланып әйтә. Фермадагы эш шартларының көннән-көн камилләшә баруын, кул эшләренең бетә баруын күз алдында тотып әйтә. Элек бит бер кешедән 135 бозау карату төшкә дә кермәгән. Шулай ич инде. Чөнки профсоюз лидеры әйткәнчә: «Бүген көрәге, чиләге, сәнәге, көянтәсе – тарихта...»

Почмагы саен нур балкып торган уңган йорт хуҗалары белән саубуллашып, Ике Басу Арташ авылы ягына борылабыз. Бу төбәкнең күренекле кешеләре белән танышуыбыз дәвам итә.

«Гөлгенә ул бер генә...»

Авылдашлары, райондашлары өчен ул шундый: бер генә... Авылда дип әйтмим инде, районда аның ишеләр бармы икән әле?! Һәр сыердан уртача 30 литр сөт савып алуга ирешү өчен, Гөлгенә Хатыйп кызы Фәләхова шикелле, бер ялсыз эшләргә дә эшләргә кирәк. Шушы авылга килен булып төшүенә 26 ел, сыер савучы булып эшли башлавына да, кайнана белән яши башлавына да 26 ел. Стажлы килен, олы тәҗрибә туплаган сыер савучы. Аның кебек килен дә, аныкы кебек үз әниседәй кайгырта торган кайнана да юк дөньяда. «Фермадан арып кайтып, бераз ятып торсам, шыпырт кына килеп, йокы бүлмәсенең ишеген ябып куя», – дип, тикмәгә генә сөйләми ич ул. Йөрәгенә май булып ятканга, күңеленә мәңгегә кереп урнашканга сөйли. Эше турында да сөйли. «Ферма мөдиреннән 25 ел ялсыз эшләдем дип, ял сораган идем, 25 ел эшләгәнне тагын бер ел гына ялсыз эшләрсең әле диде», – дип көлдереп тә ала.

Стенага элengән зур афишадан безгә хоккейчы кыз елмая. «Бу кем?» «Минем кызым, Ләйсәнем, – ди әни кеше, чиксез горурланып. – Хоккейчы ул, Дөнья чемпионы. Әле хәзер Финляндиядә – ярышта. Булмаган иле, күрмәгән җире калмады. 19 гына яшь әле аңа. 15 яшендә Түбән Новгородка спорт мәктәбенә китеп барган иде, шул заманнан бирле – «Скиф» командасында». Шулай ди дә, безне нык гаҗәпкә калдырып, кызы яулаган

медальләрне күрсәтергә керешә. Үзе бер музей ачарлык бүләкләр белән тулы бүлмәдә аның белән икәүдән-икәү калабыз. Карават янындагы тумбочкага куелган фотодан безгә бер егет елмая. «Бусы кем? – дим, янә соравымны кабатлап, – бигрәк чибәр...»

– Улым Илүс – уртанчысы, – ди әни кеше үзгәреп китеп. Йөзендә – әйтеп бетергесез моң, сагыш... – Ул юк инде, вафатына ике ел да өч ай хәзер. Институтны тәмамларга бер генә ел калганда шундый хәл менә... Ул да спортсмен иде. Физкультура укытучысы булырга хыялланды. «Их-х, әни, бер генә ел укытып карарга иде армиягә киткәнче», – диде. Армиягә дә нык әзерләнде. Барасы килде. Булмады, һәлакәткә эләккән биш егетнең бишесе дә суга гына төшкәндәй булды. Бер минут исемнән чыкмый, – ди ана, күзләрендәге яшьне күрсәтмәскә тырышып. – Елыйсым килсә, фермага чыгып китәм дә сыерларым арасына кереп туйганчы елыйм. Кеше күрми, ичмасам.

Олы уллары Илназ – математика-информатика укытучысы. Хәзер үзенең бәләкәй кызчыгы бар. Без килгәндә Гөлгенәнең кайнанасы бәби янында кайнаша иде.

– Кемгә охшап спортсмен булганнар диген?!

– Белмим, өчесе дә шундый мөстәкыйль булдылар. Кемгә охшаганнардыр, – ди Гөлгенә. – Укырга кергәндә дә артларыннан йөрмәдем, беркая бармадым. Үзләре тырыш булдылар, миннән беркайчан да акча сорамадылар. Укудан соң акча эшләү юлын таптылар. Илүснең әйберләрен алырга баргач, ботинкасына игътибар иттем: кызыл балчыкка каткан иде. Күрәсең, кайдадыр эшләгән. Миңа әйтмиләр иде шул. Сигезне тәмамлап, ерак шәһәргә, бер белмәгән җиргә, бер белмәгән кешеләр арасына чыгып киткән кызым да шундый булды.

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының Мактау кәгазенә, Татарстан хөкүмәтенең Рәхмәтенә һәм башка күп кенә бүләкләргә лаек булган алдынгы сыер савучының ире Илсур да төшеп калганнардан түгел анысы. Ул да быелтыр «Кыр батыры» дигән мактаулы исемгә лаек булган. Кайгыны да, шатлыкны бергә күтәрә, бергә бүлешә алар.

Фәләховлар ишегалды мини-ферманы хәтерләтә: дүрт сыерлары бар икән аларның. Димәк, таңнан торып фермага киткәнче башта әле өйдәге «ферма»ны карарга кирәк. «Ничек өлгерәсең соң?» – дим. Бактың исә, өйдә дә сөт саву аппаратлары... Кемнең өч һәм аннан артык мөгезле эре терлеге бар, хуҗалык аппаратлар бирә. Хатын-кыз хезмәтен җиңеләйтү бит бу, бер уйласаң. Ни дисәң дә, сөтне ирләр түгел, хатын-кыз сава бит. Шулай итеп, тапшырылган сөттән аена 30 мең сум акча кереп бара. Монысы да ярап куя. Әле менә бер сыерлары игезәк бозау китергән. «Иң яраткан мал гына хуҗасына шундый игелек кыла», – дип нәтиҗә ясый Дания Муллануровна.

Инде китәргә әзерләнгәч кенә Гөлгенә: «Кыш көннәрендә мин үзем дә клубка йөрим», – ди дә, безне хәйран калдырып, башта – кулында, аннары башында торып күрсәтә. Ә без тагын «Балалар кемгә охшаган?» – дип баш ватабыз. Менә кемгә икән ич!



Саба районының авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе җитәкчесе Гафур ХӘСӘНШИН:

«ХАТЫН-КЫЗ ТӨГӘЛ УЛ, БУЛДЫКЛЫ УЛ...»

– Без ел саен терлекчеләр слеты – терлекчеләр бәйрәме үткәрәбез. Быел да ул гөрләп узды. Ул үзенә бер олы җыенга әверелде. Мондый бәйрәмнәрне оештырганда иң элек хезмәт кешесе турында уйлыйбыз. Көн-төн эштән кайтып кермәгән авыл кешесен ял иттерәсе килә. Күреп торасыз, авыл халкы хәзер әйбәт яши: өенә газы, суы кергән, керне машина юа дисәм, бер дә яңалык әйтмәм. Бу хәзер бөтен җирдә шулай.

Инде хуҗалыкларга килгәндә, кайсы гына ферма ишеген ачып кермә – техника, кул хезмәте юк диярлек. Бүгенге көндә районда роботлар эшли торган дүрт ферма бар. Киләчәктә андый фермаларны тагын да булдырырбыз дип торабыз. Сыер савучыларга, терлекчеләргә хезмәт хакы һәрвакыт вакытында биреп барыла. Монысы да мөһим нәрсә. Һәр йортта ишегалды тулы сыеры-бозавы, казы-үрдәге. Эшләгән, тырыш кешегә мөмкинлекләр җитәрлек. Уңганы аның урманнан җиләк җыеп та сата. Шулай бит?! Безнең 70 тән артык фермер хуҗалыгыбыз бар. Грант отып, быел алты гаилә фермасы үз эшен башлап җибәрде. Бусы да яңа эш урыннары дигән сүз. Эш бар икән, яшьләр авылда кала.

Сөт һәм ит җитештерү буенча безнең район республика күләмендә беренче өчлектә бара. Бу – әйбәт күрсәткеч. Кооперативларның, шәхси эшмәкәрләрнең яңа төр продукцияне сатуга чыгарудагы өлешен дә әйтмичә кала алмыйм. Экологик яктан чиста, табигый ризыклар – Саба төбәге тамгасы белән сөт, ит, бал, икмәк, төрле ярмалар, яшелчә җитештерү, башка күптөрле ризыклар әзерләү, бер яктан, район өчен мәртәбә булса, икенче яктан халыкны эш белән тәэмин итүгә һәм керемне арттыруга яңа юл ача.

PRESSA.RU

Ни өчен кат-кат киләләр аларга? Тормыш ыгы-зыгысыннан, шәһәр шау-шуыннан азга булса да китеп, онытылып торыр өчен генәме? Бәяләр түбән булгангамы? «Җәлилнефть» нефть һәм газ чыгару идарәсенә караган «Җәлил» санаторий-профилакториендә ял иткән һәркем бу сорауга икеләнмичә бер үк җавапны бирер, мөгаен:
– Монда Эльмира РИЗАТДИНОВА булганга! Коллектив шәп – шуңа!

Гөлнур ХӘСӘНШИНА



РЕКЛАМА ХОКУКЫНДА

ТӘНГӘ – ДӘВА, ҖАНГА – ШИФА

«Мин инде сезгә җиде тапкыр килдем. Яңадан киләсе килеп кайтып китәм...» (Рәхмәт сүзләре язылган дәфтәрдән.)

Һөнәре турында сөйләшүгә күчүгә, ул балкып китә: «Мин һәрвакыт табиб булырга хыялландым! Балалар табибы! Авыл баласы бит: аның «педиатр» дип аталуын беренче тапкыр институтка документлар тапшырганда гына ишеттем...» Диплом алуга яшь белгеч туган ягына – Сарманына әйләнеп кайта. «Җәлил» санаторий-профилакториена баш табиб итеп билгеләнгәндә исә Эльмира Дамир кызы Ризатдиновага нибары 35 яшь була. Нефтьчеләр өчен салынган, алар эштән соң килеп, сәламәтлекләрен ныгытып китә торган урын була бу профилакторий. Ә аннан кинәт тормышлар үзгәрә: санаторий да үз көнен үзе күрә башларга мәҗбүр була.

«Җәлил»не менә бүгенгедәй «җәннәт почмагы»на (ял итүчеләр сүзе!) әйләндерү өчен салынган көчне санасаңмы?! Биналар ремонтлана, яңартыла, бүлмәләр заманча шартларга туры китереп үзгәртелә, яңа дәвалау аппаратлары кайтартыла (һәм боларның барысы да ял итүчеләрнең кесәсенә сукмаслык итеп эшләнелә!)... Тик күпләр бирегә тәненә генә түгел, җанына да дәва эзләп килә бугай. «Җәлил»нең җәлилләләр – нефтьчеләр өчен генә хезмәт иткән көннәре инде күптән артта калган: бүген аларга халык бөтен Россиядән агыла.

«Җәлил» санаторий-профилакторие «Татнефть»-нең дәвалау учреждениеләре арасында узган смотр-конкурста гына түгел, Бөтенроссия бәйгеләрендә берничә ел рәттән көмеш һәм алтын медальләр белән бүләкләнгән, «Гаилә белән ял итү һәм дәвала-











ну өчен иң яхшы урын» номинациясендә дипломга ия булган.

– Төмән, Самара, Киров шәһәрләреннән киләләр. Хәтта чит илләрдән! – ди Эльмира Дамир кызы. – Канададан, Германиядән ял итүчеләр булды. Әйе, чыгышлары белән безнең яктан алар... Узган ел Кытай татарлары гаиләсен кабул иттек. Уллары Казанда укый аларның. Канәгать булып киттеләр. Миңа хәзер иртән күп вакыт телефоннан: «Һаумыһыгыз!» – дип шалтыраталар. Башкортстан шулай сәламли! «Килсәк буламы, урыннар бармы?» – диләр. Комидан кадәр киләләр. Бер елны Җәлилгә хоккей буенча тренировкага балалар алып килделәр. Шул вакыт аларның әти-әниләре бездә торган иде. Юлны белеп калдылар: һәр елны киләләр, дәваланалар... Әйе, бер булганнар кабат-кабат килә. Санкт-Петербург шәһәреннән бер ханым, мәсәлән, безгә гел Яңа елда, 1 гыйнвар көнне кичкә таба машина белән килеп төшә: гадәттә, кызын һәм улын, әнисен утыртып...

Күпләр: «Өйдәге кебек рәхәт сездә», – диләр. Безнең санаторий бик кечкенә бит: нибары 50 урынлык кына. Шуңа күрә дә үзебездә ял иткән һәркемнең исемен хәтерләп калырга өлгерәбез. Шуңа да күңелләре була...

«Эльмира Дамировнага җылы итеп каршы алуы, кабул итүе, дәвалауны дөрес итеп билгеләве өчен рәхмәт...» (Рәхмәт сүзләре язылган дәфтәрдән.)

– Бездәге дәвалауның файдасын күрә, әлбәттә, халык. Менә бер мисал. Үзе дә шәфкать туташы булып эшләгән бер ханым килде. Аяк балтырындагы җәрәхәте коточкыч зурайган. Чиләнеп иткә чыккан. Карарга куркыныч... «Һәр сәгать саен авыртуны баса торган дару эчеп торам», – ди. «Кайларда йөрдең моңарчы? – дим. – Умыртка баганаңда бүсер булырга тиеш, сызлануларың – шушыннандыр». Анализлар моны раслады. Физиотерапия билгеләдек. Яралары җөйләнде. Узган көз бик сөенеп: «Авыртуны баса торган даруны хәзер көнгә берне генә эчәм», – дип килеп әйтте...

«Без халыкның өметләрен аклар өчен тырышабыз».

Халык башлыча «Җәлил»гә кан әйләнеше, нерв, бәвел куу системасы, сулыш алу, ашкайнату органнары, гинекология авыруларыннан дәваланырга, аяк-кулдагы сызланулардан котылырга дип килә. Утыз төрдән артык дәвалау ысулы көтә аларны! «Ана һәм бала» юлламаларына сорау һәрвакыт зур – еш авыручы балалар биредә иммунитетларын ныгыта.

Санаторийга аяк баскан һәркемне баш табиб үзе кабул итә: дәваны ул билгели. Биредә эшли башлагач,

PRESSA.RU

аңа бернечә яңа белгечлек үзләштерергә туры килгән: ул терапевт та, невролог та, физиотерапевт та, рефлексотерапевт та... Аның эшкә иртән җиде тулуга ук килеп, кичке җидедә генә кайтып китүенә монда инде күптән ияләшкәннәр. (Ярый, өйдәгеләре аңлый – ире Хәсән белән улы Артур аңа һәрвакыт зур терәк.)

– «Татнефть»кә, «Җәлилнефть»кә без бик рәхмәтле: нинди генә сорау белән мөрәҗәгать итсәк тә – ремонтмы, башкасымы – алар ярдәм итә. «Татнефть» яңа аппаратуралар алу өчен безгә ел саен акча бүлеп бирә. Әле менә магнитотурботром алдык. Бик акыллы аппарат! Ул безнең элек тә бар иде, монысы – яңарагы. Буыннар авыртуы, кан басымы, невроз, депрессия, кан тамырлары киңәю, тромбофлебит, миомадан файдасы зур. «Контактсыз ванна» дип хыялланган идек – ул да бар бездә хәзер. Пациент аппарат өстендә ята – аңа су бөтенләй тими, массаж астан дулкыннар ярдәмендә ясала. Хондрозлардан менә дигән дәва! Гомумән, безнең шартларда дәвалау өчен барлык аппаратларыбыз бар – аларны яңартып кына торабыз. Бернечә аппаратны алыштыручы «физиотерапевтик комбайн» кайтарттык. Әле менә «ударно-волновая терапия» дәвалау ысулы бар. Шул аппарат турында хыялланабыз. Ул авырткан нокталарга гына тәэсир итә. Артрит, артроз, остеохондроз, төрле бәрелү, имгәнүләрдән соң килүчеләргә бик килешер иде...

«Өлкәннәргә нәкъ татарча итеп – «абый», «апа» дип дәшәбез».

Шушы урында гына туктасак, «Җәлил»дә инде ял итеп киткәннәр: «Әле бит сез әйтмәгәннәр бик күп калды!» – диячәк.

– Бүген бездә, әйтик, илле кеше ял итә икән, аның иллесе дә массаж ала, – ди өлкән шәфкать туташы Земфира Мингалиева. – Йодлы-бромлыванналарга да бөтен кеше керә. Бу ванналар – безнең горурлык, суы үзебезнең скважинадан. Тынычландыра торган сыйфатка ия. Менопауза вакытында хатын-кызлар файдасын күрә. Озокерит белән дәвалаучы кабинет аша да бик күпләр уза. Чират булмасын дип, соңгы елларда ике сменада эшли башладык. Дәвалану шимбә-якшәмбе көннәрендә дә туктамый.

Лимфомассажер (артрит һәм артроз белән интегүчеләргә), коры углекислый газ ванналары (үпкә-тын юллары авыртулары, йөрәк-кан тамырлары системасы, буын чирләре), тоз мәгарәсе (аллергия, үпкә-тын юллары авыртулары), вакуум-массаж (аркадагы авырту бер сеанстан уза, диләр!)... Организмны озон белән баету. Кислород коктейльләре, үлән чәйләре... Бассейн... Релакс бүлмәсе. Җитеп торыр – калганын баргач күрерсез! Һәм болар барысы да бушлай икәнен белеп – шаккатырсыз!

«Санаторийда көннәр санаулы, әмма шушы кыска гына вакыт эчендә шулкадәр сыйфатлы итеп дәваладыгыз...» (Рәхмәт сүзләре язылган дәфтәрдән.)

– Соңгы елларда гирудотерапия белән шөгыльләнә башладым, – ди Эльмира Дамир кызы. – Сөлекләр белән эшләргә бик яратам. Сөендерерлек нәтиҗәләр дә бар инде. Казаннан бер пар ял итәргә килгән иде безгә. Балалары юк икән. Ир белән хатын инде өметләрен өзгән: безгә дә нииндидер дәва эзләп килүләре түгел иде. «Әйдәгез, тагын бер талпынып карыйк», – дидем. Сөлек белән дәвалауны да керттем. Балага узды ул, әмма ялгы үсмәде. Мин борчылам, ә ул ханым барыбер шатлана: «Мин бит, ниһаять, балага уза алдым!» – ди. Кабат дәваланырга килделәр. Уллары туды... «99,9 процентка «Җәлил» баласы ул безнең!» – диләр. Балага яшь ярым булганда Америкага күченеп киттеләр, анда тагын бер бәби алып кайтканнар – хәбәрләшеп торабыз.

Сөлек белән дәвалаганнан соң туган сабыйлар Җәлилдә дә өчәү инде...

«Сездә барысы да югары дәрәҗәдә куелган: хезмәткәрләр, ашханәдә эшләүчеләр, җыештыручылар һәммәсе дә ачык йөзле, якты кешеләр...» (Рәхмәт сүзләре язылган дәфтәрдән.)

– Коллектив ярты сүздән аңлый мине. Бар эштә дә аларга таянам. Шәфкать туташлары бернечә белгечкә ия бездә – монысы замана таләбе. Планнар елдан-ел арта тора: быел менә халыкка 21 миллионлык хезмәт күрсәтергә тиешбез. Юлларын эзлибез... Бистә сырхауханәсендә бездәге кебек аппаратура юк: халык дәваланырга санаторийга йөри. Җәлилләр безгә яратып килә, алар күбрәк «курсовка» ала – алай арзанрак. Халык үз сәламәтлегенә игътибарлы хәзер. Диагностика да күп. Хәтерләсәгез, элек авылларда бөкре әбиләр бар иде. Умырткаларында бүсер булган бит инде аларның. Вакытында табиб ярдәме алгач, бүген андый әбиләрне очратмыйбыз.

Ялга килгән һәркем киткәндә: «Ашханәдә эшләүче кызларыгызга рәхмәт!» – дип саубуллаша. Ризык өйдәге кебек әзерләнә бездә. Камыр ашларын үзләре пешерәләр.

«Сезнең санаторий турында бөтен танышларыма, дусларыма сөйләячәкмен...» (Рәхмәт сүзләре язылган дәфтәрдән.)

– Дәвалану өчен мөмкинлекләр күп инде бездә. Әмма ял итәргә дә шартлар бар, – ди санаторийның администраторы Лилия Арсланова. – Әлмәт шәһәренә алып барабыз. «Татнефть» безнең якта чишмәләрне төзекләндерде, матурлады бит: икенче экскурсия чишмәләр буйлап. Бистәдә М. Җәлил музее эшли – аны күрсәтәбез. Мәдәният сараеннан «Ак калфак», «Родники» ансамбльләрен чыгыш ясарга чакырабыз. Дискотекалар, танышу кичәләре үткәрәбез. Китапханәбез бар: «Татнефть» аны ел саен яңа китаплар белән баета.

Язын бездә ял иткән кеше, гадәттә, көзгә тагын киләм, дип язылып китә. (Сүз уңаеннан, чират инде 2018 елның җәенә кадәр төзелгән. *– Г. Х.*) Икенче тапкыр күпләр инде дусларын, туганнарын ияртеп килеп төшә. Менделеевскидан 12 кеше гел бергә ял итәләр әнә. Инде ничәнче тапкыр! Ә Самарадан бер төркем кышын килә, чаңгыларын да үзләре белән алып киләләр: бистәдә чаңгы шуу базасы да бар.

...Шушы рәхәтлекне, шушы игътибарны инде тоеп карарга телисезме? Килегез: «Җәлил»дә сезне һәрвакыт көтәләр!

ҖӘМГЫЯТЬ



■ **Казан Кремлендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов һәм аның тормыш иптәше Гөлсинә ханым хөрмәткә лаек гаиләләрне кабул итү мәҗлесе уздырды. Дүртенче мәртәбә узган бу чарага 53 гаилә чакырылган иде. Иң өлкән пар – Менделеевск районыннан Зоя һәм Иван Костиннар. Алар бриллиант туйларын билгеләп үтә икән. Зилә һәм Булат Мортазиннар – иң яшь гаилә: никахларына 10 ел. Татарстанның һәм Россиянең халык артисты Равил Шәрәфиев гаиләсендә дә бәйрәм: хатыны Раушания ханым белән 45 ел бергә гомер кичерәләр. Җырчы Салават белән хатыны Ләйсән исә – 30 ел бергә. Президент кунакларны кабул иткәндә: «Сез – республиканың зур байлыгы. Гаилә ул җылылык, мәхәббәт, игелек учагы», – дип сәламләде.**

■ **Татарстан Республикасы хөкүмәте йортында Президент Рөстәм Миңнеханов рәислегендә ТАССР төзелүнең 100 еллыгын билгеләп үтүгә кагылышлы утырыш узды. Утырышта Татарстан Дәүләт киңәшчесе Минтимер Шәймиев, Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин, Премьер-министр Алексей Песошин катнашты. Бәйрәм чараларының республика планы расланды, оештыру комитетлары һәм эшче төркемнәр оештырылды.**

■ **Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов сантехника җитештерүче иң зур компанияләрнең берсе – АКШның KONLER җитәкчелеге белән очрашты, аларга Татарстанда эшли башларга тәкъдим итте. Сөйләшү «Казан» ат спорты комплексында узды.**

МӘДӘНИЯТ

■ Зур Кызыл урамында Казан дәүләт консерваториясе каршындагы скверда танылган композитор Рөстәм Яхинга һәйкәл ачылды. Тантанада Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов та катнашты. Ул бөек татар композиторы, республиканың дәүләт гимны авторы Рөстәм Яхин әсәрләре белән горурлануыбызны җиткерде. «Яхин җырлары – республиканың визит карточкасы», – дип белдерде консерватория ректоры Рубин Абдуллин.

■ Казанның Һ. Такташ һәм М. Сәлимҗанов урамнары чатында бөек татар шагыйре Һади Такташка һәйкәл куелды. Аның авторлары – скульптор Андрей Балашов һәм Татарстанның халык рәссамы Асия Миңнуллина. Архитекторы РФ һәм ТР атказанган архитекторы Герман Бакулин. Тантанада Илбашыбыз Рөстәм Миңнеханов катнашты.

■ Казанның Черек күл паркында «Печән базары» яңа татар мәдәнияте фестивале шәһәр форматында узды. Ул шәһәр үзенчәлекләрен искә алып оештырылды. Анда көн дәвамында шагыйрьләр, музыкантлар, галимнәр, биючеләр, режиссерлар чыгыш ясады.



КОТЛЫЙБЫЗ

■ **Казан Ратушасында шәһәр мэры Илсур Метшин Татарстан Республикасының дәүләт бүләкләрен тапшырды. Театр һәм кино артисты, Мәскәүдәге «Современник» театрының сәнгать җитәкчесе урынбасары, җәмәгать эшлеклесе, якташыбыз Чулпан Хаматовага «Казанның шәрәфле гражданины» дигән исем бирелде.**



СПОРТ

■ Мисырның Каһирә шәһәрендә узган бишле ярыш (пентатон) Дөнья чемпионатында шәхси беренчелекне татар кызы Гөлназ Гобәйдуллина яулады. Биш төрле спорт ярышы: конкур, ату, фехтование, йөгерү, йөзүдә ул иң яхшы нәтиҗәләр күрсәтеп, алтын медаль яулады. Гөлназ Россия Федерациясе өчен чыгыш ясады.

ЯШЬЛӘР

■ Казанга, XXVII татар яшьләре көннәренә Россиянең 30 төбәгеннән һәм Канададан егет-кызлар җыелды. Әлеге мөһим чарада катнашу өчен 147 делегат теркәлгән. Алар «Борис Полевой» теплоходында Ульяновск, Самара, Тольятти, Болгар шәһәрләрендә тукталып, андагы татар җәмәгатьчелегенең эшчәнлеге белән таныштылар, тәҗрибә уртаклаштылар, татар теле, тарих, вокал, хореография, кул эшләре буенча мастер-классларда, семинар-тренингларда катнаштылар, дәүләт һәм иҗтимагый оешма җитәкчеләре, журналистлар белән очраштылар.



PRESSA.RU

БӨТЕНДӨНЬЯ ТАТАР КОНГРЕССЫНЫҢ VI СЪЕЗДЫНА КАЗАНГА ОКЕАННАР КИЧЕП, АМЕРИКАДАН, САН-ФРАНЦИСКО ШӘҺӘРЕННӘН ҮК КИЛГӘН НУРИЯ АПА КИЛКИНЕҢ ӘНИСЕ СӘГАДӘТ ТУРЫНДАГЫ ХИКӘЯСЕН ТЫҢЛЫЙМ.





Гөлнур САФИУЛЛИНА

«ҮЗ ҖИРЕМӘ ДИП КИЛДЕМ...»

– Бертуган апасы Хәнифә белән әнием 60 елдан соң гына табышты. Ниндидер танышлары аша эзләп тапты ул аны. Бу хакта сөйли башласам, әле дә күзләремә яшь тула... Хәнифә апаның Маньчжуриядән Рәсәйгә нигә чыгып киткәнен тәгаен белмим: әллә укырга, әллә әтиләрен эзләргә...

...Сәгадәт апа Акчурина Пенза губернасында туган. Туган авылының исемен белми дисәм дә була. Хәер, кайдан хәтерләсен – Рәсәй чиген узып, Кытай җиренә аяк басканда аңа нибары 3-4 яшь булган бит. Сәүдәгәр әтиләре җилләрнең кайсы яктан исә башлаганын чамалаган булгандыр инде... Әмма язмыш аны барыбер аямый. Монголиядән Советлар Союзына товар ташый ул. Чираттагы сәфәрләренең берсендә, чик аша чыкканда, Хәсән аганы кулга алалар һәм төрмәгә озаталар. Әтиләре шул китүдән югала. Балалары аның хакында берни белми яши. Ике ел элек кенә, ниһаять, архивлардан әтиләре турындагы документлар табыла. Аны инде ерак

1938 елда ук атып үтергән булганнар икән. Мулла баласына ягарлык гаепләр табылгандыр инде...

Сәгадәт апаның туганнарына да язмыш шактый кырыс булып чыга. Алар да татар мөһаҗирләре узган юлны уза, каберләре – дөнья буйлап сибелгән. Иң олы апасы, әйткәнемчә, әтисе артыннан ук китеп югала. Кече энесе 1953 елда чирәм җирләрне күтәрергә дип, Кытайдан шулай ук Россиягә китә һәм аның да башка хәбәре булмый. Бер абзыйсы Кытайда төпләнеп кала. Зөһрә апасы Төркиядә гомер иткән – ул ун ел элек вафат булган. Хәнифә апасы белән ничек күрешүләрен сөйләп бетермәдем бит әле.

– Бер елны әни Төркиягә кунакка барды. Шунда билет алып, аны Әзәрбайҗанга озатканнар. Үзгәреш җилләре башлангач, Хәнифә апаның адресын эзләп тапкан идек инде. Аның Баку шәһәре читендә, коммуналь фатирда, урыс күршеләре белән яшәвен белә идек. Еш кына телефоннан да шалтырата идек. Булышырга да тырыштык. Әни ул чакта аның янында – Бакуда берничә көн торды. Гомерләре берберсеннән читтә узган ике кыз туганның очрашуын күз алдына гына китерегез әле... Шуннан соң Хәнифә апа тагын ике ел гына яшәде. Без ул чакта Бакудагы бер татар гаиләсе белән танышкан идек. Аларның кызлары Сан-Францискога килгән иде. Шул гаилә, соңгы көннәрендә Хәнифә апага бик булышты. Вафат булгач, соңгы юлга да алар озатты, каберенә таш та куйдылар. Ходай берәүне дә ялгыз калдырмый...

Нурия апаның үзенең балачагы Кытайда уза. Әнисе укыган татар мәктәпләре аңа инде эләкми – белемне ул рус телендә ала. («Рус танышларым һаман шаккаталар: «Син татар булсаң да, рус әдәбиятын, шигъриятен бездән яхшырак беләсең», – дип әйтәләр», – ди ул.) Ә өйдә сөйләшү-аралашулар, әлбәттә, туган телдә – татар телендә генә була. Тукайны, Такташны, татарның башка әдипләрен, шагыйрьләрне яратуны аңа әнисе сеңдерә. Гаиләдә алар өч бала үсәләр. Абыйсы инде 35 ел элек үк вафат булган. Энесе Әдип Неверов – профессор, университетта укыта. Аны Казанда да беләләр. Ул да конгресска кунак буларак чакырулы иде.

– Без Кытайда байлык белән тормадык, әмма начар да яшәмәдек, – дип сөйли Нурия апа. – Әтием Абделәхәт сәүдәгәр иде – кибет тотты. Әнием – фармацевт, аның да үз даруханәсе бар иде. Гаиләбез шуңа да ачлыктан интекмәгәндер. Йортыбыз артык зур түгел иде. Әмма һәркайсыбызның үз бүлмәсе бар иде. Хезмәтче дә тоттык. Ә аннан тагын коммунистлар килделәр дә безне Кытайдан да сөрделәр... Соңгы вакыт анда тормыш авырлашкан иде инде, тик безгә иң авыры барыбер эләкмәде әле. Әти белән әни Төркиягә китәргә дип хәл иттеләр. Әнинең бер кардәше исә Рәсәйгә китте. Без алар белән инде башка хәбәрләшмәдек: Төркиядә андый мөмкинлек булмады. Чемоданга нәрсә сыя – шуны гына алдык, барысы да калды. Чик аша чыкканда, кыйммәтлерәк, яхшырак күренгән кием-салымны да тартып алды-



2-5 август көннәрендә Казан шәһәрендә Бөтендөнья татар конгрессының VI съезды булып узды. Анда Татарстаннан, Россиянең 73 төбәгеннән һәм 41 чит илдән 811 делегат һәм 207 кунак катнашты. Бөтендөнья татар конгрессы оешуга 25 ел тулган көннәргә туры килүе белән дә үзенчәлекле булды бу Корылтай. Аның эшендә Татарстан Республикасы Президенты Рөстәм Миңнеханов, Дәүләт Киңәшчесе Минтимер Шәймиев катнашты һәм чыгыш ясады.

Туган телебезне ни көтә? Ул яшәрме? Аны киләчәк буыннарга тапшыру өчен без кулдан килгәннең барысын да эшлибезме? Корылтайга җыелган милләттәшләрнең барысын да борчыган уртак сорау иде бу. Съезд мөнбәреннән туган телебез хакында иң ачынып чыгыш ясаган кеше Казан шәһәренең Ш. Мәрҗани исемендәге 2 нче татар гимназиясе директоры Камәрия ханым Хәмидуллина булды. Ул бик күпләрнең әйтәсе килгән фикерен җиткерде кебек:

– Милли мәгарифтән курку бар. Гаиләдә татарча сөйләшсәң, башлангыч белемне татар телендә бирсәң җитә, диләр. (Әмма әти-әниләр үзләре дә татарча сөйләшә белми!) Телебезне мондый чикләүләр эченә кертү дөрес түгелдер: ана кеше баласына бер бишек җыры гына көйли алырлык итеп өйрәнү, ана телен башлангыч мәктәптә генә уку... Үзебез утырган агачка балта чабу бит бу!

Милләтне саклау – телне саклау ул. 11 ел буе балаларга белемне татар телендә бирәбез дә, чыгарылыш имтиханнарын рус телендә тапшырырга мәҗбүр итәбез. Бердәм дәүләт имтиханын кертү – милли хокукларыбызны бозу ул. 309 нчы маддәне гамәлдән юкка чыгару җәһәтеннән федераль үзәк белән аңлашу табарга кирәк...

Чыгышы ахырында Камәрия ханым бик гыйбрәтле бер тарих сөйләде.

...Рәсүл Гамзатовның бер танышының улы сугыш вакытында хәбәрсез югала. Ана кеше бу хәсрәттән башына кара шәл ябына... Туплар тынгач, күп гомерләр узгач, Рәсүл ага чит илләрнең берсендә йөргәндә әлеге ананың улын очрата. Кайткач, анага әйтә:

– Кара шәлеңне сал инде, улыңны таптым! – ди.

Ана кара шәлен сала һәм шунда ук сорау бирә:

– Телен онытмаганмы?

– Оныткан... Без аның белән тәрҗемәче аша аңлаштык, – ди әдип.

Ана кара шәлен кабат ябына. Бу юлы инде гомерлеккә...

PRESSA.RU

лар. 1956 ел бу, миңа бу вакытта 13 яшь. Барысын да хәтерлим... Өебезне, үземнең бүлмәмне... Әмма Кытайга кабат барганым юк. Теләмим дә... Күңелемдә барысы да элеккегечә калсын, шулай саклансын...

Башка илдә, башка мәмләкәттә тормышны өр-яңадан башлау бервакытта да җиңел түгел. Кайда кемнең танышы, туганы бар – Кытайдан Төркиягә күченгән татарлар ул чакта шунда барып урнаша: беренче мәлдә кемгәдер сыенмыйча, таянмыйча булмый бит. Нурия апаның гаиләсе Әнкара шәһәрендә төпләнә. Урта мәктәпне ул шушында тәмамлый. Төрек телен өйрәнә. Әмма татарлар ул чакта күбрәк үзара гына аралашалар, төрекләр белән гаилә корулар соңрак башлана. Бер-берсенә кунакка йөриләр, бәйрәмнәргә бергә җыелалар.

Булачак ире Зыя белән дә Нурия татар туенда таныша. Зыяның әби-бабайлары шулай ук Пенза мишәрләре. Ул үзе Япониядә туып-үскән. Әнисе Таһирә, өлкәнәйгәч, Төркиягә үз татарлары янына күченгән, ә Зыя анда эшләп калган. Аның Әнкарага әнисенең хәлен белергә килгән чагы. Егет шулай уйлый. Күкләрдә укылган никахы артыннан килүен ул әле кайдан белсен?!

«Татар тарихын укыйм да, алар анда ничек торалар икән, дип уйлый идем».

Барысы да бик тиз була. Кияүгә чыгып, ире белән Япониягә, Окинавага китеп баруын сизми дә кала Нурия. Гомеренең татарлардан аерылыбрак торган чоры бу аның. Япониядә ире яшәгән җирдә милләттәшләребез булмый. Зыя Американга караган оешмада эшли, аралашкан кешеләре дә күбрәк американнар. Хәер, яшь хатынның кулында сабый бала, аның әле башка мәшәкатьләр, башка гамьнәр белән яшәгән вакыты. Шуңа да, үзе белгән телләрне санаганда, япон телен кертми ул. «Зыя японча белә иде, ә минем аралашырга япон танышларым булмады, сөйләшерлек итеп өйрәнә алмадым», – ди. (Сүз уңаеннан. «Дусларым арасында татарлар да, руслар да, төрекләр дә, инглизләр дә бар. Кем белән сөйләшәм – шул телдә уйлыйм: башымда тәрҗемә итеп тормыйм», – ди Нурия апа.)

Улларына 9 яшь вакытта Килкиләр гаиләсе Америкага, Сан-Франциско шәһәренә күченә. Орхан инде анда үсә. Яшәгән илләр, җирләр үзгәрсә дә, гаилә эчендәге тәртип шул ук кала: өй бусагасын атлап, эчкә узуга алар барысы да татарча сөйләшә башлыйлар. Табынга да татар аш-сулары гына килә. Өйдә татар җырлары гына яңгырый.

– Без Сан-Францискога башка татарлардан позднарак күчендек. Аптырамагыз, без өйдә, Пенза мишәрләре кебек, шулай «позднарак» дип сөйләшәбез... Татарларны сагынган идем инде. Әнкарада бергә үскән дусларым да шушында. Шунда ук татар оешмасы эшенә кушылып киттек. Сан-Францискода аның оешуына 60 ел инде. Җыела торган бинабыз да бар. Зур түгел, йөз генә кеше сыя. Татарлар аны үз куллары белән салган. Шул бинаны тоту өчен татар ризыклары пешереп сатабыз. Без анда күп түгел, 250 ләп кеше генә. Татарстаннан килгән яшьләр дә кушылып тора. Безнең белән – татарча, үзара урысча сөйләшәләр, шуңа азрак эчебез поша... Дөрес, безнең яшьләр дә, җитди сөйләшү булганда, инглизчәгә күчәләр. Татарчалары җитми. Үзара да күбрәк инглизчә аралашалар. Башка милләтләргә кияүгә чыгу, өйләнүләр дә ешрак хәзер. Үземнең дә киленем инглиз кызы...

Ел саен Сабантуй оештырабыз, бәйрәмнәрне, туган көннәрне бергә үткәрәбез. Җыелып лото уйныйбыз. Зәкят акчаларын Казанга китерәбез, мондагы ятимханәләргә. Бу эш белән Оркыя ханым Сафа шөгыльләнә...

Моннан унҗиде ел элек Нурия апа тол калган. Кияве Зыяга инсульт булгач, Төркиядән аны карашырга әнисе килгән дә, кире китмәгән инде: кызын ялгыз калдырырга теләмәгән. Менә 20 ел инде алар бергә яшиләр. Сәгадәт апага бүген 99 яшь икән! Үз аңында, зиһенендә, ди. Телевизор карый, инглизчә тапшырулар тыңлый, русча газеталар укый, аннан кулына Коръән китабын алып, догалар укый икән.

– Мин Американың кием-салым, косметика сата торган иң зур, иң бәяле кибетендә эшләдем. Авыр булса да, эшем кызык иде. Инде менә пенсиядә. Буш вакытым шактый хәзер. Иртәнге төрек хәбәрләре тыңлаудан башлыйм – төрек теле дә бик якын миңа. Еш кына интернеттан төрек кинолары карыйм. Инглизчә фильмнар да ошый. Һәр кич исә «Комсомольская правда»ны укыйм. Кириллица таныш булгач, «Сөембикә»не уку да авыр түгел миңа – журналыгызның кайбер саннары Америкага да килеп ирешә.

Казанны күптән күрәсем килә иде. Әмма әнине багасы бар бит, аны калдырып китә алмадым. Хасталыклары да булды. Хәзер хәле яхшырак чак әле. Килүемне ул бик-бик теләде. «Бар, Нурия, – ди. – Миңа ул-бу булса, син янымда торсаң да була, тормасаң да... Аннан картаерсың, йөри алмый башларсың». Миңа да 74 бит инде... Дус хатыныма барысын да әзерләп калдырдым: кәфенлеген, сәдакаларын... Багарга бер хатын таптым. Телефоннан сөйләшеп торабыз, әнинең хәлләре әйбәт, иншалла, мине исән-имин каршы алыр...

Мин күз алдына китергәннән матуррак Казан. Безнең Сан-Францискодан да матуррак! Исем китте! Болай дип уйламый идем...

Бик яраттым!

Нурия апа Килки яшәгән җирләренә бердәнбер теләк белән кайтып китте: инде Казанны улы Орханга күрсәтәсе килә аның. Насыйп булсын!



ЕНИКЕЕВ Илнур. Әстерхан

Казан дәүләт мәдәният һәм сәнгать университеты, Казан социаль һәм гуманитар белем бирү институты

Өйләнгән

Карьера: җырчы

Тормыш шигаре: «Теләк-омтылышлар чынга ашмас дип, беркайчан да курыкмаска! Кыю булырга, алга барырга. Берни дә эшләмәсәң, берни дә үзгәрмәячәк...»

https://www.facebook.com/suyumbike.zhurnaly

Хыялым шәһәрендә яшим

Рухи мәркәзебез – Казанга күчеп килүем, биредә Россиянең һәм Татарстанның халык артисткасы Венера Ганиева белән танышуым, аның шәкерте булып китүем тормышымны бөтенләйгә үзгәртте. Хәзер мин сәнгать, музыка дөньясында яшим. Һәр яңа көн шушы дөньяда барган яңалыклар белән баеп, күңелдә кабатланмас тәэссоратлар калдыра. Шушы Казанда кайнавым белән бик бәхетле мин. Үземне бер бик тә игелекле зур эшкә өлеш кертүче кебек хис итәм.


Якташларның сөенече – минеке дә


Быел Әстерхан шәһәрендәге Александр-Мария дәваханәсенең нейрохирургия бүлегенә умыртка баганасына катлаулы операцияләр ясый торган – пациентка авырлык китермичә диярлек, кирәк урынны гына «өшетеп» ясый торган бик тә кыйммәтле аппарат кайтарганнар. Әле бер ел элек кенә авырулар операциягә көтеп айлар буе чират торалар иде. Моңа бик күп чыгымнар тотылып, операциядән соң да аякка басу өчен озак вакыт кирәк була иде. Хәзер исә аны медицина полисы буенча бушлай һәм тиз арада ясатып була. Йөзләрчә кешенең гомерен озайту дигән сүз бу.

Таш атканга – аш белән

Таиландның Пхетчхабури провинциясендәге бер авыл хуҗалыгы кооперативында кыргый филләр, диварны җимереп кереп, фермерларның әзерләп куйган дурианнарын ашаган. Кооперативның менеджеры Прасерт Канчанаванит сүзләренә караганда, филләр кырыкка якын дуриан ашаган, диварны җимергән, кондиционерны ваткан. Имештер, алар моны белеп эшли, диләр кооперативта. Аңа кадәр дә филләрнең, йөк машиналарын туктатып, җимешләрне ашаган очраклар булгалаган. Шунысы аяныч: әлеге складта ремонт төгәлләнгән генә булган. Шулай да тайландлылар филләргә карата зыян салмаган. Менә нинди кече күңелле халык!


сөендерде 




көендерде 


сөендерде 



көендерде 

сөендерде 



көендерде 

«Нәселеңә лаек бул!» – дип әйтә иде...

Гаиләбезнең тереге – әтием Ринат Рәфикъ улы Еникеев 58 яшендә гүр иясе булды. Ул гомере буе Эчке эшләр министрлыгында эшләде. Мине дә дөрес итеп тәрбияләде, хәрбиләрчә тәртипкә өйрәтте. Аңардан кешенең кадерен белергә, ихтирам итәргә өйрәндем. Әти аңлый һәм кирәк вакытта акыллы киңәше белән ярдәм итә белә иде. «Без – Уфа якларыннан, морзалар нәселеннән», – дип әйтә иде һәм шуңа лаек булырга тиешлегемне дә аңлата иде. Хәзер исә әтием мине бакыйлыктан күзәтеп торадыр, уңышларыма сөенәдер шикелле.

Гаделсезлек тантана итте

Җәй башында 6 яшьлек Алексей Шимконың, имештер, исерек килеш Ольга Алисованың машинасы астында калып һәлак булуы турындагы хәбәр мине генә түгел, бөтен ил халкын «аһ» иттерде. Имеш, бу малайның канында 2,7 промилле аракы барлыгы ачыкланган. Экспертизага ышансаң, бала бер шешә аракы эчеп бетергән булып чыга бит! Акча һәм хакимият аркасында, кайбер элементлар безне «исерек» балалар «тәрбияле, гадел» Алисоваларның автомобиль тәгәрмәче астына ташлана торган илдә яшәргә мәҗбүр итә. Моңа бер дә түзеп торасы килми.

Көн туса – яңа террор

Быел җәй башыннан ахырына кадәр дөньяның әле бер, әле икенче ноктасында, бигрәк тә Европаның зур шәһәрләрендә бер-бер артлы терактлар булып торды. Бу хәлләр теракттан еракта булган кешеләрнең күңеленә дә курку һәм бер үк вакытта борчу сала. Теракт турындагы хәбәрләр килүгә берьюлы ике хис кичерәсең: кызгану һәм нәфрәт. Аларны оештыручылар артында зур кешеләр торуы сер түгел һәм шуларның пычрак уеннары аркасында гади халык даими куркып яшәргә мәҗбүр. Күрәсең, теракт оештыручыларның да максаты – шул.

PRESSA.RU



КАЮМ БАБАЙ «МӘГАРӘСЕ»



Лилия ГӘРӘЕВА

СЕЗНЕҢ ГӨБЕДӘ МАЙ АТЛАП КАРАГАНЫГЫЗ БАРМЫ? Ә БӘЛӘК БЕЛӘН КЕР ТӘГӘРӘТКӘНЕГЕЗ? МИЧТӘ ПЕШКӘН КОЙМАК БЕЛӘН КАЙЧАН СЫЙЛАНГАН ИДЕГЕЗ?

Менә безнең дә бу эшләрнең берсен дә эшләп караганыбыз юк иде. Гөбеләр күптән инде чормада, киле, бәләкләр дә... Балачакта иңнән төшмәгән көянтә-чиләгенә кадәр музей экспонатына әверелә бара. Мичтә пешкән коймак тәме дә сагындырган, дидек тә... авылга кузгалдык.

Нәрсә әйтәсегезне чамалыйм: «Андый авылны кайдан табарсыз икән?» – дисез. Ә без ике гасырга чигенергә уйлыйбыз. «Вакыт машинасы»на утырабыз да... Шаяртам, билгеле. Андый машина юк, ә менә бу эшләрне үз кулларың белән эшләп карау мөмкинлеге бирә торган җир бар. Һәм андый җир Казаннан әллә ни ерак та түгел – Яшел Үзән районының Олы Ачасыр авылында гына.

Сәяхәтебез музейга – Каюм Насыйри исемендәге архитектура һәм этнография музей комплексына. Ләкин экспонатларын пыяла аша гына карап йөри торган гадәти музей түгел бу. Бөтен нәрсәне тотып, сынап, хәтта авыз итеп тә карарга була торганы. «Андый музей да буламы?» – диярсез. Менә бит, бар икән.

Шушы урында бер тайпылыш ясарга кирәк: әдип үзе Олы Ачасырда тумаган да, яшәмәгән дә. Аның туган авылы Олы Шырдан моннан алты чакрым ераклыкта. Шуңа да бу – Каюм Насыйри музее түгел, әдипнең исемен генә йөртә. Әмма дә ләкин кара-каршы ике яклы өй, ихатасында борынгы келәтләре, базлары, лапас, сарайлары булган бу йортны Каюм Насыйрига бөтенләй үк нисбәтсез дип тә булмый. Әдипнең туган нигезендә, энесенең улы Габдрахман Хөсәенов төзегән йорт ул. 1947 елда аны Габделгани Минзарипов дигән кеше шушында күчереп сала. Йорт белән бергә бик күп борынгы әйберләр: яңгыратып суга торган герле сәгатьләр, Каюм Насыйри үз куллары белән ясаган борынгы көзгеләр, аның кул җылысын саклаган савыт-саба шкафы, ул ясаган кәнәфи, көнкүреш кирәк-ярагы, эш кораллары да күчә. Габдрахман Хөсәенов борынгы әйберләрнең кыйммәтен аңлый торган кеше була, үзенең вафатыннан соң йортының музей булуын тели. 1997 елның 1 мартында музей беренче кунакларны кабул итә.

...XXI гасырдан XIX гасырга кайту өчен бизәкле капканың келәсенә генә басасы. XIX гасыр ахыры – XX гасыр башында яшәгән урта хәлле татар крестьяныының тормыш-көнкүрешен чагылдыручы утар... Яшел чирәмле зур ишегалды. Келәт, абзар, баз... Лапас астында арба-чана шәйләнә. Менә-менә келәт ишеге ачылыр да, кулындагы коштабакка түбәләмә итеп он тутырган ак яулыклы, чигүле алъяпкычлы җитү кыз килеп чыгар сыман. Дөрестән дә, каршыбызга чуар күлмәк өстеннән чигүле алъяпкыч япкан кызлар – музей хезмәткәрләре атлый. Дүртәү алар. Кулларында – чәкчәк. Безгә, боларны гел күреп яшәгән кешеләргә гадәти кебек күренсә дә, Мәскәү, Германия, Америкадан килгән кунакларга бу бик гаҗәп тоеладыр. Алар өчен монда бар да экзотикадыр.

Музейның мөдире Гатиятуллина Рәзинә фаразыбызның дөреслеген раслый. Үз гомерендә тере тавык та күрмәгән, авыл һавасы иснәмәгән, бәрәңгенең ничек үскәнен белмәгән кешеләр дә килә икән бирегә. Өйгә узып, экскурсовод: «Менә монысы хатыннар ягы булган, монысы ирләр ягы», – дип, элеккеге татар тормышы белән таныштырганда ниндирәк хисләр кичерә икән ул ханым-әфәнделәр? Чигүле борынгы чаршаулар, тәрәзә









Фото: Ксения Богданова

PRESSA.RU



пәрдәләре, кызыл башлы сөлгеләр, кулдан тукылган паласлар, чигүле мендәр-ястыклар түшәлгән сәке, ялтыратып агартылган самавырлар аларга да матур күренә микән? Күренәдер. Шулай булмаса, туристларны җәлеп итү белән мәшгуль фирмалар инде менә ничә еллар бу музейны үзләренең экскурсия маршрутына кертмәсләр иде. Монда аларга бар да кызык, яңа, ят. Тагын кайсы музейда әле кунаклар килешкә самавыр куеп, коймак изеп торалар икән? Хәтта мунча да ягылган! Музей эшләү дәверендә юынып чыгарга теләүчесе генә булмаса да, мунча ишеген ачуга, биткә кайнар пар бөркелсә, күңелле дип, һәр кунакка мунча өлгергән була.

Аһ-ваһ килеп, йорт, ихатадагы абзар-кура, бакчалар белән танышканнан соң, тигәндә – кәбестә, киледә кипкән алмалар төеп, бәләк белән кер тәгәрәткәннән, кул тегермәнендә он тартканнан соң, кунакларны чәй табынына дәшәләр. Стенага киптерергә элгән бәйләм-бәйләм дару үләннәре: мәтрүшкәнең сарысы, зәңгәре, әрем, гөлбадран, юкә чәчәге исләренә хушланып, җырлап торган күмер самавырыннан шифалы чәй эчү, мич коймагы, татар чәкчәге, авыл катыгы белән сыйлану, әй, ошый да икән соң үзләренә! Ошамас инде, мичтә үзләре пешергән коймаклар бит ул! Табагачны кулларына алгач, әйләндерә-әйләндерә тикшерәләр икән. Кемдер җәһәт кенә каптырып ала, кемнеңдер коймагы табасы-ние белән учакка капланып төшә. Үлән чәйләре дә күңелләренә бик хуш кунакларның. Каюм Насыйриның дару үләннәрен өйрәнеп язган «Хәвасе нәбатат» китабына нигезләнеп, музей хезмәткәрләре үзләре җыя аларны. Туристларга үзенә күрә кечкенә генә бер күчтәнәч әзерлиләр шулай.

Утарда туристларга күрсәтә торган тагын бер кызыклы урын бар – кияү келәте. Ярма бүрәнәләрдән бурап салган, аулак, ышык урын ул. Авыл кешесе монда ашлыгын, онын, он үлчәргә бизмәнен-герен, тубалын-иләген саклаган. Келәтнең тагын бер вазыйфасы булган әле, кызы җитеп, кияүгә бирер вакыт җиткәч, никахтан соң монда кияү келәте әзерләгәннәр. Каюм Насыйриның «Сайланма әсәрләре»ндә (3 нче т., 248–249 нче битләр) кияү келәте турында болай диелә: «Ул бүлмәгә кияү урыны ясыйлар: карават, ул караватка ике кат түшәк җәяләр, мамык түшәк була, ефәк юрган, вә ефәк материядән яки нәфис ситсыдан ул караватка чаршау. Кияү керәсе кичне ул бүлмәне бик нәфис итеп җыялар...» Халкыбызның бу борынгы йоласы хакында Гомәр Бәшировның «Туган ягым яшел бишек» әсәрендә дә бик матур итеп тасвирлана. Әле балаларның кияүне тиз генә кыз катына кертмичә, ишек бавы сораганнары безнең заманнарга кадәр килеп җиткән: «Ишек бавы – бер алтын, безнең апа – мең алтын...»

Кияү келәте дигәннән, без килгән көнне Олы Ачасырның иң өлкән кешесе – Гөлмөнәвәрә апа Яруллиналарда Коръән мәҗлесе иде. Насыйп булса, киләсе елга 100 яшь тула икән үзенә. Гөлмөнәвәрә апа кызык ул, һәр соравыбызга җавабы бер: «Онытканмын инде, балалар». Алай да кеше үзенең туен хәтерләмиме соң! Август аенда үз авылларына ук килен булып төшә ул.

Ул чорда кияү келәтләре булмый инде, билгеле. Никахтан соң, кайнана-кайнаталар яшьләрнең үзләрен генә калдырып, күрше-күләнгә таралыша. Гөлмөнәвәрә апа онытканнарны Тәзкирә, Мәдинә апалар хәтерләрендә яңарта. «Элек, дөрестән дә, бай кешеләрнең андый келәтләре булган ул, – дип искә ала Тәзкирә апа Шәйхуллина. – Мин менә 1977 елда килен булып төштем. Безнең чорга андый келәтләр калмаган иде инде. Никахтан соң төнге якка өйдәге бөтен кеше таралып бетә, икенче көнне генә кайталар. Өй әһелләре өч көн шулай кешедә кунып йөриләр әле. Безнең якта туйга кадәр «Иҗәбе кабул» дигән нәрсә үткәрәләр. Кияү белән кәләшне бер тактага бастырып, бергә тормыш көтәргә ризалыкларын сорыйлар. Аннары, туйлар узгач, Коръән мәҗлесе үткәрәләр. Аны безнең якта «Кайтара алу», диләр. Туйда булган үпкәләр, начарлыклар бар да юкка чыксын дип үткәрелә ул».



Ачасырда Каюм Насыйри исемендәге музей гына түгел, әдипнең борынгы бабасының исемен йөрткән чишмә дә бар әле. Тау битеннән көнгә карап типкән бу чишмәне халык Бәйрәш чишмәсе дип атый. Миңнуллин Әнвәр дигән кеше аңа яңа улак куйдырып, зур итеп бурасын бураткан. Музейны күрергә килгән туристлар бу чишмәне дә күрми китми. Яшь киленнәргә су юлын күрсәтер өчен дә шушы чишмәгә алып төшәләр. Музей хезмәткәрләре чишмә йортын, улакларын ел саен юып, тирә-юненә чәчәкләр утыртып – карап-тәрбияләп торалар икән. «Чишмә суын авыз иткәндә, суга үлән бөртеге агызыгыз, – дип өйрәтә безне Рәзинә ханым. – Йоласы шундый безнең якта».

Каюм Насыйриның «Әбугалисина»сында геройлар гыйлем мәгарәсендә була. Ачасырдагы борынгы татар утары да Әбугалисина ятлап алырлык гореф-гадәт кануннары, йолалар саклана торган гаҗәеп мәгарә икән.









PRESSA.RU



Гөлүсә БАТТАЛОВА

Гөлүсә Батталованың «Бер йотым бәхет» китабы шигърият сөючеләр өчен чын бәйрәм ясады бу җәйдә! Шулай булмыйни! Газета-журнал битләрендә күренеп-күренеп киткән шигырьләрен болай да яратып кабул итәләр иде бит инде! Аны Марсель Галиев «фидаи рухлы кызый» дип атады. «Аның өчен вакыт чикләре юк, шигъри аргамагы үткәнне, бүгенгене, киләчәкне юргалап җилкенә. Тояк эзләрендә сүз энҗеләре балкый. Елата да, юата да, ачындыра да, очындыра да...» «Ул эчке кичерешләр сәркатибе генә түгел, ул инде шигырьләренә диагноз сыйфаты бирә белүче җитлеккән язучы». Монысы – Ренат Харис сүзләре.
Татар халкының шигъри бишеге булган Казан артында – Әтнә районы Түбән Шашы авылында туган, Татар дәүләт гуманитар институтының чит телләр факультетын тәмамлаган, туган ягы Күәмдә ире Алмаз белән кыз-уллар үстереп ятучы Гөлүсәбез менә шундый шагыйрә!

МИН СИНЕҢ ТӨШЕҢӘ КЕРЕРМЕН...

* * *

«Аңла, – дидең, –
мин яратып китәм...»
«Яратмыйм» дип әйткән булсаңчы...
Мин – мәңгегә синең сөюеңнең
Буранында калган юлаучы...

Сөю тынын изге сүрә итеп,
Бәгыремә яздым канатып.
Җилләр, ахры, әфсен пышылдаган –
Мәхәббәттән киттең яратып...

Юхаланды шул ук әрсез җилләр,
Кабат-кабат җанны агулап.
Ике ярда өнсез сагышларның
Кайтавазы йөрде чабулап.

Мең талкынды кебек үксез бәгырь,
Шәфәкъларның төсе уңганчы...
Әрнүләрдән торган соңгы догам –
«Яратмыйм» дип әйткән булсаңчы!..

* * *

Мин синең шәүләңә әйләнмәм,
Ялынмам, ялвармам, кил диеп.
Үзгәң өзелгәч кайтырсың,
Җилләргә җилкәннәр киереп.

Мин синең бәхетең булалмам –
Кар эреп югалган эзләрең.
Киек каз юлында кайтаваз –
Әрәмгә түгелгән хисләрем.

Мин синең төшеңә керермен
Бөреләр тулышкан таңнарда.
Кан тамган ярамны әрнетеп
Омтылма җанымны аңларга.

Мин синең дөньяңа табынмам,
Газизрәк, якынрак үз күгем.
Хушлашыйк. Мәңгегә. Күп нокта.
Күз яшьсез тын гына үкседем...

* * *

Җан ярамның әрнеп сызлаганын,
Үтеп киттең, нигә сизмәдең?
Эзләреңне кочып елар булдым –
Мин һаман да синнән бизмәдем.

Сагышларым инде чиктән ашты...
Яңгыр явып, юллар өзелгән...
Күзләр талды – белмим,
ни эзлим соң,
Торналарның киткән эзеннән?

Күкнең төбе тишелгәндер, ахры –
Күзләр аңлый минем хәлемне.
Мәхәббәттән соңгы ядкарь итеп
Түргә элдем ачы әремне.

Сары яфрак минем җаным төсле –
Үрелдем дә, җәлләп өзмәдем.
Эзләреңә ятып мең үкседем...
Ярый әле үзең сизмәдең...

* * *

Син кайтырга вәгъдә биргән идең,
Таң чыгыннан күзләр дымлангач.
Тиле дигән тамга суктым җанга –
Күз алдында гәүдәң сынлангач.

Син сөяргә вәгъдә биргән идең,
Шәфәкъ кызыллыгы сүнгәнче.
Мәхәббәттән җан бирүең артык,
Сарыларга сабып үлгәнче.

Син калырга вәгъдә биргән идең,
Бәхетемнең карап күзенә.
Акыл инде сине көтеп арды,
Йөрәк кенә нидер сизенә.

Син кайтырга вәгъдә биргән идең –
Араларда янган күперләр.
Буш вәгъдәдән җылы тапмый сүнде
Мәхәббәттән калган күмерләр.

* * *

Ачы таңнан кырга чыгып чаптык!
Өлгергәндер дисәк арышлар –
Ашыкканбыз. Җилдәй җитез җанны
Гафу итмәс, ахры, язмышлар.

Җилләнергә дидек, бер туйганчы!
Чын яшеңне онытып беразга!
Галәм киңлегендә ник очмаска –
Риза түгел йөрәк бик азга.

Сабыйлыкта калган бу күңелләр
Тәгәрәде үрдән үзәнгә...
Шаянлыкны аңламады язмыш,
Гөнаһ диеп салды бизмәнгә.

Яшь аралаш елмайгандай иттек,
Кемгә кирәк безнең елаулар?!
Күктән җиргә ыргыткан күк булды
Баш очында торган сораулар.

Җайдакмы без гомер атларында?
Колдамы соң тәкъдир тезгене?
Аерырга өйрәттеме тормыш
Гөнаһлыны, савап, изгене?

Тез астына китереп сукса заман,
Җүләрлектән кемгә, ни файда?
Таң алдыннан бәхилләшеп кайттык.
Яшьлек белән. Чыклы тугайда.

Чәчләр иртә агарганга бары
Гаепләме икән язмышлар?
Кыр ягына карап уйлап куйдым:
Өлгергәндер инде арышлар...

* * *

Синнән миңа кул сузымы ара,
Миннән сиңа бары бер адым.
Мин язмыштан очрашулар түгел,
Онытырлык дәрман сорадым.

Карлы кичтә, бары бер адымда
Бәхет белән яшьлек хушлашты.
Мәхәббәттән калган күләгәләр
Җилләр кочагында адашты.

Кул сузымы ара ераклашты –
Ерагайды синең буй-сының.
Эреп барган шәүлә җылытмас шул
Керфекләрнең бәсле тоҗымын.

Синнән миңа – еллар чакрымнары,
Ул юлларны, белмим, кем үтәр?
Елый-елый сөюеннән качкан
Җирдә күптер безнең кебекләр.

Ходайга сорау

Син яралткан Адәмнәрме соң без?
Безнең үзәк үзле балчыкмы?
Хәтер җуйдык. Җиргә ник килгәнне
Уйлап тормый уйлар талчыкты.

Богъдай агачын да ботарладык.
Күптән инде. Моннан биш былтыр...
Ә Тәкъдире... безнең кулда аның –
Кемгә – дәрья. Кемгә – шымытыр.

Фәрештәләр куып таратылды –
Артык кашык сыймас казанга.
Дөнья малын әрдәнәләп өйдек
Ахирәткә илтер ызанга.

Син яралткан Адәмнәрме соң без?
Гидайлармы әллә адашкан?
Мәхшәр мәйданында берәү йөри
Иман эзләп сыңар караштан.

Ватанында Пәйгамбәрләр булмый –
Табындырса купшы әләмнәр.
Шайтан ыруында табан ялый
Син яралткан садә адәмнәр...

* * *

Әйа, агач, яшең күпме?
Түгелгән җимешең күкме?
Г. Кандалый.

Нигез ташында уйга оеган
Бөкрәеп беткән йөзьяшәр карчык.
Җанның җелеген суыра җилләр –
Йөрәк үзе дә укмашкан ярчык.

Йөзең ак булса, җыерчык – бизәк.
Сөякләр түгел, бәгырьләр каткан...
Чуерташ булып чәчелер төсле
Сукбай давыллар екса аяктан.

Нигез ташында уйга оеган –
Күңеле – каба, хәтере – орчык...
Дөнья гаменнән бизмәгәндер лә
Акылын җуйган йөзьяшәр карчык!..

Дәвер дисбесе уйга уралган,
Табалмас, ахры, рухташ игезен...
Өрфия җанлы йөзьяшәр карчык –
Таныдым үзен...
Ул бит... мин үзем...

* * *

Син – көчле бит, диләр. Ә мин менә
Кабыгыма кереп бикләндем.
Нәзберек җан хәлсез гәүдәм булып,
Аратасын куйды чикләрнең.

Җебегән, дип, яңаклады берәү,
Башны иеп тордым, дәшмәдем.
Иңнәремдә адәм күтәрәлмәс
Йөгем барда кирәк яшьләрем...

Хисләрендә – пафос, диде кемдер,
Ышанмады ихлас йөрәккә...
Ясалмалык минем сүрү түгел,
Хакыйкате үткән үзәккә.

Җансыз, диеп, җанны ашадылар,
Безгәме соң каты бәгырьлек!..
Дөнья үзе – тере гәүдәләрне
Үле җаннар баскан каберлек...

Яши белмим, ахры, кысаларда –
Ызаннары күптән җимерек.
Күндәмлеккә ант эчкәндә генә
Баш калкытып куя кирелек.

Җайсыз адәм, диеп, һич булмаса,
Җиз иләккә салып иләгез!
Мең юньсезлек аша исән калган
Татарлыкка ләкин тимәгез!

* * *

«...туган җирем, кан яңартып яткан
элекке авылым, хуш!»
М. Мәһдиев «Бәхилләшү»

Ап-ак яулык... Яшел болын...
Үткәннәрдән саркый сагыш...
Безниләрне васыять иттек?
Кайдан килдек? Кая барыш?!

Ак алъяпкыч... Яшел болын...
Беркатлырак ихлас җаннар...
Яшен булып яшьнәгәнбез –
Бүген – утсыз аҗаганнар...

Ак тукыма. Милли чүәк.
Йөз аклыгы – чиккән бизәк.
Ник югалды шушы сурәт –
Йокты әллә яман бизгәк?

Гамьсез уйлар. Гамьле караш –
Дөнья әле күчәрендә.
Инде зәгыйфь тамырларда
Яшәү булган... Кичә генә...

Ә бүген без никтер сүлпән...
Соң кемнәрдән, нәрсә даулыйк –
Сагынмаклык булып калгач
Ак алъяпкыч, ап-ак яулык?!.

Ап-ак яулык... Яшел болын...
Үткәннәрдән саркый сагыш...
Буш хыяллар – чакрым-чакрым,
Кылган гамәл бары карыш...

Тарих ялы – күн дилбегә –
Яшим дисәң, ныклапябыш!
Тик әлегә җансыз юлдан
Җәяү генә атлап барыш...

PRESSA.RU

Рифә Рахман иҗаты укучыларда һәрчак кызыксыну уята. Шигърият, проза, драматургия, журналистика, әдәбият фәне – һәркайсында үз урыны, үз исеме аның. Хикәяләрен аеруча яраталар. Чөнки аларда – көтелмәгән сюжетлар, үзенчәлекле чишелешкә ия конфликтлар, күңелгә уелып калырлык образлар. Сизгер күңеле белән хис-кичерешләрне оста итеп тасвирлап биргән «Күзләре соп-соры» хикәясен хатын-кызлар, мөгаен, яратып кабул итәр: әсәр героеның холкы, гадәтләре күбесенә хас бит. Ә без Рифә ханымны күркәм юбилее белән котлыйбыз! Илһамлы сәгатьләр, иҗат уңышлары телибез!


Рифә РАХМАН

КҮЗЛӘРЕ СОП-СОРЫ…

(Хикәя)

Ишекне ябар өчен сумкамнан ачкыч эзләгәндә, телефон шалтырады. Ачкычны аласы урынга, аңа үрелдем. Ят номер. Исеме юк. Бер-бер эш кушыптыр инде, ичмасам, ял көнемдә дә тынычлыкта калдырмыйлар, дип, капкачлаган идем дә, ниндидер сәер көч яңадан ачарга һәм минем белән сөйләшергә теләүчене ачыкларга мәҗбүр итте.

– Алло, алло!

– Әйе.

– Исәнме!

– Бер көе.

– Нишләп алай ачулы?

– Һич юк. Тыңлыйм Сезне.

– Сезнең диган булып кыланма инде! Алайса мин дә Сезгә күчәм. Барасызмы?

– Барабыз.

Улым белән, бу ялны теплоходта уздырырбыз дип, ай буе планнар корсак та, һичкемгә әйтмәгән идек. Ул, сәяхәткә әзерләнгәнемне сәгать буе өйдә көтеп аргач, тәмам туеп, ишегалдына чыгып китте. Кием дә озаграк сайланды, гомер булмаганча ни вакыт бизәнү өстәле артында утырдым. Көтә-көтә көтек булгандыр инде.

Телефонны колакка куйган килеш кенә коридор тәрәзәсе янына килдем. Әнвәр тирәк астындагы утыргычта күршеләрнең мәче баласы белән уйнап утыра. Иптәшләре барысы туп тибә. Пычранмыйм дигәндер инде: уенга кушылмаган. Җитмәсә, телефоннан сөйләшеп, аның көтүен тагын да озынайтам. Сумкамны телефонлы кулымның беләгенә элдем дә тәртипсез салынган кәгазьләр арасыннан ачкыч эзли башладым. Әллә ачкычлар элгечендә калган инде? Монысы гел сумка кесәсендә йөри иде. Помада бар, тарак бар, билетлар салынган… Ачкыч дигәне дә шунда булырга тиеш тә бит. Ярар, кереп, икенчесен генә алырмын.

Бер колагың телефонны тыңлаганда ачкыч табарлыкмыни? Йә, ни дип сорый тагын?

– Икегез дәме?

– Икебез дә.

– Алайса без дә икәү киләбез.

– Ярар.

Шулай дип әйттем дә, ризалык биреп ташлавыма үзем дә аптырап киттем. Кемнәр ул –

«икебез»? Нигә икәү? Нигә «алайса икебез»? Иптәш кызым белән берәр җиргә бара дип уйлыйммы әллә бу кеше? Парлашыр һәм минем белән генә калыр өчен, дус егетен дә сәяхәткә алмакчы, ахирием белән таныштырмакчымы?

Каушабрак:

– Кем белән? – дип сорадым. – Белергә ярыйдыр бит: кем белән?

– Кызым белән.

– Ке-е-м?

– Кызым.

– Фу! Башта кот очкан иде. Алай икән... Яхшы, – дип кенә әйтә алдым.

Бер таныш түгел кеше белән нигә дип аның сүз уңаена сөйләшеп торам? Кем икәнлеген сорарга да... Юк, сорамаска! Әле сөйләшергә вакыт бар. Гомеремдә беренче тапкыр эш буенча шалтыратмаган ир-атның бәрхет тавышыннан колагын рәхәтләндерсен әле. Кемлеген белмәвемнән дә уңайсыз. Кешеләрнең исемен, тавышын хәтерли алмаганга, болай да телефоннан сак сөйләшәм мин, кирәкмәгән сүз ычкындырып куюың бар.

Кызым белән... Ни дигәнне аңлата ала соң бу сүзләр? Йөргән кызымы? Үзенекеме? Әллә дуслары – кызлар затыннанмы?

– Андый җавап көтмәгән идем. Яхшы сүзегезгә рәхмәт! Хәзер җилдерәбез алайса!

Нәрсәдер әйтергә кирәк иде. Телефонның теге башында еш-еш сулап көткәннәре ишетелә.

– Үзегез генә килсәгез дә ярый да бит... Хәер, аермасы юк, – дигән булдым.

– Аны калдыра алмыйм шул. Безгә бер-беребездән башка күңелсез.

– Алай икән... Алайса килеп тормасагыз да ярый!

– Ул чагында сездән башка күңелсез булачак.

Нәрсәгә дип һаман буш сүз куертам? Теләсә нишләсен! Миңа кем ул?.. Трубка капкачын ябам дигәндә, таныш тавыш тагын сүз тапты:

– Бәлки, юл уңаеннан сезне дә әләктереп китәргәдер?

– Җәяү генә дә ун минуттан артмый торган юлга такси чакырту гадәтем юк.

– Ә сез такси түгел, бик тә якын кешем дип уйлагыз.

– Уйладым. Якын кешем.

– Кайсы тукталышта көтик?

– Якын кешегезнеме? Татарстан. Тукайдан соң ук ул. Елга портына бару юлында кала.

– Алайса бер ярты сәгатьтән без «Мерседес»та шунда килеп туктыйбыз, яме. Анда машиналарны штрафка җыйганнарын беләм. Тиз генә арткы утыргычка утырырсыз, озак тукталып тормабыз, китәрбез дә барырбыз.

– Ярар. Җәяү барасы булмаганда, кузгалмый торырга да була икән әле.

Аптырадым. Теплоходта Идел буйлап йөреп кайтырга билет алганлыгымны беркемгә әйткәнем юк. Бу номерны белмим. Тавышы таныш та, таныш та түгел.

Яңадан тәрәзәгә карадым. Әнвәр кемгәдер шалтырата. Әллә мине ашыктырмакчымы? Мин монда, аны онытканкебек, буш сүз куертам.

– Хәзергә сабуллашып торыйкчы, ишек ябасым бар, – дигән булдым да, кызыл кнопкага баскач, яңадан ишек янына килдем. Эзли торгач, каһәр суккан ачкыч табылган иде, әмма бәйләме белән тартып алам дигәндә, пароход билетларын әләктереп ерттым.

Инде пароходка кертерләрме-юкмы? Әллә барып ук тормаскамы? Ялгышлык белән ертылганлыгы күренеп тора. Нигә юкка баш катырам, өзелеп үк төшмәгән ләбаса!

Үзем ачкыч борам, үзем эшсез калган телефонымa Әнвәрнең шалтыратканын көтәм. Юк. Мине җыймый. Әллә кайчан шалтыраган булыр иде инде. Ә кем белән сөйләшмәкче? Әтисенә мактанып аласы килгәнме? Иптәш малайларынамы? Әтисе белән сөйләшмәс, атна башында ук авылга китәсен әйткән иде, аларда Теле-2 тотмый.

Ачкычны йозак тишегеннән тартып алдым да тәрәзәгә килдем. Әнвәремнең кем беләндер нәрсә турындадыр аңлашканы күренде. Әллә әбисенә, әни мине фәлән җиргә алып бара, шуны-шуны күрсәтә дип сөйлиме? Кара, аны да кисәтергә онытканнар. Шалтыратып алыйм дип телефонны яңадан ачкан идем, үзе үк аваз салды. Сискәнеп киттем дә кулымнан төшереп җибәрдем. Капкачлы телефон алма, төшерсәң, ватыла, дип кисәткәннәр иде аны. Инде тагын акча чыгарасы икән...

Алай да яшел кнопкага басам. Эшли! Эшли! Димәк, экранын гына төзәттерәсе. Яңа телефон алу белән бер инде ул. Трубка бераз тын торганнан соң колагыма әле генә бик белеп сөйләшкән кебек тавышның ягымлы итеп:

– Без инде сезне үз турыгызда ук көтәбез, – дигәне ишетелде.

Ничек? Ярты сәгатьтән дигән иде ләбаса. Нәрсәләремә генә ризалаштым?! Өч тукталыш араны, кызу барганда, биш минутта да үтәләр бит алар! Әле теплоход кузгалырга да никадәр вакыт бар! Яр буйларында да ял итәрбез, башкаларның да зур-зур теплоходларда Казан портыннан киткәнен карап торырбыз дип кенә иртәрәк бармакчылар иде.

– Юк, кирәкми, үзебез генә барабыз.

– Әнвәр менә, машина белән яхшырак булыр, диде.

Әнвәр? Аны белгәч, танышым бит инде. Кемлеген чамаламавымны аңламаса гына ярый. Белмәвем белән үпкәләтүем бар. Берәр туган-тумача да булса.

– Әнвәр шулай дигәч, ярар соң, сезнең белән барырбыз. Инде бераз көтәрсез. Хәзер төшеп җитәм.

Тәрәзәгә карыйм. Әнвәр утыргычта юк! Җанфәрманга, үкчәле туфли кигән аякларымны чалыш-чолыш китереп, лифтка утырырга да башыма килмичә, баскычлар буйлап түбәнгә йөгерәм.

Ишекне этеп җибәрүем була, Әнвәргә килеп бәреләм. Уф! Исән! Беркем алып китмәгән! Кочаклап алам да маңгаеннан үбәм. Күздән яшь атыла.

– Аллага шөкер. Исән икәнсең! Урладылармы әллә дип кот очты...

– Мам, ты че?!

PRESSA.RU

– Бирермен сиңа мамыңны, дуңгыз малай, татарча, әни, дип әйт! Утыргычта күрмәгәч, юкка чыктың дип торам!

– Да ну тебя! Әни, ник озак тордың? Көтә-көтә туеп беттем. Әле ярый уйнап утырырга песи баласы булды.

– Үпкәләмә инде, Әнвәрчегем!

– Үзенә Анварчик диергә ярый, ә миңа «мама», дип әйтәсе түгел!

– Балакаем, мин бит Анварчик, димим, Әнвәрчегем, дим.

– Миңа аермасы юк! Бәбәймени мин? Алай итеп малайлар янында әйтмә, яме!

Әйтмәм. Ошамаса, әйтмәм. Бергәләп чыгабыз. Ишекнең теге янында һичкем юк. Улым:

– Кешеләрне дә көттерерсең дип, чакырырга кереп бара идем, – ди. – Китеп үк барганмы әллә? Синең шул булыр инде. Болай да матур икәнлегеңне белә торып, ярты сәгать буена нәрсәгә бизәнеп утырырга иде?..

Нинди ярты сәгать?! Түзәмени ул аңа үзе дә. Әнвәр як-ягына карана. Аптыраштa. Нәрсәгә аптырый соң ул? Нинди кешеләр турында сөйли? Әй, Әнвәр югалды дип, шул арада баштан чыккан: ишек төбендә «Мерседес» көтәргә тиеш иде бит безне! Үзем дә аны машинада килүчеләр алып киттеме әллә дип курыктым түгелме соң?!

– Әнвәр! Син безне кемдер көткәнне каян беләсең? Мин бит әле бу хакта сиңа әйтергә дә өлгермәдем.

Улым серле елмая. Үзенең ишегалдына кергән машиналарны күзәткәнлеге күренә.

– Миннән подъезд алдында калганнар иде, – ди.

Нинди көн бу, ә?! Син уйларга да өлгермисең, колакка-колак кына сөйләшәсең – сереӊ бар дөньяга таралган була. Әнвәр подъезд каршында мине машина көтәсен кайдан белергә мөмкин?

– Әнвәр! Син кемнәр турында сөйлисең?

Улым сорауны ишетмәдеме, карый торгач, нидер тапкан кебек, күрше подъездга таба атлады. Мин дә шул якка борылдым. Машиналар куя торган уентыкта ап-ак, өр-яңа «Мерседес»ның капоты чыгып тора!

– Әнвәр!

Нигә туктамый ул? Ник бер соравыма җавап бирсен?! Әтисе белән бер инде: үзе теләгәндә генә сөйләшә. Алай дисәң, ул менә – минем янымда, әтисенә безнең кайдалыгыбыз да барыбердер. Әнвәр минем тормышыма битараф түгел. Бөтенләй аңламый дип булмый. Өйдә булыша. Яхшы укый. Теләсә нәрсә белән борчымый. Тик... үзе теләгәндә генә сөйләшә, теләсә генә җавап бирә. Әллә бөтен ир заты шундыймы соң? Үзенекен үз итүчән. Һичкемгә исе китмәүчән. Алай дисәң, Әнисәнең кайсы ир кешегә исе киткәне бар? Әтисе белән Әнвәрен генә шул исәпкә кертә алмый.

– Әни, ашык инде. Көттермә!

– Борыл әле!

Әнвәр борылмады. «Мерседес»ка якын иде инде. Менә аның алгы ишеге ачылып китте дә затлы киемдәге чибәр генә ир-атның чыга башлаганы күренде. Чыкты. Әнвәр белән ирләрчә кул биреп күреште.

Ә кызы? Кызы кайда? Теге ир, аны да урамга чакырыр өченме, арткы ишекне ачты һәм, нәрсәдер алып, улыма сузды. Песи, кечкенә генә песи баласы иде ул!

Әнвәр шунда ук әлеге песигә үрелде. Бер-берсен ошатканнары әллә каян күренеп тора: борыннарын борынга терәшкәннәр. Әнвәрем аны иреннәреннән үбеп алган булды, колак артларын кашыды. Шушыннан гына карап торыйм әле. Ничәмә-ничә тапкыр, чит кешеләр белән артык якынайма, дигәнем бар, ул менә колак та салмый икән. Беренче күргән кешесенең мәчесен кочаклап, машинасына кереп утырырга торгандай. Үзе соң, үзе?! Тиктомалга сүз куертып маташмадымыни?!

Бу таныш түгел ир-ат минем чыкканымны, аңа карап торганымны белә, сизә бит инде! Нигә бире таба килми? Нигә үзләре янына чакырмый? Ишек төбендәге утыргычка утырдым. Телефонны алдым. Укылмаган бер язу бар икән. «Без сине аста көтәбез. Артур».

Артур? Дус-ишләрем арасында Артур дигән бер генә кеше дә юк иде. Уйлап-уйлап та таба алмадым. Ул һаман бу якка карап тора. Нигә килми? Нигә чакырмый? Үзем барганны көтәме? Чакырган булып, шаяртты гынамы? Мәче китерергә генә килгәнме?

Җавап язарга булдым. Артур, мин сине белмим, белергә дә теләмим, дип әйтимме? Фу! Сумкамны актарганга салынып, утырып кына торыйм әле. Мине оныттылар бугай дигән идем. Юк икән. Сискәнеп киттем.

– Мам, ты че?

Яратмыйм Әнвәрнең шулай дип эндәшкәнен! Җыен мин ошатмаган сүз сеңә дусларыннан. Җитмәсә, урысча! Дәшмим әле.

Әнвәр телефон тоткан кулыма үрелгән иде. Икенчесе белән мәче баласын кочаклаган.

– Улым, бер белмәгән кешеләр янына барырга, әйберләрен алырга ярыймыни? Күпме тукыйм.

– Нишләп белмәсен? Ул әнә сине бик яхшы белә. Якын килгәч, үзең дә танырсың әле.

– Ә син аны кайдан казып чыгардың?

Казып чыгарырга – борынгы заман кешесемени... Бер дигән яшь ир. Чибәр. Затлы киенгән. Минеке шул булыр инде. Ирләрнең ирлегенә тиюдән тәм табу. Исем китмәгән булып кылану. Ошатканда да куган булырмын, кит әле, диярмен. Утызда да киребеткән булып калырмын дип, кем уйлаган?

– Ул мине «Контакт»тан үзе эзләп тапкан. Әниең фамилиясе белән эзләдем, Әнвәр икәнеңне ишетеп белә идем, ди.

– Мин аны белмим. Китсен, алай шаярмасын. Бар, барып әйт, мәчесен үзенә илтеп бир. Болайга киткәч, теплоходта йөрергә дә чыгасы килми. Киләсе атнага билетның яңасын алырбыз әле.

Әнвәрнең борын салынды. Кара син, мәче баласы да үпкәләгән кебек карап тора. Бәләкәй вакытта минем дә шундый ук мәчем бар иде, һич уйламаганда, суга төшкән кебек юк булды. Көне буе хуҗалык тирәсендә кайнашкан, беркая чыгып йөрмәгән карт әбием, югары очтан килгән бер малай, кул арты китмәсен өчен, биш

тиенгә сатып алды аны, яңалары булыр әле дип уйладым, бирдем инде, күзе бик төшкән иде, кем улы икәнлеген дә сорамаганмын, диде. Имеш, борчылма, озак та үтмәс, Сорыкай шундый ук бәбиләрне кәрзин тутырып китерер. Борчылмаска! Бигрәк матур иде шул. Менә бу почык борын кебек үк матур!

Сорыкай ул елны әллә нинди сарылы-сорылы песиләр алып кайтты. Әнисәнең аларга күңеле ятмады. Ярый әле күршеләргә таратып бетерделәр. Сорыкай тагын-тагын бәбиләр дип уйлаганнар иде дә, үзе дә әллә кая китеп югалды. Әбиләренең, мәче үз нигезендә үлми, читкә китә, дигәннәре дөрестер, ахрысы.

Әнвәрнең борчылганын күрү авыр иде. Нигә әле үзенең дә, аның да кәефен төшерергә? Әнә бит машина көтеп тора. Барып өлгерергә вакыт җитәрлек әле. Җәяү атлыйсы түгел.

– Әйдә, Әнвәр. Һава сулап кайтыйк булмаса? Ул да билет алмагандыр бит?

– Алган.

– Алайса телефоннан син аның белән сөйләшкәнсең инде?

– Әйе...

Нәрсә дисең бу малайга? Эш узгач, орышудан мәгънә юк. Шулай да кем соң ул? Аны «Мерседес»ка утыртып алып китәрлек кеме бар?

– Улым, кем ул?

– Артур абый.

– Артур икәнлеген беләм. Кайдан? Кайда яши, кем булып эшли? Аларын сорап та тормадыңмыни?

– Юк. Әйбәт икәнлеге болай да күренгәч, сине дә белгәч, нәрсәгә тикшерим. Танымасаң, аларын юлда белешербез әле. Безнең теплоходта бергәләп төн чыгасы бар.

– Кояш батуга, ятам да йоклыйм. Йөрерсез йолдызлар астында елга суын иснәп Артур абыең белән икегез.

Нәрсәгә төрттереп сөйләшәм мин? Төнге сәяхәткә баруыбыз түгел диярсең. Өйдә дә йоклап булганда, анда барып ятмыйсың бит инде.

Бераздан Артур дигәннәре үзе дә Әнисәләргә каршы килә башлады. Кем икәнлеген белмәсә дә, таныш чалымнар бар кебек иде анда. Исеме генә менә, исеме генә...

Артур оялчаннардан түгел иде бугай. Килеп җитүгә үк, Әнисәне Әнвәре, мәчесе-ние белән кочагына алды.

– Сине дә табар көн бар икән. Ярый да шушы мәче булды. Малаеңны аның белән кызыктырмасам, һич тә синең телефоныңны бирәсе, адресыгызны әйтәсе түгел иде. Танyйсыңмы бу мәчене, Әнисә?

Кайлардан таныйм? Көзгедән карап, үзеңне танымаслык яшькә җитеп барганда.

– Юк!

– Ә мине?

– Сезне юк та юк инде!

– Колаксыз Ибрай малае Артур бит мин! Синең белән балалар бакчасына йөргән идек. Оныттың дамыни? Әле кичләрен җәй көннәрендә, урамыгызга төшеп, мәче балагыз белән бергәләп уйный идек.

– Син? Артур? Теге миңа өйләнәм дип аптыраткан Артурмы?

– Соң...

– Ничек эзләргә булдың син мине? Ә мин менә хәтердән үк чыгарганмын. Үпкәләмә инде. Ике дистәдән артык вакыт эчендә бер тапкыр күрмәгән кешене кем дә таный алмас иде.

– Ә мин таныдым. Әниеңә охшатып таныдым.

– Алай икән, – дигән булдым, сүзне ничек дәвам итәргә белмәгәннән генә.



Рәсем: Наталья Васильева

PRESSA.RU

– Шулай, – дип суздысы ул да. – Гомер үткән дә киткән. Сине онытмавыма үзем дә аптырыйм мин! Шушы мәче баласы аркасындадыр да инде.

– Ә мин сезнекеләрне һич исемә төшерә алмыйм. Мәктәпкә керәсе елны китеп барганыгыз гына хәтердә калган.

– Соң... Син мине яратмый идең бит. Онытуыңа аптырыйсы юк.

Әнисә кычкырып көлде. Артур да, Әнвәр дә елмайдылар.

– Бакча баласында нинди ярату булсын? Бала янында шаяртмале, Артур!

– Нинди бала? Җиткән егет диген. Яраткан кызы аның да бардыр әле.

Әнвәр аска карады.

– Соң, мине яратсаң, гел күрше малаегыз Гали белән генә уйнарга тырышмас идең. Аны усал малайлардан якламас идең.

– Үзем малайша булганга гына ул.

– Аңа кияүгә чыгуың малайшалыктан түгел бит инде, Әнисә. Сүземне гел кирегә сукалап утырасың.

Тагын Әнвәргә күз салдым. Нигә тарткалашалар икән болар, дигән кебек борынын җыерган.

– Чыктым шул. Галигә шул... Гали сораганда, Сәлигә барып булмый.

– Әнә шулай тырт та пырт сөйләшмәсәң...

– Алай сөйләшмәсәм дә, сиңа чыкмаган булыр идем. Ә менә эзләп кайтсаң... Яшь чагымда ук эзләп кайтсаң...

– Безнең яшьлек узмаган әле, Әнисә!

– Әйе, утызда да кыз, тыз да быз, – дип көлгәнемә Артурның ачуы килде.

– Элек тә шундый идең, бөтенләй үзгәрмәгәнсең. Өйләнәм мин сиңа, дигәнемә ышанмаган булдың, Әнисә. Өйләнергә дип килдем менә.

Фу! Теленә салынмаса! Ә чынлап сөйләшсә?

– Кызым белән киләбез, дигән идең. Ул кайда? Өйдә калдымыни? Хатының нигә сезнең белән түгел?

Артур аптырады.

– Ник минем өйләнгәнем юклыкны да ишетмәгән идеңмени? – ди.

– Юк. Соң, кызым, дигәч...

– Кызым дигәнем менә шушы мәче баласы бит инде ул. Әнисе картайды. Тәрбиясе минем кулга калды. Картайгач, мәчеләр, кешеләрдән кача, табигатьтә югала ул, дигән иде әбиең. Шулайдыр, ахрысы. Жирләгән булыр идем, тапмадым. Истәлеккә дип, әбиегездән мәче балагызны сатып алып киткән идем бит. Менә шул песинең нәселе инде бу юеш борын. Күзләре нәкъ синеке кебек, име?

Әллә тагын. Җан иясе хуҗасына охшый инде. Күпмедер. Әнисә мәчесе түгел бит ул! Аңа ничек охшасын?!

– Кара инде, кара, күзләре соп-соры. Борыны почык. Керфекләре озын. Аны ашатырга, юындырырга да кеше кирәк. Икегез генә Әнвәргә дә күңелсездер. Әллә бергә генә торабызмы?

Артур әнә шулай тиз-тиз генә ярды да салды.

Юк! Нигә күңелсез булсын! Менә бит теплоходта ял итәргә чыгабыз. Әтисе белән торганда аны да күрми иде әле ул. Әнвәргә карадым. Ул әллә җавабымны көтә, әллә үзе дә җавап әйтер кебек карап тора – аңламадым.

– Мам, ты че?! – диде, ачуны китереп. – Һаман икәү генә яшәмәбез бит инде?! Не груби. Не тяни...

– Бирермен мин сиңа ул ямьсез урысча сүзләрең өчен. Әни диген!

– Әни, кешене аптыратма инде, пароход китеп барганчы кузгалыйк. Мин риза дигәннән генә берни үзгәрмәскә дә мөмкин бит. Кайткач, сүзеңне кире алырсың.

Кара син бу хәйләкәр малайны! Теге якка да, бу якка да ярамакчы! Ә бәлки, аның шундый булуы кирәктер дә. Әнисәнең тырт-пыртлыгыннан кемгә файда? Артур түгел, күңелен аңласа, чынлап яратса, тышкы кыяфәте аннан ямьсезгә дә чыгарга әзер еллары бит аның.

Үзгәрмәскә дә мөмкин, ди... Үзгәрмәс дип уйласа, нигә әле ул инде онытылып беткән бер малайның балачак сүзләрен җәпләп торырга тиеш? Ә үзгәрсә? Артурның Галидән кайсы ягы ким? Ялгыз да булса? Әнвәргә дә ошагач? Песие дә үз нәселенеке булгач...

Әнисә елмайды, тик берни дә дәшмәде. Машина ишеген ачты да кереп утырды.

– Әйдә соң, алып кит безне үзең белгән җирләргә! Үзең белгәнчә яшәргә!

Шулай шаярып кына әйткән кебек иде дә...

Менә унбиш ел яшәп ята икән инде.

Әнисә ишек катындагы киездә йоклап яткан мәче баласы янына килде. Башыннан сыпырды. Нигә уятырга иде инде аны? Менә хәзер ашарга сорап йөдәтәчәк. Йөдәтсә, сөт салып бирер. Суыткычтан гына аласы.

Кара син бу мәчене. Күзләре соп-соры. Керфекләре озын. Әнисәнең Алисәсе диярсең. Аны Артурына охшаткан булалар. Ә ул менә үзенә тарткан дип уйлый. Күзләре соп-соры бит. Әнисенеке, әбисенеке, Әнисәнеке кебек соры. Ул сабый вакытында уйнаган мәче дә шундый иде. Их, әбисе шуны Артурга сатып җибәргән! Бөтен мәче балаларын да йортта калдырып булмый, дигәндер. Их, дип үкенгәндәй итсә дә, Әнисә аңа үпкәләми. Әнә бит бер мәче баласын Әнвәр үзләренә алды. Әни, чат сезнең икегез кебек тә бу, ди. Белмәссең тагын. Читтән ныграк күренә. Әнвәр юкка әйтмәс. Әнвәр юкка яратмас.

Әйе. Күзләре соп-соры икән шул Әнисәләрдә калганының да. Мәче булса да, кеше кебек акыллы карап тора. Борынын имчәк эзләгән сабый кебек боргалый. Күзләре соп-соры. Соп-соп соры. Әнисәнеке, Алисәнеке, Артурыныкы кебек. Нигә дип бер сүзне кабатлыйсы килә дә тора? Үзалдына сөйләнеп утырып, Артурны уята инде. Мәче баласыннан да саграк йоклый ул. Сөтне аннан да ныграк ярата. Уянса уяныр, шул соры күзләреннән бер генә үбимче.


БЕРВАКЫТ ӨЛКӘН ЖУРНАЛИСТ ИЛДАР НИЗАМОВ ӘЙТЕП КУЙГАН ИДЕ: «БАЛАГА БАЛА КИРӘК ИПТӘШКӘ!» БУ ФИКЕР БЕЛӘН БАРЫБЫЗ ДА КИЛЕШТЕК.

Асия ЮНЫСОВА

КЕШЕГӘ КЕШЕ КИРӘК

Фонтан тирәли куелган эскәмияләрнең берсенә лапылдап бер кыз килеп утырды. Тәртипсез кызларның берсе инде бу. Килеп утыруга ук букчасыннан олы гына бер шешә чыгарып, йотлыгып-йотлыгып сыра уртлап алды. Кызның кәефе ни чама икәнлеген белерлек түгел. Ул әле мәгънәсез генә, дөрес-рәге, гамьсез генә елмаеп ала, әле кашларын җыерып, үз алдына сүгенеп куя: «Вот блин! Каян алыйм мин аңа акча? Фатир бәясен куя беләләр үзләре! Ярый ул алар заманында тулай тораклар булган. Ә мин кая барыйм? Туган тиешле диләр бит әле. Чыбык очы... Тәртипле йөрсәң, салып кайтмасаң, акчасыз да тотар идем мин сине, дип яхшатлана. Вот блин! Салып кайтырга түгел, менә монда кабып кайтырга да бетеп киткән әле!» Кыз сырадан бушаган шешәсен аркан якка гына селтәп, кычыткан арасына томырды. Шуның белән аның шөгыле дә бетте. Инде нишлисе? Тик утырганчы дип елап алырга булды. Кызганыч авазлар чыгарып, бер ара үксеп алгач, тагын тормышка игътибары уянды. Нәфесе хәмер тели иде. Йә, ничек юнәтергә икән шул тәмле тәмсезне?

Кызый шунда утыргычның икенче башында утырган ир-ат затын күреп алды. Һа! Аның ягына юри генә дә бер борылып карамаган була бит бу ир тәганәсе. Кара күзлек киеп алган да тәкәббер кыяфәт белән йөзен кояшка таба каратып утыра бирә. Ник ул аңа – матур кызга таба карамый? Бу адәмнең битарафлыгы кызның ачуын чыгара башлады: «Әй, син, кояштагы таплар миннән кызыклырак тоеламы әллә? Әй, син! Монда кара! Күрәсеңме минем күз тәпләрендәге тапларны? Алар кызыклырак. Аларның тарихы бар. Шул тарихны кемгә дә булса сөйлисем килә. Болайрак шуыш.



Күзлегеңне дә миңа салып бир. Күзлек миңа кирәгрәк!»

– Сеңлемме син, апаммы – белмим. Бәйләнмә син миңа. – Теге ир заты телгә килде. – Минем күзлегем сиңа файда китермәс. Үземә дә аңардан файда юк. Ә тарихыңны сөйли аласың. Мин тыңларга әзер. Хәер, син аны сөйләп бетердең дә бугай инде. Фатир хакын түләмәгән өчен торагыңнан куып чыгарганнар булса кирәк...

– Нәкъ шулай. Минем бүген кайтып кунар урыным юк. Сыеныр кешем дә юк. Йә, мин кемгә кирәк? Ә бит Казаныгызга укырга дип килгән идем. Юньле кешеләрнең баласы идем. Башта әти үлеп китте, аннан әни... Икесен дә яман шеш алып китте. Түләп укый торган җиргә кергән идем. Түләргә акча юк. Ташладым укуны. Әкренләп дуслар табылды. Кайгыны оныту юлларын өйрәттеләр. Котылдым инде мин ул дуслардан. Алар өйрәткән гадәтләрдән генә арынуы кыен. Хәзер, торыр почмагым да калмагач, кабат алар янына сыенмый хәлем юк. Их, абзыкаем, бир миңа күзлегеңне. Оялам мин бу кара янган йөземнән. Их!

Кыз тагын үксеп елап җибәрде. Бу юлы чын-чынлап, хәсрәтләнеп...

Күзлекле кеше кыз янына таба шуышты:

– Сеңлем димме, апам димме... Сукыр бит мин. Абайламадыңмыни? Күзлек миңа сөйкемсез күз бәбәкләрен яшерү өчен кирәк. Кояшка төбәлеп утыруым шул йолдыздан килгән нурны тояр өчен. Икебез дә бәхетсез икән. Кичәгә көнгә кадәр мин бәхетсез түгел идем әле. Минем Юлдашым бар иде. Этемнең кушаматы ул Юлдаш. Кичә аны машина таптады. Юлдашны алып киттеләр. Ә мин менә шушында – фонтан янында утырып калдым. Өем була торып, төнне шушы утыргычта үткәрдем. Чөнки Юлдаштан башка мин өемә кайта белмим. Аңлыйсыңмы? Адресымны беләм, ә кайта белмим. Менә нинди сәер хәл – синең өең юк, минем юлым юк. «Нишләп утырасың монда? – дип, төн буена бер кеше дә килеп сорамады.

Кыз кинәт айнып киткәндәй булды. Тәмам әсәренеп калды. Күзлекле кешенең суырылып киткән йөзенә төбәлде: «Синең ашыйсың киләдер, эчәсең... Ә мин тиле синең яныңда голт-голт итеп сыра чөмереп утырдым. – Яхшы ата-ананың яхшы булып туган баласындагы миһербан исән иде әле. – Йә, ничек ярдәм итим сиңа, абый?»

– Болай итәбез, сеңлем. Әйе, сеңлем икәнсең. Син мине җитәкләп өемә алып кайт. Теләсәң, яшәп тә калырсың. Берара миңа «күз» булып торырсың. Мин сиңа кыенлык китермәм. Аннары берәр чарасы табылыр. Тик ни бит... Мин дә кызларның хәмер белән дуслыгын хупламыйм. Миңа «күзләремнең» аек булуы кирәк. Бәлки, бер-беребезгә таяныч булыр өчен Аллаһ сине шушы фонтан янына китергәндер. Кояш астындагы бу фани дөньяда кешеләр бер-берсенә кирәк әле. Шулай бит, сеңлем. Әйдә, киттек! Бир кулыңны!

Бу сөйләшүнең шаһиты булган мине – өченче кешене алар абайламадылар да бугай.

PRESSA.RU



Язучы һәм шагыйрә, җырлар авторы, тәрҗемәче, журналист... Сүзнең тәмен белеп, рәхәт итеп, онытылып укырлык итеп яза. Геройлары – язучылар, артистлар, табиблар, игенчеләр... Үзе ул табиб та, укытучы да, артист та, адвокат та, тел һәм әдәбият галиме дә, психолог та була алыр иде. Аның дөньясы – иҗат, китаплар, театр, сәяхәтләр... Ул – укытучы кызы. Шуларга өстәп, табигать, авыл баласы, Ык кызы... Тагын әллә ниләр тезеп китәргә була Асия апа турында. Ә укучыларыбыз аны язмалары аша яхшы белә. Асия Юнысова язган, дип яратып укыйлар.

«Кыз» йолдызы – минем йолдыз



Эльмира ЗАКИРОВА

Кайбер көннәрне Асия апа белән җәяүләп эштән кайтабыз. Ул – кызыклы әңгәмәдәш: әллә нинди темаларга кереп китәбез. Бассейнда йөзеп кайтуын сөйли дә әнә: «Без бит тәпи йөри башлаганчы ук йөзәргә өйрәнгән», – дип куя. Ышанам: Ыкта чума-чума йөзеп үскән лә! Казаннан Октябрьскига оча торган самолетлар да туган авылы Кызылъяр болынына төшеп утыра торган булган ди әнә... Шундук берәр мәзәк сөйләп ташлый да, вак кыңгырауларны чыңлаткандай, рәхәт итеп көлә үзе. Бүген иртәнге бишкә кадәр Ремаркның «Триумфальная арка»сын укыган икән. Жоан Мадуның прототибы Марлен Дитрих, ди. Беркөн редакциягә Моэмның «Острие бритвы»сын алып килгән иде. Белмәгән язучысы, укымаган китабы юктыр бу Асия апаның!

Бер караганда – шаян, бер караганда – кырыс һәм таләпчән... Төрле чакларын күргән бар аның.

«Әкияттәге кызый бит мин, / Тәвәккәл мин, хәтәр мин...» – дип яза бит әле әнә. *«Минем күңел – моңлы курай...»* – анысы да аңлашыла инде.

Мин – тырбызык, / кабыргга торам...» – дип тә куя әле!

«Кыз» йолдызы – минем йолдыз, / Язмышыма шул «Кыз» хуҗа...

Әһә, сентябрьдә, димәк, туган көне! Миңа кызык булып китте. Аны күбрәк беләсем, тирәнрәк ачасым килә башлады. Кем соң ул Асия апа?

«Татарстанның атказанган мәдәният хезмәткәре», Татарстан журналистларының Хөсәен Ямашев исемендәге премиясе лауреаты, «Бәллүр каләм» иясе... Берсеннән-берсе матур шигырь китаплары авторы... Күптән түгел дөнья күргән «Асылташ» китабындагы шигырьләрен дә, әнә, минем тормыштан, ди. Шигырь юллары яңадан-яңа сораулар тудырды.

***– Җитез аяк идек без яшьлектә – / Журналистка кирәк бу сыйфат,* – дип язасыз «Туган көндә» дигән шигырегездә, Асия апа. Журналистикага килүегез турында сөйләгез әле.**

БАЛАЧАКТАН УК КИЛДЕМ МИН ЖУРНАЛИСТИКАГА. Без укыган дәвердә мәктәптә стена газеталары чыгару бар иде бит. Ә мин инде 3 нче класста ук стена газетасы редакторы идем. Үзебезнең Кызылъяр мәктәбендә укыганда да, Баулыдагы 2 нче мәктәптә дә редактор булдым. Миңа хәтта бүтән класс укытучылары да мөрәҗәгать итә иде. Дизайнын да үзебез уйлыйбыз, кемнән интервью алырга кирәген дә... Буш урыннар калганда шигырь язып тутырам. Без көн саен авылыбызга кайтып йөри идек: район үзәге белән авыл арасында автобуслар сәгать саен йөреп тора! Ә мин, газета чыгарып утырып, төнге 11 ләргә дә калгаладым. 9 яшемдә беренче шигырем район газетасында басылды. Язмаларым өчен гонорар да түлиләр иде! Берчак шул гонорар акчасына мандолина сатып алдым. Чибәрлеге белән магик көчкә ия Галимә апа мандолина түгәрәген җитәкли, күбрәк аңа була да йөри идек ул түгәрәккә. «Каз канаты», «Әнисә»ләрне уйнарга өйрәндем өйрәнүен. Әмма колакка аю баскан булып чыкты. Өйгә интеллигент кыяфәте биреп, мандолинам стенада эленеп торды...

Баулы урта мәктәбендә укыганда Петр Александрович Зотагин безнең класс җитәкчебез иде. Рус теле һәм әдәбияты укытучыбыз башта Баулы район газетасында эшләгән. Районнарны берләштергәндә газетаны япканнар, Петр Александрович безгә килгән. Журналистика буенча беренче дәресләрне аңардан алдык. Журналистлар җырын да ул өйрәтте!

Трое суток шагать, трое суток не спать / Ради нескольких строчек в газете... – дип, Зотагинның аккордеонына кушылып җырлый идек. Кыяфәте дә, тавышы да гел Владимир Трошинныкы инде! Мин аның аккордеонына гына түгел, һөнәренә дә гашыйк булдым... Университетта аерым журналистика факультеты юк, ул тарих-филология факультетының бер бүлеге генә. Анысына керү өчен дә берничә ел стаж җыярга кирәк. Татар теле һәм әдәбияты бүлегенә төбәп бардым... журналист булу өчен.

– Университетта укыганда Зөлфәт белән сөйләшеп-көлешеп утырып, кадерле профессорларның лекцияләрен өзә торган булгансыз, диләр. Студент елларыгыз турында да сөйләгез әле.

МИН АЛАЙ ТӘРТИПСЕЗ ТҮГЕЛ ИДЕМ! (*Көлә.*) Безнең 456 нчы группа, 60 нчы еллар урталарында мәктәп тәмамлап, укырга кергән егет һәм кызлар. Сабакташым язучы Рафаэль Сибат болай язган иде безнең хакта: «Күбебездән әле әрем-кычыткан, бодайборчак, сарык-сыер исе дә китмәгән. Чистай мишәре Әмир Дәминов, пулемет кебек кызу-кызу тыкылдап, әдәби бәхәсләргә керә, Әгъләм белән Зөлфәт көн саен берәр чиләк шигырь язалар (ошамаса, чиләккә генә аталар – чүп чиләгенә!). Лекцияләрдән качарга да өйрәндек инде. Шулай бервакыт таярга ниятләп яту иде. «Һайт, егетләр!» – дигән тавышка борылып карасак, кояштай елмаеп Асия карап тора. Күзләрендә ирония катыш үткенлек. «Ә-һә, әле сез лекциядән качасызмы?» – ди. Оялучан вә каушаучан Фәрит Гыйльми тигез асфальт өстеннән кереп китәргә җир тишеге эзләде...»

Хәтерлим мин дә... Ул сезнең риясыз, эчкерсез, самими көлүегезне яратып яза. «...әдәби детальләр, сискәндергеч яңа сүзләр, кыздай киендерелгән җөмләләр Асиянең иң беренче язучы булуын сөйлиләр», – дип бәяли. Сезне республиканың иң көчле журналистларыннан берсе дип атый. Үзегез дә инде: *Януларым гел ихластан иде. / И түктем лә шуны кәгазьгә!* – дип язгансыз бит әнә! Ә шул Зөлфәт сезгә мондый шигырь юллары багышлый: *И Асия! Шигырь кәнизәге, / Җиһанның бер сәер җимеше... / Һәр язганың булсын соңгы сыман, / Һәр язганың хиснең төүгесе!*

ЖУРНАЛИСТИКАГА КИЛҮЕМ СИКӘЛТӘЛЕ БУЛДЫ ШУЛАЙ ДА. Китап нәшриятында сәясәт бүлегендә эшләп алдым, «Татарстан коммунисты» журналында тәрҗемәгә кереп киттем, «Ватаным Татарстан» газетасына тәрҗемә бүлеге мөдире итеп эшкә чакырдылар. Властька Горбачев килгән чак. Турыдан-туры 50 шәр бит тәрҗемә итеп, машинисткага әйтеп кенә җыйдырган чаклар да була иде. Тәрҗемә бүлегендә озак эшләмәдем, әдәбият бүлеге мөдире итеп куйдылар. Һәрвакыт яздым. Күбрәк очерклар яза идем. Авыл хуҗалыгында эшләүчеләр, нефтьчеләр, табиблар турында... Нефтькә коенып, буровойда Агарков егетләре белән вахтада торганым да булды (бригадир Агарков – ВЛКСМ съезды делегаты иде). Бервакыт онкология больницасында 8 сәгатькә сузылган операциядә басып тордым. Хирурглар, операция шәфкать туташлары, яшәү белән үлем арасында яткан хатын... Барысының да халәтен үз йөрәгем аша үткәрдем.

– Хәзер сезнең юллар белән дәвам итәм инде: *Төне буе яздык мәкаләләр – / Мәртәбәнең әҗере ай кыйбат...* Шулай бит?

ГАЗЕТА БИТ МАРТЕН МИЧЕ КЕБЕК, КӨН САЕН «УТЫН» ТАШЛАП ТОРЫРГА КИРӘК АҢА! Әдәбият бүлегендә эшләгәндәге беренче интервью Нурихан Фәттах белән иде. Язучылар, җырчылар, театр артистлары, рәссамнар – бар да минем геройлар. Кеше эштән кайтып китә, ә мин – театрга. Ул ләззәт бирми иде. Арып карыйсың. Чөнки син эшлисең.

PRESSA.RU

Кулда ручка, блокнот. «Татар җыры» концертлары төнгә кадәр бара иде. Син кайтырга чыкканда инде транспорт туктап калган була. Таксилар кыйммәт. Гадел Кутуй урамына кадәр җәяүләп кайтам. Икенче көнне эштә, соң кайткансыңдыр, димиләр, «материал кайчан була?» – дип сорыйлар. Бер полоса, димәк, 9 бит дигән сүз. Туп-туры машинисткалар янына керәм дә мәкаләмне әйтеп кенә яздырам. Ике сәгатьтә инде минем материалым әзер була. Экспромтом гына эшли алуым, йөгерек зиһенем миңа һәрчак булышты. Гомергә диктофон белән эшләмәдем, аны тыңлап утырырга вакытым юк иде минем. Мин – блокнотлы журналист.

– Ә шигырьләр кайчан язылды соң?

ЖУРНАЛИСТИКАДА АКТИВ ЭШЛӘГӘН КЕШЕНЕҢ ИҖАТКА ВАКЫТЫ КАЛМЫЙ. Гариф абый Ахунов: «Асиянең һәр мәкаләсе, язмасы әдәби әсәр», – дип үсендерә иде. Мәгънә салынмаган бер хәбәр дә язмадым. Шәхесләрне тарихка кертеп калдырасым килде. Фотога төшергәндә дә композициясен үзем уйлый идем. Васнецовның «Три богатыря» картинасын хәтерлисезме? Гариф Ахунов, Мөхәммәт Мәһдиев, Аяз Гыйләҗев, шуны кабатлап, «Өч баһадир» булып фотога төштеләр. Бу идеянең авторы мин фәкыйрегез иде... Әдәбият бүлегендә эшләгәндә тыгыз элемтәдә яшәдем язучылар белән. Гомәр Бәширов, Әмирхан Еникиләр белән аралашырга туры килде. Берчак редакторыбыз әйтә, Гомәр абый авырып киткән, хәлен белеп кайтырга кирәк, ди. Киттем өйләренә. 95 яшьлек Гомәр абый... шәһәр мунчасына китеп барган! Хәтерлим, Мәхмүт Хөсәен, минем архивларымны алып кал әле, дип килгән иде. Юморлы Салих абый Баттал белән гел аралашып тордым... Язып та бетерә шигырен, редакциягә килеп тә җитә... Алар миңа соңгы бер таяну ноктасы итеп карыйлар иде шикелле. Кайчак аларга арбитр да булырга туры килә иде. Миргазиян Юныс белән Мөхәммәт Мәһдиев арасында конфликт чыкты бер мәлне. Кайсыдыр газетада Миргазиян абый Мәһдиевкә кагылып киткән. Мәһдиев җавап язып китерде. Чыгармадым. «Тимер йөрәк белән йөри ул, Мөхәммәт абый, клапан белән генә», – дидем. Үләренә күп калмаган иде инде: Мөхәммәт абый соңгы сүзне минем аша әйтеп калдырырга теләде. «Аягың җиңел булырмы икән, Асия?» – диде. «Мин 195 ел яшәдем» дигән мәкалә алып кайттым аңардан. Моңа ышанырга була дип карыйлар иде миңа. Ярдәм итә ала дип саныйлар иде. Туфан абый – үзе бер сәхифә. Аның белән дус булдык без. Гариф Ахунов һәр язмамны җыеп барган икән... Минем сүземне әдәби сүз дип күрәләр иде. Башкорт язучысы Наҗар Нәҗминең хатлары саклана. «Менә нинди икән син!» – дип язды ул, Рәшит Әхмәтҗан үлеменә язганнарымны укып. Ә андый хушлашу сүзләре күп язылды инде. Нәкый Исәнбәт, Гариф Ахунов турында... Хәйдәр Бигичев турындагысы: «Бу хәбәр барып ирешмәгән бәхетле төбәкләр бар. Алар әле Хәйдәр Бигичев вафатын ишетмәгән...» дип башланып китә иде...

– Сезнеңчә, журналистика нинди булырга тиеш?

КӘГАЗЬ БЕЛӘН КАЛӘМНӘН ЛӘЗЗӘТ АЛУЧЫЛАР БЕТТЕ. Хәзерге журналистлар информация дәрьясында курсор кебек кенә. Журналистлар түгел, блогерлар алар. Кыска информацион жанрлар өстенлек итә хәзер. Журналистиканың алга таба нинди буласын күреп торабыз инде... Безнең алда һәрчак максат, проблема була иде. Язмаларыбыз белән кешенең проблемасын хәл итәргә алына идек: кемгәдер фатир алырга булышабыз, кемнеңдер баласын авырудан йолып калырга тырышабыз, кыерсытылганнарны яклыйбыз... Язган әйбернең эзе калырга тиеш. Без шундый журналистлар идек. Журналистларда, матур язудан тыш, акыл булырга тиеш. Кредосы, кыйбласы, фикере булмаган журналист журналист була алмый. Журналистның вәкаләте – гаделлек урнаштыру.

***– Өянкеләр һаман шул икән лә, / Кычытканнар һаман шук икән... /* Шул җырыгыз без – авыл балаларының җаннарын актарып ташлый. Сез бит Ыктан, авылдан. Сөйләгез әле...**

ТУГАН ЯКНЫҢ ҺӘР СУРӘТЕ ҖАНГА БИЗӘК БУЛЫП УЕЛГАН. Зәйнәп Фәрхетдинова җырлый торган ул җырымны да яраттылар. «Шул җырны ишеткәндә, машинамны туктатып, юл буе чирәмендә аунап елаганым бар», – дигән иде мәрхүм Шамил Зиннур улы Закиров. Биш минутта язылган шигырь иде ул югыйсә. Кухня өстәле янына килеп утырдым да үземә таныш картина – Ык буендагы өянкеләр, әрәмәсендәге бөрлегәннәр, басмаларда кер чайкаулар, өй каршындагы сиреньнәр – күз алдыннан үтте. Венер Мөхәммәдиев шуны көйгә салган. Бу җыр 2002 елда «Татар җыры» бәйгесендә лауреат булды.

***– Йөгерек Шәйхулла оныгы мин, / Йөгерек ул – безнең кушамат...* – дип, Сез үзегезнең нәсел белән таныштырып китәсез...**

КУШАМАТЫБЫЗ ЙӨГЕРЕК БЕЗНЕҢ. Әтиемнең әтисе Шәйхулла – бабамның Сабантуйларда ак күлмәген җилфердәтеп, гел беренче килгәнен күргәнем булды. Иңнәренә кызыл башлы сөлге салалар иде. Аның атасы Галиулла бабам да Йөгерек иде. Шундый нәсел без. Әни ягыныкылар – укымышлы кешеләр, муллалар. Китап ярату көчле иде аларда.

***– Кыштыр-кыштыр! Әллә яфрак, әллә / Балачакны искә төшереп, / Лампа яктысында утырамы Минем әни дәфтәр тикшереп?... /* «Укытучы кызы» дигән статус – үзенә бер мәртәбә. Ләкин ул әллә никадәр җаваплылык та өсти әле...**

УКЫТУЧЫ КЫЗЫ АВЫЗЛЫКЛЫ БУЛА. Аңа таләпләр һәрчак югарырак. Укытучы кызы булу җиңел түгел. Укытучы балалары арасыннан бер без генә үзебезнең авыл мәктәбендә укыдык. Башка укытучылар балаларын район үзәгендәге рус мәктәпләренә урнаштырдылар. Әнием – татар теле һәм әдәбияты

укытучысы. Бездә һәрчак китап культы иде. Өйдә ялгыз калганда китаплар минем иптәшләрем була иде. Чехов, Гюголарны укыйм. Әни кичләрен йә педсоветта, йә политукуларда... Мич төннегe шылтыраган тавышлар Гогольнең хыялый хикәяләренә әллә нинди шомнар өстәп, тагын да тәэсирлерәк итеп җибәрә... Шуларны укый-укый, ишекне дә бикләмичә йоклап китәм... Баулы урта мәктәбендә укый башлагач, ичмасам, тәмам ирекккә чыктым, узаманга әйләндем менә.

– Тормышыгызда эз калдырган кайсы вакыйга, кылган эш-гамәлләр белән горурлана аласыз?

КИТАПЛАРЫМНЫ ЧЫГАРА АЛМАСАМ, ҮКЕНЕЧЛЕ БУЛЫР ИДЕ. Балалар өчен биш шигырь китабы чыгардым, лирик шигырьләрем тупланган өч китабым дөнья күрде. Ә шулай да журналистика юлында язылган очеркларымны китап итеп чыгара алмавыма үкенәм. Ул шәхесләрнең күбесе юк инде. Фуат Мансуров, Азат Аббасов, Мөнирә Булатовалар... Ул заман кешеләре бик зыялы, бай биографияле иде. Алар мине үзләре белән тиң күреп сөйләштеләр. Берәүне дә кабул итми, сөйләшми дигәннәре дә... Кешене ача, сөйләштерә беләм мин – ачылмастайлар да ачыла. Миңа гына сөйләгән серләрен дә теләсә кая селекмим.

– Белмәгән эшегез – ул нәрсә?

БЕРКӨН ДУШНЫ АЛЫШТЫРЫП КУЙДЫМ ДА, СӨЕНЕП ЙӨРИМ ШУҢА. Әтинең кул арасына кереп, пычкы тартып утын да кистем, су да ташыдым. Авыл балалары бөтен эшне дә белә. Бәйләп тә, тегеп тә караган булды. Бүген кытай, кыргыз, төрек җиңел промышленносте азат итте ул күңелле эшләрдән. Метекле эшләрне яратмыйм. Тиз кирәк миңа! Башлаган эшне бетермичә туктамыйм. Иртәнге 7 гә кадәр обой ябыштырып, битне генә юып эшкә киткән чаклар да булды. Нәрсәләр белмимме? «Әй, әйттем әле!» – дия алмыйм. Ызгыша белмим. Кешедән бер күңелем кайтса, гафу итә алмыйм. Бусы – начар сыйфат. Әни кебек итеп токмач кисә, апам кебек итеп чәлтәр бәйли белмим. Күзеңне бетермә дип, кул эшләреннән тыебрак тордылар.

– Кайсы китапны кайта-кайта укыйсыз?

«ЧАЛЫ КОШЫ»! Балачактагы иң яраткан китабым. Гюнтекинның ул әсәре холкымны да шактый бозды. Врачлар мәктәпкә прививка ясарга килгәч, тәрәзәдән сикереп төшәргә кирәк идеме соң?! «Герой нашего времени»ны укып әле дә туялмыйм. Һәр укуымда яңа китап итеп кабул итәм. Укыйсы килгән китаплар байтак. Мин гомер буе китап укыйм.

***– Кемнәр чыгар,ниләр булыр анда – / Күп уеннар күргән сәхнәдә?* – дип язасыз. Сез театрга гашыйк җан. Артистлар – сезнең геройлар. Ә үзегез театрда кемне уйнар идегез?**

ЮК, МИН АРТИСТ БУЛМАС ИДЕМ! Артистлар уенына кызыкмыйм, кызганып карыйм. Чөнки алар гомер буе кеше «күлмәген кияләр» бит. Үзем булып яшәргә өлгерәсе иде әле. Геройларымның артистлар булуы хак анысы. Алар турында байтак язылды.

– Сезнең сәяхәтләр яратканны да беләбез. Шулардан алган иң якты тәэсирегез?

ИҢ КЫЕНЫ ТАУГА МЕНҮ ҮГЕЛ – ТӨШҮ! Аяк тая, адым саен бала башы чаклы ташлар тәгәрәп ята... Мамисон үткеле аша чыгып барабыз... Грузиянең Батумиена – Аджария башкаласына – барып, Кавказ сыртларында йөреп, «Турист СССР» значогы алып кайтуым искә төште әле. Тау башындагы куышларда куныл, Төньяк Осетиянең Югары Цей тауларында штормовкага утырып «чана» шуып, чиләкләп койган тропик яңгырларга эләгеп йөргән чаклар бар иде... Романтика шулай ашкындырган инде тауларга!

***– Альбомнар, альбомнар... / Юкалар, калыннар. / Кайвакыт актарам – / Елларны кайтарам...* Фотоальбомыгызда сакланган иң истәлекле фотосурәт кайсысы, Асия апа?**

МИН ӘНИЕМ ИТӘГЕНДӘ УТЫРАМ. Чәчләр чигәләп үреп куелган. Үзем ак күлмәктән. Бик бәхетле кебек мин анда... Икенче бер фотода – әни белән Камилә әбием. Әбкәйне «чибәр җиңги» дип йөртәләр иде. Морза кызы булган ул. Шул әбием бирнәсе булып, миңа талир тәңкә истәлеккә калган... Болар бик кадерле фотолар минем өчен.

***– Ике якта – ике кызым, / Ике кызым – йолдызым...* Бу юллар, әлбәттә, кызыгыз Ләйсән, оныгыгыз Камилә турында... Сез нинди әни, нинди дәү әни?**

ӘНИ, ДӘҮ ӘНИ НИНДИ БУЛЫРГА ТИЕШ – МИН ШУНДЫЙ! Ләйсән әтисе һәм минем юлдан китте: журналистиканы сайлады. Шигырьләр язуы да бездән күчкәндер, мөгаен. Ә Камиләбез менә Казан федераль университетының физика институтын тәмамлады. Аспирантурада укый. Бүгенге көндә Парижда стажировкада. Шул кызларым уңышларына сөенеп яшим.

...Асия апа белән бер тынга, эштән өйгә кайту юлында гына әнә шулай сөйләшеп атладык. Юк, мин әле аны һаман ачып бетерә алмадым. Салкын тисә дә, баш-тамак авыртса да, беренче диагнозны ул куя, Асия апа «доктор» ул безнең. Ул белмәгән үлән-чәчәк юктыр! Боларын сөйләп тә тормыйм инде... Ул пешереп редакция халкын сыйлаган коймак, балан бәлеше, бәрәңге бөкрие (бездә – бәрәңге тәкәсе – *Э. З.),* кыстыбыйларны да... Бергә командировкаларда йөреп кайтуларны да... Чәчәкләр-гөлләр яратуын да... Сиреньнәр, ромашкалар, төнбоеклар, кашкарыйлар, ак чәчәкләр, исле гөлләр, розалар, лаләләр – барысы да шигырьләренә сибелгән! Үзе дә әллә кай яклары белән ачыла торган серле чәчәк кебек ул! Сентябрь чәчәге!

PRESSA.RU





Ләлә
САБИРОВА-
ГЫЙМАДИЕВА

САГЫНДЫРЫР ТАНЫШ ЧЫҢЛАВЫ

Без университет тәмамлаган 1969 ел. Әле аңа кадәр практика үтәсе бар – Казанның Галимҗан Ибраһимов исемендәге 89 нчы мәктәбендә татар теле һәм әдәбияты буенча укучылар алдында «сынау» бирергә тиешбез. Миңа бишенче сыйныф эләкте. Анда ул чакта ук күренекле булган шагыйрь Шәүкәт Галиевнең төпчек улы Җәүдәт тә укый – бу минем өчен бигрәк тә сөенечле булды. Чөнки безнең төркем Шәүкәт абый белән беренче курсны тәмамлаган елны ук дуслашып беткән иде – Курганга фольклор экспедициясенә ул безнең белән бергә чыкты, шуннан соң укуны тәмамлаганчы аралар өзелмәде. Гомерлек дусты Илдар абый Юзеев белән бергәләп без яшәгән тулай торакка да килеп йөрде әле, анда әдәби укулар үткәрә торган идек. Безнең төркемдәгеләр бу ике олуг шагыйрьгә ул чактан ук мөкиббән булды, һәрберебез үзебезне күрсәтеп калырга тырыштык. Әнә салмак-сабыр тавыш белән Харрас Әюпов үзенең атлар турындагы моңсу шигырен укый, аның артыннан Рәшит Ягъфәров чыга – ул, ярсый төшеп, «капчыкларга салып, чормаларга элеп куелган гармуннар»га мәдхия укый, Рәшит Әхмәтҗанов исә укырга кергәнче үк өлгергән шагыйрь иде – аны Шәүкәт абыйлар үз тиңнәре кебек күрде. Флүс Латыйпов белән Равил Вәлиевнең дә ул чакта ук язучы булуында шик булмады – алар армия хезмәте үтеп килгән егетләр иде. Арада иң яшьләре без – Роза Мулланурова, Роза Зәйнуллина (Туфитуллова) һәм мин. Кыюсыз идек, шуңадыр, абыйларыбыз безгә

Кыңгыраулы мәктәп еллары...

Кошлар да бер шулай
таралалар,
Сау бул инде, туган оябыз.
Офыкларга карап очар өчен,
Иңнәрдә без канат тоябыз.
Әйтерсең лә,
пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Күңелләрдә гомерлеккә калыр
Шушы соңгы, моңлы чыңлавы.
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Зур юлларга безне чыгардың
син,
Күңелләргә бирдең омтылыш.
Соңгы звонок булсын
беренчесе –
Син каршыла безне,
зур тормыш!
Әйтерсең лә,
пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Онытылмас,
кая юл тотсак та,
Сагындырыр таныш
чыңлавы.
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

Алда әле заман имтиханы,
Күп сынаулар әле үтәсе,
Максатларга әле ирешәсе,
Хыялларны чынлык итәсе!
Әйтерсең лә,
пар атларда үтте
Кыңгыраулы мәктәп еллары;
Киләчәккә безне озатканда
Онытылмас
дәртле чыңлавы.
Кыңгыраулы, кыңгыраулы,
Кыңгыраулы мәктәп еллары!..

күбрәк игътибар итә, иҗатка дәртләндерә. Сүз уңаеннан, Курганда йөргәндә Шәүкәт абый шул өчәвебезгә багышлап шигырь дә язган иде әле:

Өч иптәш кыз бергә йөриләр,
Алар белән бергә мин йөрим...

Бу вакытларда ул шулай безне болыннарга-тауларга алып чыгып, тормыш матурлыгын күрергә өйрәтә иде.

Сүзем 89 нчы мәктәп турында иде бит әле...

...Шәүкәт абыйны үз туганым кебек якын күргәнгә, Җәүдәт тә миңа бик якын булды, педагогик яктан дөрес булмаса да, үзем дә аңламастан, аңа аеруча игътибар иттем. Кичәләргә әзерләнгәндә яисә театр уйнаганда Җәүдәткә иң шәп роль эләгә иде.

Бер Җәүдәт кенә түгел, Шәүкәт абыйның дүрт баласы да шушы мәктәптә белем алды. Без практика үткән елны олы улы Җәмил чыгарылыш сыйныфта укый иде. Шагыйрьнең беренче баласы мәктәп тәмамларга җыена! Үзенең сөйләвенчә, Шәүкәт абый белән җәмәгате Фәридә апа өчен гаять дулкынландыргыч вакыт булган инде ул. «Кыңгыраулы мәктәп еллары» шул чорда туган, чынлыкта, Җәмилгә, аның сыйныфташларына багышлап язылган.

Бу хакта Шәүкәт абый көндәлегенә шундый юллар язып калдырган: «Җәмил бүген 10 ны тәмамлый. Кичен чыгарылыш кичәсенә бардык. Сөйләдем. Яңа язган «Кыңгыраулы мәктәп еллары» шигырен укыдым. 28 июнь.»

(Бүген мин Җәмилгә карыйм да, Шәүкәт абыйны күргән кебек булам: йөз охшашлыгын әйткән дә юк, үз-үзен тотышы, сөйләү интонациясе дә аныкы...)

Әйе, Шәүкәт абый әлеге шигырен тәүге тапкыр 89 нчы мәктәпнең соңгы кыңгырау бәйрәмендә укыды. Соңыннан шигырь җырга әйләнде – аңа Хөснул Вәлиуллин һәм Рим Хәсәнов көй язды. Җыр бөтен Татарстан мәктәпләренең гимнына әверелде. Минем үземә дә шактый еллар укытучы булып эшләргә туры килде – һәр чыгарылыш кичәбез «Кыңгыраулы мәктәп еллары» белән башлана, шуның белән тәмамлана иде. Әле дә радиодан шул җыр яңгырый башласа, үзәкләрне өзеп, Шәүкәт абыйлы еллар искә төшә. Сагындырып, юксындырып. Андый кешеләр сирәк була торгандыр ул. Фәридә апа белән алар бер бөтеннең ике яртысы кебек яшәде – шул бергәлек аларга ихлас, ярдәмчел, гади, кешелекле булып калырга ярдәм иткәндер дип уйлыйм.

Балалары укып бетереп чыккач та, Шәүкәт абыйның бу мәктәп белән арасы өзелмәде. Очрашуларга йөреп торды, «Сабантуй» балалар газетасы хезмәткәре буларак, миңа да еш кына аның янәшәсендә булырга туры килде. Үз исемендәге махсус премия булдырып, соңгы елларга кадәр чыгарылыш кичәсендә «Кыңгыраулы мәктәп еллары» җыры астында мәктәпнең иң яхшы укучыларына үз куллары белән шул премияне тапшыра иде.

Шәүкәт Галиевнең туган ягы – Апас, Кайбыч мәктәпләре дә шагыйрь рухы белән яши. «Кыңгыраулы мәктәп еллары»н алар да күптән үзләренеке итеп кабул иткән инде. Шәүкәт абыйның кызы Алсу ханым аларның чакыруларын һәрчак теләп кабул итә, шагыйрь әтисенең Бакырчы авылындагы музеенда көтеп алынган кунак ул.

Шәүкәт абыйларның тормышы балаларында, күпсанлы оныкларында һәм оныкчыкларында дәвам итә. Исемнәрен мәңгеләштереп, «Кыңгыраулы мәктәп еллары»ның буыннан-буынга тапшырылуында аларның да өлеше зур булыр дип уйлыйм.

Фото. КДУ студентларының тулай торагында («Кызыл почмак»та) әдәби укулардан соң.
Беренче рәттә: Шәүкәт Галиев, Илдар Юзеев.
Икенче рәттә: 1 нче – Мөдәррис Әгъләмов, 2 нче – Роза Зәйнуллина, 4 нче – Ләлә Сабирова.
Өченче рәттә: 1 нче – Рәшит Ягъфәров, 2 нче – Флүс Латыйпов, 5 нче – Харрас Әюпов.

PRESSA.RU



МИЛӘҮШӘНЕКЕЛӘР

Гөлнур САФИУЛЛИНА

– Мин аларга «улым», «кызым» дип шундый җиңел әйттем... Рәхәт шулай эндәшү... Кайтканнарына ничә ел булганын үзләре, бәлки, санныйдыр, мин белмим – гомер буе алар белән яшәгәнмен кебек тоела...
Күп балалы әни булырмын дип, ул, әлбәттә, беркайчан уйламаган. 1989 елны катлаулы операция кичерә: бала турындагы өметләре бөтенләй киселә. Гомер әкренләп уза. Гаиләсе җимерелә. Ул үз эченә бикләнә башлый. Уйларның төрлесе килә башка... Әле «әни», әле «мама» дип дәшкән бала тавышы ишетеп еш кына артына борылып карый: анда беркем юк... (Өйгә балалар атлап кергәч, бу тавыш тына!)
Миләүшә ГАЛИУЛЛИНАның бүген... Кызык, мин аның ничә баласы бар дип әйтергә дә белмим икән бит! Мәктәп яшендәгеләре – җидәү. Тагын... Хәер, барысын да язманы укыгач аңларсыз.
Бу балаларның кайберләре күрергә өлгергән хәсрәтне, авырлыкны, кыенлыкны олы кешеләрнең кайсысы гомер буена да күрмидер. Миләүшә әниләре шуңа күрә дә аларны яратуга күмәргә, үткәннәрен оныттырырга тырыша. Һич кенә дә зарланмый. (Ул, гомумән, зарланырга яратмый!) Тәрбиягә бала алган гаиләләр Сарман районында – 28. Бу адымга ялгызы тәвәккәлләгән кеше ул гына, ул берәү генә.
Инде үзен тыңлыйк.

Шәйхетдиновалар

– Чулпан белән Ләйсәннең әнисе минем дус кызым иде... Кадрия белән гомер буе аралашып яшәдек. Олы кызын бигрәк ярата идем, аны күрер өчен авылларына гел барасым гына килеп торды. Аннары Кадрия эчә башлады. Әйбәт хатын иде ул, бу чир аңа кайдан иярде, белмим. Бәйли, тегә иде, пешергән бәлешләре ашап туймаслык була иде... Әнисен аналык хокукыннан мәхрүм итү өчен Чулпан үзе йөрде. Аңа инде 16 яшь иде. Өйдә ашарга булмагач, балалар нишләсен?! Безне син үзеңә ал әле, диделәр. Шулай бергә яши башладык... Үзе бер тапкыр бала бакмаган ялгыз хатын кулына балаларны кем инде тиз генә тапшырсын – документлар артыннан сигез ай йөрдем. Аларны караган өчен хөкүмәт беренче тапкыр акча биргәч: «Кызлар, әйдәгез, әниегезне дәваланырга алып барабыз», – дидем. Кайттык авылга. «Кирәкми, интегеп йөрмә. Син мине инде үзгәртә алмыйсың. Әнә ул акчага балаларга берәр нәрсә ал», – диде Кадрия. Янып үлде ул... Бик әйбәт хатын иде.

Ләйсән, миңа килгәч, 5 нче класска укырга керде. Беренче тапкыр аңа кышкы аяк киеме алганны гел хәтерлим. Сайладык, үзе бик яратты, киеп тә куйды. «Кызым, искесен чүплеккә генә атып калдырыйк», – дим. Тәмам тузган, чалшаеп, кыегаеп беткән иде. «Аны әни алган иде...» – ди ишетелер-ишетелмәс тавыш белән. Әнисен никадәр яратуын шунда аңладым... Минем дә әни булырга өйрәнә башлаган гына чагым бит. «И-и, кызым, билгеле, алып кайтабыз – урамга кияргә ярар», – дим. Аларга мин кырысрак булдым. Кызлар белән, гомумән, авыррак. Малайлар белән уртак телне тизрәк табам. Үземнең дә холкым аларныкына охшагангамы соң?

Чулпан миндә ике генә ел торды. Ул кияүгә киткәндә Кадрия исән иде әле. Никахка, айнытып, аны да алып бардык, икәү янәшә утырдык. «Миләүшәгә «әнкәй» дип әйтегез», – дия иде ул... Чулпан инде үзе әни – оныкларым бар! Икенче баласын көткәндә: «Үземнең кызым туса – Сөмбел, улым туса Булат дип кушарга хыяллана идем. Каршы килмәсәң, әйдә, улыңа Булат дип кушыйк әле», – дидем. Ире, әти-әнисе белән сөйләшкән. «Син әйткәнчә булыр», – диде. «Минем Булатым кайткан!» – дип кенә торам. Чаллыда яшиләр. Хөкүмәт Чулпанга фатир да бирде инде. Ләйсәнгә дә көтәбез.

Латыйповлар

– Латыйповларны алып кайтыр алдыннан төш күрәм. Түгәрәк күл, кырыйлары ямь-яшел үлән, күлнең өсте тулы кыр үрдәге икән... Иртүк районның опека бүлегенә шалтыратам. «Сез миңа балалар бирәсез. Кыр үрдәкләре күрдем. Бер күл!» – дим. Кычкырып көлделәр: «Әйе, күп, өчәү алар, Миләүшә апа», – диләр.

Тәрбиягә алган гаилә, киемнәрен җыеп, Латыйповларны опека бүлегенә китереп куйган икән. Андагы әниләре авырып киткән. Дус кызым Ләлә ашарга әзерләп калды, мин киттем балаларны алырга. Өйдәге табынны күреп шаккаттылар. «Болар барысы да безгәме?» – диләр. Башта авыррак булды алар белән. Кулда ипи, кесәдә ипи, мендәр астында, диван артында... Ашыйсы килгәнне ашасыннар, дидем. «Эссен» кибетенә алып бардым да: «Нәрсә телисез – алыгыз», – дидем. Печенье, шоколад, сохари, колбаса... Сагыз чәйнәп рәхәтләнделәр. Аннан туйдылар. Ипине дә өстәл янында гына утырып ашый башладылар. Аш ашарга өйрәттем. Тамаклары һәрвакыт тук аларның. Хөкүмәт биргән акча, шөкер, безгә җитә. Иң элек квартплата түлим, аннары капчык-капчык он, ярма, ит алып куям. Минем балалар ризык сайланмый алай, әмма камыр ризыкларын күбрәк яраталар.

Латыйповлар уннан артык бала алар. Миндә – өчесе. Абыйлары Илдар зуррак иде инде, аны колледжга укырга урнаштырып, бүлмә бирделәр. Кызгандым... «Безгә, туганнарың янына кил, бер пешкән аш барыбызга да җитәр», – дидем. Сыйдык... Армиягә киткәнче миндә торды, инде Түбән Камадан үзенә фатир бирделәр. Кайтып йөри.

Зәйнекеләр алар. Өйләрендә янгын чыккан бервакыт. Илдарга ул вакыт 6 яшь була. «Илнурны эзләдем, тик тапмадым – кровать астына кереп яткан булган. Аны коткара алмадым, тәтенгә тончыккан иде. Лилия бишектә иде, өстенә янган чүпрәк төшеп, ул елый башлады. Мин аны күтәреп, бусага төбенә килеп утырдым. Күршеләр ничектер ишекне ачтылар», – дип сөйләде ул. Лилиянең ул чакта аяк-куллары, бите пешкән. Тәне генә түгел, йөрәге, җаны да янган бугай аның... Дөньяга ачулы ул. Сентябрьдә 18 тула аңа.

Руслан иң кечкенәләре аларның. Шунысын бигрәкләр дә яратам. «Әни» дигән сүзне иң беренче миңа ул әйтте... Мөслим районы Түбән Табын авылында, коррекция мәктәбендә укый. 2 нче класска кадәр тырышып карадык: үзем дә, укытучылар да. 12 яшьтә булса да, ул әле һаман машина белән уйный. Дөресрәге, иртән алсаң, кичкә вата. Ул ваткан уенчык инде! (Аннан зураклары да машина белән уйный әле бездә. Качып-качып. Уйнагыз рәхәтләнеп, дим. Алар бит уйнар чакта күрмәгән аны. Психолог белән сөйләштем, ул да шулай ди.) Әниләрен аналык хокукыннан мәхрүм иткәч, балаларны алырга киләләр. Шул вакыт ул, 1 яшь тә 7 айлык Русланны ләгәнгә сала да өстенә бәрәңге капчыгы бастыра. Яшереп кала, янәсе. Зәйдәге әбиләре сөйләде моны. Баланың башына шул чакта зыян килмәдеме икән?

Әтиләре үлде аларның – күмәргә бардык. Руслан аны бөтенләй белми. Әле беркөнне сорый: «Кешенең ике әнисе буламы?» – ди. «Әйе, була, берсе – яшь, икенчесе – карт», – дим. «Ул безне нигә ташлаган?» – ди. «Күрәсең киләме, әйдә, алып барам, улым?» – дим. Бер көн буе уйлап йөрде, аннан: «Юк, әле барасым килми», – диде.

Латыйповлар да миңа барысы да «әни» дип дәшә. Класс җитәкчесе: «Миләүшә апага әйтегез әле, килеп китсен», – дигәч, Илнур: «Нишләп «апа» дип әйтәсез, ул бит безнең әни», – дигән.

PRESSA.RU

Туган көннәренә һәрберсенә яхшы телефон алам – кимсенеп үсмәсеннәр. Акча салып торам. Алар үзләре сорамый. Балалар, гомумән, бернәрсә дә сорамыйлар. Бервакыт кибеттән шалтыраталар: «Руслан 5 мең акча тотып килгән, үзең җибәрдеңме?» – диләр. «Нәрсә сорый – бирә торыгыз, хәзер килеп җитәм», – дим. Кайттык та кулларын төйдем. Моны берәүдән дә курыкмыйча әйтәм. «Икенче кагылмассың, мин бур малайларны яратмыйм. Үзеңә авыр булыр – моннан соң сорап кына ал», – дидем. «Аңладым, әни», – диде. Мин аларны яклап әллә кайларга барып җитә алам (җитәм дә!), әмма гел-гел яннарында булмам бит. Кайчак шактый кырысланырга да туры килә. Бигрәк тә кайткан мәлләрендә. Барысына да әйтеп куйдым: «Урламыйсыз. Кеше әйберенә кагылмыйсыз. Хәер сорашмыйсыз. Нидер кирәк булса, кайтып әйтәсез, акчам булмаса да, алып бирермен».

Балаларыңны ник эшләтмисең, диючеләр бар. Район үзәгендә торабыз – монда нинди эш бар соң? Кышын кар көриләр. Идән юалар. Бәрәңгене дә алар белән бергә эшләдек. Бала гына бит алар, уйнасыннар рәхәтләнеп.

Латыйповларны алып кайткач, барыбыз бергә әни янына чыктык. Аръяк урамда тора ул. «Әни, менә бу балалар минекеләр, абыйныкыларны ничек яратсаң, аларны да шулай якын ит», – дидем. Әнием Зөлифә үзе дә җиде айлык килеш ятим калган, аны апалары үстергән. Сиксән яшьлек әниемә ипи-сөтне кибеттән шушы балалар алып кайта. Аның янына кунарга чыгалар. Әби, дип яратып торалар. Туган көннәре җитсә, чәй куеп, әни аларны үзенә чакыра.

Минаевлар

– «Җәлилдәге бер хатынның ике малаен кая куярга белми интегәләр. «Не управляемые», диләр. Алай булса, Миләүшәнеке инде алар, дидем», – ди Зәния. Берсут приютыннан аның белән бергә барып алдык малайларны. Бик акыллылар алар...

Башта әниләрен сагындылар. Адель, мәктәптән кайткач, гел үзен кочаклап йөреп тора, сөйләшми иде. Тәрәзәдән карап гел әнисен көтте. Кечкенә әле ул, быел 4 нче класска гына бара. «Улым, әйдә, әниеңә шалтырат», – дим. Бик куанып шалтыраткан иде, шунда ук телефонны ташлады: «Ул исерек», – ди. Ул арада әниләре үзе шалтырата башлады. Адель миңа ялына: «Алма телефонны!» – ди.

«Кил, апаем, атна саен килеп йөр. Мунчалар кереп китәрсең», – дидем әниләренә. Җәлил бистәсе монда гына бит. Айгөлләрнекенә дә әйттем, Чаллыдан барып каршы алырбыз, дидем. Күренгәннәре юк...

Әле бер таныш хатын: «Минаевларның әниләрендә яман шеш икән. Балаларын күрәсе киләдер инде. Хәлен белеп кайтмыйсызмы?» – диде. Олысы Илмир 13 яшьтә, аңлый, аңа әйтәм: «Башта икәү барып кайтыйк, улым. Адельгә әлегә белгертми торыйк. Әниең чынлап та авырса, аннары бәхилләшергә алып барырбыз», – дим. Башта карышты, «Әти-әнине сайлап алмыйлар, улым. Барырга кирәк», – дигәч кенә ризалашты. Күчтәнәчләр алып киттек. Тик ишекне ачучы булмады. Күрше әбисе чыгып: «Исерек ул», – диде... Өч көннән соң гына шалтыратты Роза, исерек иде, малайлар сөйләшмәделәр. Кыйнаган ул аларны, куркалар... Танышкан булсак та, минем исемне хәтерләми, гел төрлечә дәшә Роза. «Адель сиңа да чәчәкләр алып кайтамы?» – дип сорый берсендә. Әйе, кечкенәсе язын мәктәптән кайтканда гел сары чәчәкләр җыя. «Әни, бу сиңа!» – ди. Кайта, киемнәрен салып, пөхтә итеп элеп куя һәм... тузан суыртырга тотына. Без аңа «Золушка» дибез. Үткәннәре турында сирәк сөйлиләр алар. Бөтенесе дә. «Әни ире белән ятып йоклый, ә безгә гел өйне җыештырырга куша иде», – ди Адель. Куллары шундый кечкенә аның – ничек эшләгәндер, балакаем. Бавыры ярык Адельнең. 3 яшьлек чагында әнисенең энесе стенага сылаган. Шаяра башласалар да: «Адельгә тия, кагыла күрмәгез», – дип кенә торам. Аның өчен бик куркам. Елый башласа, туктамый ул... «Мин ул хәлне хәтерлим», – ди. «Оныт, улым», – дим аңа. Ә болай минем балалар авырмыйлар алар. Салкын тиюнең ни икәнен дә белмиләр. Чыныкканнар...

Галләмовлар

Сүзебезгә районның опека һәм иганәчелек органы өлкән белгече Зәния Вафина кушыла:

– Миләүшәнең: «Тәрбиягә бала алырга телим», – дигән гаризасы ята иде, чираты җитте дә безне Казанга, тәрбиягә алу үзәгенә чакырдылар. Иртәнге сәгать өчтә районнан чыгып киттек, дүрт сәгать юлда булдык. Барсак: «Балалар Сабада, приютта, компьютердан фотоларын карыйсызмы?» – диләр. «Карамыйм, мин аларны сайлап алырга җыенмыйм», – ди Миләүшә.







Шуннан туры Сабага чыгып киттек. Мин инде борчылам: «Шулкадәр юл килдек. Балалар Миләүшәгә ошамаса, нишләрбез?» – дим. Приютка барып җиттек. Айгөл белән Ранис кадетлар мәктәбендә укый икән, алар дәрестә булып чыкты. «Кием-салымнарын җыеп чыгарыгыз», – ди Миләүшә. «Башта аларны карамыйсызмыни?» – дип аптырап, ярты пакет кием тоттырдылар. Ияртеп чыкты балаларны мәктәптән Миләүшә, машинага кереп утырдылар, кайтабыз. Бер-ике сәгать кайткач, Айгөлгә кемдер шалтыратты. «Кая барасыз?» – дип сорады, ахрысы, ул: «Домой едем, к маме», – дип җавап бирде... Миләүшә телефоннан дус кызы Ләлә белән сөйләшеп алды: мунча якканнар, манты пешкән, өйдә көтәләр икән. Кайтып туктадык. Балалар йөгереп чыкты – бар да Миләүшәне килеп кочаклый, үбә. Ә бу яңа ике бала, пакетларын күтәреп, шыпырт кына өйгә кереп киттеләр... Бер-ике көннән ВКонтактеда Айгөлгә язам, әниегез ничек, дим. «Мама у нас клевая!» – дип җавап бирде...

– Айгөл белән уртак телне тиз таптык: күз карашыннан аңлашабыз, – дип дәвам итә Миләүшә. – Тыңлый, урамга чыкса, вакытында кайта, алдашмый, бөтенесен сөйли. Аның белән холыкларыбыз охшаш.

Айгөл белән Ранисның Кукмарада фатирлары бар. Ай саен алар өлешен түләп торабыз. Айгөлнең анда кайтасы килми, бәлки, Кукмарадагысын сатып, Чаллы ягында фатир алып булыр. Әтиләрен сагыналар алар... Әни дип исләренә төшермиләр. Салган чакта шалтырата да кызына пычрак сүзләр кычкыра. Соңгысында Айгөл: «Гөлфия апа, сез нәрсә сөйлисез?!» – диде... Әни, дип дәшәсе килми бугай. Ул аны пычаклар белән куып йөргән...

Зөлфия

– Бервакыт карыйм: урамнан безгә таба бер бала кочаклап Зәния килә. «Кем бу?» – дим. Яшүсмер кебек кенә күренсә дә, Зәния кочагындагы кыз инде бала булып чыкмады.

1996 елны Зөлфияне Сарманнан Алабуга балалар йортына тапшырган булганнар икән. Үсеп, яше җиткәч, ул аннан чыгып киткән. 2014 елны гына шушы кызны Алабугалар фатирга чиратка куярга эзли башлаганнар. Абыйсына фатир безнең район аша бирелгән булгач, Сарманга мөрәҗәгать иткәннәр. Зәнияләр аны милиция аша эзләргә керешкәннәр. Инде 15 ел бомжлар белән подвалда яшәп яткан икән Зөлфия. «Таптык, алып кайттык, инде нишләтик?» – дип Алабугага шалтыраткач, алар: «Үзегезгә пропискага кертә алмыйсызмы?» – дигәннәр. «Минем бер генә вариантым бар», – дип, Зәния аны миңа алып килгән. Нигә кертмәскә, сигез янына тугызынчысы сыяр дип, керттем пропискага. Бөтен документларын җыеп, фатир чиратына куйдык...

Марат

– Мин опека органында эшли башлагач, тәрбиягә бала алган бер гаиләдә күңелсез хәл чыкты, – дип сөйли Зәния ханым. – «Мине кыйнап эшләтәләр», – дип, бала «Пусть говорят»ка шалтыраткан. Мәскәүдән, тапшыруга чакырып, электрон билетлар килеп төште... Бала, өйгә кайтмыйм, кыйныйлар, ди. Әнисе: «Тырнак белән дә чиерткәнем юк», – ди. Ул аны 6 яшьтән алып үстергән. Тикшерә башладык, экспертиза үткәрдек – тәндәге бәрелүләрнең бик күптәнге булуы ачыкланды. Егет, киемнәрен җыеп, опека бүлмәсенә килеп утырды... Кая куярга? 16 яшендә аны инде бер гаилә дә тәрбиягә алмаячак. Балалар йортыннан балаларны алып бетерергә дигән карар чыккан вакыт – анда да тапшыра алмыйбыз. «Пропискага гына керт Маратны. Югыйсә фатирсыз кала. Мин аңа әлегә колледждан бер бүлмә сорап карыйм», – дим. «Бүлмә сорама, бездә генә торыр», – ди Миләүшәм.

Халык театрында уйнап йөри бүген Марат. Тормышта да артист ул. Шуңа да бөтенебезне ышандырды. Авылда ике гаилә үзара сүзгә килгән булган. Ә ул, аларның уллары белән дуслашып, үзен тәрбияләүчеләргә каршы чыккан.

– Маратка инде 20 яшь. Аграр колледжда укып йөри. Кулы эш белә аның. Кыш көне бөтен оешмаларга боздан сыннар ясый – акча эшли. Яңа елга балаларның һәрберсенә бүләкләр ала. Ишегалдындагы такталарны күрәсезме? Ул алып кайтты. «Сарай салам. Туган көнеңә миннән бүләк булыр, Миләүшә апа», – ди. «Кирәкми, улым», – дим. «Минем әле бу йортка кайтып керәсем бар», – ди...

Шулай... Документта «әни» булу вакыты чыгу, бу вазыйфадан туктау дигән сүз түгел бит әле ул. Анықылар инде бу балалар, гомергә аныкылар. Руслан әнә әнисе янынннан бөтенләй китмәскә җыена. Кәҗәләр алырга, ике катлы йорт төзеп, әнисен өске катта гына яшәтергә хыяллана ул. Матур хыял!







PRESSA.RU



ОЛА, ИСПАНИЯ!

Җәйге ял турында сүз чыккач, гаиләдә караш икегә бүленде: берәүләр җылы диңгездә коенуны хупласа, икенчеләребезгә ят шәһәрләр, чит мәдәният белән танышуы ошый булып чыкты. Ахыр чиктә, алтын урталыкта тукталдык. Безне Испания – кояшы да, диңгезе дә, бай мәдәнияте дә булган, алай гына да түгел, ачык һавадагы тарихи музей дигән исем белән халык теленә кергән – мавыктыргыч ил үзенә дәште.



Айгөл ӘХМӘТГАЛИЕВА

«Маньяна» дия-дия...

Казаннан Барселона аэропортына килеп төшүгә, үзебез тукталасы Салоу шәһәренә юл тотабыз. Андагы пляжларның Европада иң яхшылардан саналып, алтын яр буе дип аталуын да, сыйфаты һәм куркынычсызлыгы буенча иң югары стандартларга җавап биреп, халыкара Зәңгәр флагка ия булуын да ишетеп белә идек. Урта диңгезнең фирүзә чиксезлеге белән күзгә-күз очрашуга, барысы да әһәмиятен җуйгандай тоелды. Шулай да ниятебез көне-төне су буенда яту түгел, өлгерә алганча барысын күрәсе-беләсе дә килә! Корридалары, дәртле биюләре аша испаннарны кызу канлы итеп күзалласак та, экскурсовод кызлар исә аларны «сабыр, тыныч, артык пошмас» дип сурәтләде, яраткан сүзләре дә – маньяна, ягъни иртәгә дигән сүз икән. Теләсә нинди эшне, иртәгә-иртәгә ди-ди, атнага, айга сузарга мөмкиннәр, ахыр чиктә ул «маньяна»ның бөтенләй булмавы да бар. Пошмас диюләре хактыр: затлы машинадан төшеп, гаиләләре белән тротуар өстендә ашъяулык җәеп ашап утыручылар да, агач күләгәсендә, чирәмдә, эскәмиядә йоклап ятучылар да (бомжлар түгел!) җитәрлек, аркылы атлап чыксаң да исләре китми... Мин үзем биредәге халыкны чегәннәр кебек каракучкыл тәнле, ут карашлы дип күз алдына китергән идем, төрлесе бар: гасырлар дәвамында катнаш никахлардан кемнәр генә тумаган. Озынча йөзле, римлыларча туры яки бераз бөкрерәк борынлы, кара чәчле, каракучкыл тәнлеләр дә, саргылт чәчле, зәңгәр күзлеләр дә, сумала шикелле кап-каралар да җитәрлек. Кармен, Исабель, Диего, Федерико кебек исемнәр белән бергә, мөселман исемнәре дә еш очрый, аеруча Мөхәммәт исеме киң таралган. Гарәпләрнең VIII гасырда ук Испаниянең көньягын яулап алулары да, безнең заманда Марокко, Сирия, Ливан кебек илләрдән эмигрантларның агылуы да моңа бер сәбәптер.

Сервантес иле серләре

Кемгә нәрсә, кәҗәгә кәбестә дигәндәй, минем үземә Испания, иң беренче чиратта – балачактан ук Дон Кихоты белән күңелне иләсләндергән Сервантес иле; Тинчурин театрында язын гына карап кайткан «Өметсез хыяллар» («Бернарда Альба йорты») хуҗасы Гарсиа Лорка иле. Эрмитажда испан рәссамы Пабло Пикассоның кубизм юнәлешендә иҗат ителгән картиналарына, аңларга тырышып, бик озак карап торганым бүгенгәчә хәтеремдә. Сальвадор Дали хатыны, аның иҗатына канат куючы Галаның – Елена Ивановна Дьяконованың Казан кызы икәнлеге турында укыганнарым истә. Архитектор Гаудиның могҗизалы йортлары турында тапшыруларны йотлыгып караган идем. Әйтерсең, нәкъ шушы шәхесләр йөргән сукмаклардан узачакмын – шуны күзаллап, эчем кытыклана... Улыбыз да, кызыбыз да инглизчә яхшы белгәч, аларга салынырбыз дигән идек, чөнки сәламләшү сүзе булган «ола!»дан башлап, испанча өйрәнгәнебез йөз сүзгә дә тулмый. Ни гаҗәп, анда русча белмәгән бер кеше дә юк диярсең. Курорт зонасы булгач, ихтыяри-мәҗбүри өйрәнгәннәр, күрәсең. Чөнки һәр турист, аңа күрсәтелгән якты йөз – акча чыганагы. Кибеткә керәсеңме, кафегамы, урамда сорау бирәсеңме – синең Россиядән икәнеңне ни хикмәт беләндер шунда ук танып, вата-җимерә булса да русча аңлата башлыйлар.



Таррагона шәһәре б. э. к. II гасырда ук гладиаторлар сугышына, театраль күренешләргә шаһит булган. Рим амфитеатры калдыклары, XII-XIV гасыр дәвамында төзелгән кафедраль соборның гаҗәеп архитектурасы, лабиринтны хәтерләткән тар урамнары күңелне әллә кайларга алып китә.

Гәрәбә комлык, көләч кояш, җылы диңгез – бернинди статуслары да кирәкми...

Кайбер урамнар тар гына түгел, коточкыч тар, машина да, җәяүле халык та, мотоциклда йөрүчеләр дә бик күп – ник бер авария күренсен! «Зебралар» янында без, гадәттәгечә, башта уңга-сулга каранып, икеләнеп торсак, тора-бара күнектек: машиналар җәяүле ул сукмакка аяк басканчы алдан ук туктый, иркенләп юл бирә. Юл тамгасы «40» дип күрсәтә икән, бер шофер да шул тизлекне арттырмый, чөнки 41 гә генә җиткерсә дә, ул 100 евро штраф түләргә тиеш, ә 60 ка житсә – 300 евро. Белмим, штрафларның шулай саллы булуы йөгәндә тотамы андагы халыкны, әллә инспекторларның, бернинди агач артына, чокырга посмыйча, иң күренә торган урында кукраеп басып торуы сәбәпме, әллә үзләренең эчке культурага ия булуымы...

Каталониягә килә калсагыз, һичшиксез, күреп калырга кирәк урыннар бихисап. Шуларның берсе – Таррагона шәһәре. Ул – тарих белән бүгенгенең, киләчәкнең янәшәлеге, бергәлеге. Борынгылык янәшәсенә, шушы стеналарга терәп диярлек салынган заманча йортлар, ул йортларның балконында җилфердәгән Испания әләмнәре, шундый горурлыкка, патриотизмга ия халкы сокландыра. Биредә ике елга бер тапкыр шундый фестиваль – тере кешеләрдән замок төзеп, командалар арасында ярышу үткәрелә икән. Мондый ярышларда һәлакәтләр дә булып тора диделәр. 100-500 ләп кеше, берсе өстенә икенчесе ба-

PRESSA.RU





■ Шәһәр үзәгендә, тере кешеләрдән замок төзү фестивален багышлап, бронза һәйкәл тергезгәннәр, ул 219 скульптураны берләштерә.

■ Порт-Авентура паркы Европаның Диснейленды санала, аның белән тулысынча танышып чыгу өчен бер түгел, әллә ничә көн кирәк!



сып, әллә ничә катлы йорт биеклегендә башня булып калыксын әле. Моның өчен хәтта махсус мәктәпләрдә укыталар! Ла Пинеда шәһәрчегендә наратларга куелган һәйкәлне күрү йөрәккә май булып ятарлык. Ни дисәң дә, нарат безнең урманнарның да күрке бит. Испанчадан el pino – «нарат» дип тәрҗемә ителә икән, шәһәрнең исеме дә Урта диңгез буенда үскән наратларга бәйле рәвештә сайланган.

Шәһәр урамнары шундый тар!

Утыз секунд кына!..

Коста-Дораданың туристик башкаласы саналган Салоу шәһәрендәге Порт-Авентура паркына бармый калу – Парижда булып та, Эйфель манарасын күрми кайтуга тиң. Аттракционнар паркы бездә дә юк түгел, әмма биредәге Кытай, Мексика, Кыргый көнбатыш, Урта диңгез, Полинезия, Феррари-парк дип бүленгән тематик зоналар һәрберсе аерым бер әкияти ил кебек, һәм аларны бары тик Порт-Авентурада гына күреп була. Паркны төп оештыручыларның берсе – Голливудның атаклы Universal Studios кинокомпаниясе икәнен әйтсәм, мондагы фантазияне күз алдына китерү артык кыен булмас. Биредә джунглилар да, бөтерелеп аккан елгалар да, кап-караңгы лабиринтлар да, сабый баладан алып сакаллы бабайны утыртып әйләндерерлек йөз метр биеклектәге «таулар» да җитәрлек. Улым бик каты кыстагач, «30 секунд кына әйләнә ул», дигәч, батырлыгымны җыеп, мин дә иң «көттә» саналган аттракционга менеп утырдым. Аның 135 км/сәг. белән җилдергәнен дә, су өсләреннән баштүбән әйләндереп килгәнен дә соңыннан гына белдем, чөнки утыз секунд эчендә бер генә мәртәбә дә күземне ачарга өлгермәгән идем... Паркта бер күренеш күзгә чалынды: һәр аттракционга утыруның үз таләбе бар, буең фәлән метрдан, фәлән сантиметрдан ким йә артык булырга тиеш түгел! Махсус үлчәп торалар, бер сантиметр җитми йә арта икән, ялын-ялынма, һичкемне үткәрмиләр! Һи-и, бездә булсамы, «ярар инде», дип, кеше хәленә керми калмаслар идеме... Биредә һәр тематик зонада төрле кызыклы тамашалар да оештырыла: нәкъ боевик фильмнарындагыча, бер-берсен чәеп сугышучы испан мачоларын да, утлы таяк белән биюче папуасларны да күрергә була.

Ah! Барселона!..

Барселона – Испаниянең иң затлы шәһәрләреннән берсе. Аның архитектурасы сокланып туймаслык! Пассеч-де-Грасия бульвары белән Каррер-де-Провенса урамы киселешендә торган Мила йорты – бер генә дә почмагы булмаган, дулкынны хәтерләткән гаҗәеп корылма! Кайчандыр магнат Пере Мила-и-Капс һәм аның хатыны Гаудидан үзләренә бөтен кешене шаккаттырырлык йорт төзеп бирүне үтенгәндә, мондый ук могҗизаны күзалдына китермәгәннәрдер... Һәр ташны, һәр кирпечне, һәр бизәкне табигатьнең бер өлеше итеп күрсәтергә яраткан Гауди гомеренең 43 елын Саграда Фамилия храмы төзелешенә багышлый.

Каталония мәйданында урта гасыр эзләрен саклаган, кәкре, тар урамнары белән дан тоткан Готик квартал да, тирә-яклап тезелеп киткән сәүдә үзәкләре дә урнашкан. Сүз уңаеннан, Massimo Dutti, Pull and Bear, Oysho, Zara Home, Uterqüe, Stradivarius, Lefties һәм Bershka кебек брендларның төп хуҗасы – испан магнаты Амансио Ортеге. Mango сәүдә челтәренең дә «туган җире» – Испания. Шушында ук адым саен кафе-рестораннар да тезелгән, хәләл кафелар да бар. Өчпочмакбәлешкә ияләшкәннәр өчен испан кухнясы сәеррәк тә тоелырга мөмкин.

Үгезләр сугыштырып, помидорлар атышып...

Испаннарның сиеста, фиесталары безнең өчен шактый гаҗәп тоелды. Сиеста – төшке аштан соң ял, йокы вакыты, һәм ул өчәр сәгатькә сузыла, көндезге 1 дән 4 кә яки 2 дән 5 кә тиклем кибетләр, аптекалар, банк-



■ Каталония мәйданы – Барселонаның «Кызыл мәйданы» ул.

■ Саграда Фамилия храмы 1882 елда төзелә башлый, һәм ул бүген дә төзелеп бетмәгән. Бу могҗиза янынан ел әйләнәсе туристлар өзелми, аның янында сәгатьләр буе сокланып торырга була.



лар да бикләнә. Тик туристлар күп йөри торган урыннарда хәзер сәүдә үзәкләре бикләнергә ашыкмый икән – Барселонада без алай бикле ишеккә тап булмадык. Фиестага килгәндә, ярым шаяртып, испаннар – атнасына җиде көн күңел ача торган халык, диләр. Кем ничектер, мин үзем, мәсәлән, корриданы акыл белән аңлый да, кабул да итә алмыйм. Кан коешны, кешене йә үгезне канга батыруны ни рәвешле ләззәтләнеп тамаша кылырга буладыр? Гасырлар буена килгән бу традициягә хәзер нокта куелган, Каталониянең региональ парламенты корриданы тыю турында карар чыгарган. 2011 елдан бирле Барселонада үгезләр сугышы уздырылганы юк... Буньоль шәһәрендә үткәрелүче Ла-Томатина фестиваленә элэгергә теләр идегез микән? Мәйданга җыелган халык бер-берсенә помидор ыргытып кинәнә, бу «сугышта» 145 тонналап помидор «һәлак» була... Ярый әле, уен шарты буенча, помидорны шешәгә салып атарга ярамый; үзен дә, артык каты эләкмәсен өчен, бераз сытып ыргыту хәерлерәк... Томат пюресына баткан халык та, урам да, шул урамны юарга килгән янгын сүндерү машиналары да кызганыч булып китте. Үзләре бөтен җиргә «Су – Испаниядә кыйммәтле ресурс, әрәм-шәрәм итмәгез!» дип язып куйганнар. Испания үзе дә шактый кыйммәтле ил, гади генә бер шешә суны да кимендә 1 еврога сатып аласың.

Базарлары төн буе эшли, испан, һинд сувенирларының җаның теләгәнен сайларга була. Безнең Россия туристлары зәйтүн мае, испан виносы, дуңгыз ветчинасы – хамон күтәреп кайта.

Барселонага килгәч, җырчы фонтаннарны тамаша кылу зарур. Кичен салават күпере кебек балкыган матурлыкны күрергә әлеге мәйданга халык агыла, аяк басар урын табу да кыен. Чегән кызларының аллы-гөлле итәкләрен хәтерләткән төсләр кушылмасы, әле дәртле, әле моңсу яңгыраган көйләр, янәшәдәге пальма, әфлисун, зәйтүн агачлары, төнге шәһәрнең мең төскә кергән балкышы, кул сузымы гына булган диңгезнең җиләс җиле җанны иркәли. Әйе, Испания – кичен дә

Алар бәйрәмнәр ярата! Әле ниндиен: дәртле, ярсу, канны кайната торганын!

кояшлы, матур, якты, бай ил. Әлбәттә, бу матурлыкта туризмнан агылган акчаларның өлеше бихисаптыр. Аерым берәүләрнең генә түгел, гади халык мәнфәгатьләрен кайгыртырга да җитәдер. Өметсез – шайтан, ди. Кем белә, бәлки кайчан да булса безгә дә Европа дәрәҗәсендәге мәдәният килеп җитәр әле. Әнә бит, Казан инде күз өстендәге кашка әйләнде, шул матурлыкны күрә һәм аңа соклана белергә генә кирәк. Аннан соң, бәлки, испаннар кебек ачык йөзле булырга, елмаерга, үз милләтебез, тарихыбыз белән горурланырга да өйрәнер идек...

РИЗЫК



■ Балыкны җаның теләгәнен ашарга була. Кысла, креветка, моллюск яратканнарга тулы ирек, «гамбас ахийо» дип китерсәләр – сарымсак белән кушылган креветканы, паэлья бирсәләр – дөге, кишер, моллюсклардан әзерләнгән пылауны авыз итә аласың. Испаннарның яраткан ашы – помидор «шулпасы» гаспачо белән сыйланырга мөмкин. Тик помидор, суган, сарымсак, уксус кушып әзерләнгән салкын аш токмачлы кайнар шулпаны алыштыра алмый инде...

PRESSA.RU

16+

ХАТЫН-КЫЗ ТИРӘНРӘК УЙЛЫЙ



Рушат СОЛТАНОВ,
Татарстан халыклары ассамблеясенең Мөслим районы вәкиллеге җитәкчесе.
гаилә стажы – 37 ел;
3 бала атасы.

**Ир-ат һәм хатын-кыз. Бер үк галәмгә без бит очраклы гына эләкмәгән... Шулай булгач, нигә соң бер-беребезне күп вакыт аңламыйбыз? Гамәлләребезне, теге яки бу адымыбызны, әйткән сүзләребезне... Үзара тартылуны «җиңеп», арага каршылыклар керә дә куя...
Ә ир-атлар үзләре бу хакта ни уйлый икән?
Сүзне аларга бирик.**

1 Иң элек хатын-кызның нәрсәсенә игътибар итәсез: киеменә, буй-сынына, күзләренә, чәченә...

– Безнең чорда кешенең өс киеменә карау дигән нәрсә бөтенләй юк иде. Булачак хатыным белән ике арадагы җылы хисләр дә аралашудан соң туды. Ә гомумән алганда, хатын-кызның киеменә дә, буй-сынына да, йөз-кыяфәтенә дә күз төшми калмый инде. Бар җире дә килсә, күңелгә, әлбәттә, хуш килә.

2 Нәрсә өчен бик якын хатын-кызны да гафу итмәс идегез?

– Хыянәтне. Бу хакта җәмәгатемнең үзенә дә әйткәнем бар. Мин, гомумән, кешеләрдә өч нәрсәне кабул итә алмыйм: хыянәтне, алдашуны, икейөзлелекне. Ә чынлыкта, әйткәнемчә, бу дөньяда гафу ителмәс бер нәрсә дә юк. Вакыт белән, хәлләр үзгәрү белән барысы да гафу ителергә тиеш. Дин дә шулай куша. Җәмәгатем мин гафу итмәслек хәлләрне беркайчан да тудырмады. Безнең тормышта минем бәгыремә тигән бер нәрсә дә булмады.

3 Ир кеше өчен аның хатыны дус та була аламы?

– Әйе, иң беренче чиратта дус әле ул. Гаиләгә ял итәргә кайтасың: йә сиңа шатлыгыңны уртаклашырга кирәк, йә борчуың булганда, аны сөйләп, күңелне бушатырга. Иртәнгә башың ял иткән, күңелең тынычланган килеш эшкә чыгып китәргә тиешсең. Шуның өчен дә, әйткәнемчә, хатын ир кеше өчен дус та, сердәш тә, кайвакыт киңәшче дә.

4 Хатыныгызга ничек тәкъдим ясаганыгызны хәтерлисезме?

– Минҗиһан безнең бер туганнарга кунакка кайтып йөрде. Мөслимдә төзелеш оешмасында штукатур-буяучы булып эшли иде ул. Мин инде бу вакыт армиядән кайткан, читтән торып институтта укыйм, мәктәптә география укытам. Безнең Яңа Карамалы авылы бик матур җирдә урнашкан, урман эчендә. Минҗиһан ялга кайтканда чаңгыда йөрергә чыга идек. Ниһаять, өйләнергә карар кылдым. Минҗиһан бу вакытта инде Чаллыда эшли иде. Без Мөслимдә очрашырга һәм аның авылына бергә кайтырга тиеш идек. Ә ул, транспорт шулай туры килгән дә, Минзәлә аша кайтып киткән. Көттем-көттем дә, Каенсазга үзем генә киттем. Минҗиһан түр якта өй җыештырып йөри. Верандада табын әзерләгәннәр. «Кызыгызның кулын сорарга килдем», – дидем әтиәнисенә. Өстәл янына Минҗиһанны да чакырдылар. 1980 ел бу. Июнь ае. Җәйге сессиягә киткәнче, әткәй һәм әнкәй белән Минҗиһаннарга барып, туй көнен билгеләргә дә өлгердем. 8 август көнне өйләнештек. Туйга кадәр өч көн, өч төн тоташ яңгыр яуды. Авылда юл юк, урамнар пычрак – машина үтә алмаячак. «Җәүдәт малае хатынны трактор белән сөйрәтеп алып кайтты», – дип көләрләр инде дим. Иртәгә туй дигән көнне кичке якта яңгыр туктады, җирләр кипте: бәлагазасыз гына өйләндем. Ул чакта туйларны колхозның партком секретаре алып бара иде, нигәдер килә алмады – эштән бушамагандыр инде. Башлангыч класс укытучым Мөсәлим абый алып барды мәҗлесне. «Җидегән чишмә» җырының бик популяр чагы бу. Минҗиһан ягыннан туганнар бар да ул җырны белә: безнең туй табынында өч көн буена шушы җыр яңгырап торды. Бу җырны ишеткән саен, хәзер дә өйләнешкән вакытлар искә төшә.

5 Хатыннары ирләреннән күбрәк мал тапкан гаиләләр бар. Ир кеше бу очракта үзен ничек тотарга тиеш?

– Катлаулы хәл, әлбәттә. Әгәр дә инде хатын-кызның тәрбиясе бар икән, ул: «Сине мин ашатам», – дип, ир-ат күңеленә җәрәхәт салып тормый. Чөнки гаиләдә ирнең акча белән бәяләп бетереп булмый торган үз роле бар.

Мондый хәл үзебезнең гаиләдә дә булды. Мин мәгариф бүлеге җитәкчесе булып эшләгәндә, җәмәгатем акчаны миннән 200 сумга артыграк алды. Икеме, өчме ел дәвам итте бу: идарә хезмәткәрләренә акча артмый, ә тәрбиячеләрнеке күтәрелә иде. Дуслар җыелган җирдә: «Мине хатын туйдыра», – дип шаярта идем.

6 Гашыйк булуын хатын-кыз башлап үзе белдерүгә ничек карыйсыз?

– Әгәр хатын-кызның хисләре чыннан да ихлас икән, моңа әйбәт карыйм. Тора салып, урамда беренче очраган кешегә әйтми бит ул аны. Күңеле белән сизә. Ир-атның күзе, йөзе аңлата битараф түгел икәнлеген, тик ачылырга гына кыюлыгы җитми. Ә нигә әйтмәскә? Вакытында аңлаша алмаганга күрә генә бер-берсеннән читтә гомер иткән, гомер буе үкенеп, берсен-берсе яратып, сагынып яшәүчеләр турында белмибезме әллә?! Чын ярату икән, әйтүнең гөнаһысы юк.

7 **Хатын-кызларны ир-атларда иң беренче чиратта нәрсә җәлеп итә дип санийсыз?**

– Безнең чорда кызлар бәдәнле егетләргә битараф түгел иде. Тыйнаклык, әдәплелек беренче урында иде. Хатын-кыз ир-атка караганда да төптәнрәк, нечкәрәк уйлый – тагын күп нәрсәләргә игътибар итә торган булганнардыр. Ә бүгенгеләр кесәсе калыннарга карый, диләр. Дөрес бугай. Бер танышымның улы бер кыз белән очраша иде. Өйләнешергә ниятләре барын да белә идем. Әле күптән түгел күрештек тә, сорыйм: «Өйләнмәдеңмени?» – дим. «Безнең фикерләр аерылды әле», – ди. Аерым фатирың да юк, синең әти-әниең белән торырга җыенмыйм, дигән икән кыз. Тормыш авырлыгын бергә кичерсәң, мәхәббәт ныграк та була да бит...

8 **Хатын-кызларның үзегезнең кайсы якларыгызга игътибар итүне көтәсез?**

– Хәзер миңа бу сорауга җавап бирү читенрәк. Яшьлек үткән бит инде. Мин холкым белән бик аралашучан, ачык кеше. Теләсә кайсы компаниягә кереп китәм. Сөйләшми торган кеше булса да, сүз катам, сөйләштерәм. Үзем дә ачык кешеләрне яратам.

9 **Ир-ат белән хатын-кыз икесе ике галәмнән икәне билгеле инде. Кайчакларда аларның бер-берсен аңламаулары шуннан килеп чыга да.**

– Ике галәмнәндерме, түгелме, белмим. Әмма ир белән хатын арасында фикер каршылыклары булу табигый. Чөнки икең ике гаиләдә тәрбияләнгән, гаилә традицияләре үзгә, белем дәрәҗәсе төрлечә, шушылардан чыгып, теге яки бу ситуацияне аңлау, кабул итү дәрәҗәсе, әлбәттә, бер-берсеннән аерыла. Шуңа күрә, кайчакта килешмәсәң дә, ризалашырга туры килә.

10 **Хаклы икәнегезне яхшы беләсез, әмма хатынызның үз туксаны – туксан, хаклык аның ягында дип саный.**

– Минем хатынның бик әйбәт сыйфаты бар: ачуланышканда ул каршы дәшми. Бер-ике сүз әйтсә – әйтә, әйтмәсә – юк. Никадәр кызган булсаң да, кеше сиңа каршы әйтмәгәч, туктыйсың. Аннан безнең «үз туксаны туксан» итәргә вакыт та булмады: һәр көнне иртәнге 5 тә чыгып киттем, кичке 9 да, 10 да гына кайттым. Гомер буе! Сәгать җиделәрдә үк кайтсаң: «Ни булды, нигә иртә кайттың?» – дип аптырыйлар иде.

11 **Шундый очракны күзаллыйк әле: Сез, ачыгып, арыпталып эштән кайтып керәсез, ә өйдә ашарга пешмәгән. Хатыныгыз, арыдым дип, диванда кырын ятып тора.**

– Безнең әткәй үзе бер чынаяк чәй дә ясап эчмәде – гел әнкәй ясаганны көтте. Калагы булмаса да, әткәй барып алмый, аны әнкәй китерә иде. Бу мәсьәләдә мин үзем бабайдан – Минҗиһанның әтисеннән үрнәк алдым. Ул Татарстанның атказанган механизаторы иде, колхозда механик булып эшләде. Бабай көн саен иртүк нәрәткә чыга, әмма әбине уятып, чәй әзерләтеп тормый иде. Бер чынаяк чәй өчен нигә хатынны уятырга? Мин дә уятмадым. Хәтта командировкага киткәндә дә. Күңеле кушканда гына озатып калды. Укыганда тулай торакта яшәдек, армиядә булдык – мөстәкыйльлек бездә җитәрлек. Ашарга әзерләүнең кыенлыгын күрмим. Тик бер нәрсә бар: хатын өйдә булганда мин аш-суга тотынмыйм. Ул бит балалар бакчасында тәрбияче булып эшләде – сменалы эштә, шуңа күрә, кайчан кайтсам да, өйдә пешкән ризык булды. Ашарга пешмәгән дип гауга чыгарган гаиләләрне беләм мин. Аш куерган дип тавыш чыгаручылар да бар. Югыйсә ир соңарып кайтканга куерган ул... Җәмәгатемә әйтәм, хатын-кызларга җәннәт хәзер, дим. Суыткыч ризык белән тулы, плитә янында сәгатьләр буе кайнашмасаң да, теләсә кайсы ир-атны ашау белән «алдап» була.

12 **Сер түгел, берәр җиргә җыена башласак, без, хатын-кызлар, соңга калучан... Бу хәл белән ничек көрәшәсез?**

– Иң авырткан җирләремнең берсе бу... Хатын-кызның мәшәкате җитәрлек икәнен күңел белән аңлыйм, әмма каядыр барасы булганда алданрак әзерләнә башласаң да ярый бит. Мин гаиләмне өйрәттем: фәлән сәгатьтә китәбез дип әйтәм икән, алар шул вакытка әзер булырга тиеш. Сәгате җиткәч, машинага чыгып утырам. Тагын биш минут көтә алам... Без бит гомер буе сәгатькә карап эшләгән кешеләр. Озак еллар район башлыгының социаль мәсьәләләр буенча урынбасары вазыйфасын башкардым. Үзем дә төгәл булырга тырыштым, башкалардан да шуны таләп иттем.

13 **Хатын-кызлар еш кына... бүләк сайлауда ялгыша: ир-атка ошамастай бүләк бирә...**

– Бер елны бергә эшләгән хезмәттәше белән санаторийга барды Минҗиһан. Минем яшел күлмәк киясе килгәнне белә иде ул, кибетләрдә йөргәндә шундый күлмәк очраткан, алган. Тик ул миңа зур булып чыкты. «Син нәрсә, санаторийдагы йөрешеңнең күлмәген алып кайттыңмы?» – дип көлдем. «Үзеңнән башка сиңа бүтән кием алмыйм», – диде хатыным шуннан соң. Миңа бүләк сайлаганда, ул гел балалар белән киңәшләшә. Ә өс киемнәрен без хәзер гел икәү алабыз: аңа да, миңа да. Еш димим, әмма җәмәгатемә чәчәк бүләк иткәлим. Өйләнешкән көнебездә, балаларның туган көннәрендә. Ул бервакытта да хисләрен тышка чыгармый: «Ярар, куй, әйбәт булган», – ди. Баштагы мәлләрдә моңа кәефем төшә иде. Аннан берничә тапкыр: «Кайдан бу чәчәкләр?» – дип сораучыларга, горурланып: «Рушат алып кайтты!» – дигәнен ишеттем. Минем өйдә икәнне белмичә әйтте. Алдымда егылып төшмәсә дә, аны шатландырганымны шуннан аңладым.

Ә теге яшел күлмәкне бер дустымның туган көненә алып бардык. Озакламый исә кибеттә нәкъ шундый күлмәкне янә очраттык. Миңа яраклы үлчәме дә булды. Бик яратып кидем!



Тулысынча сайтыбыздан укыгыз: www.syuyumbike.ru

PRESSA.RU

ЭЧКЕ КИЕМ КЕМНЕКЕ?

Көз – елның үзенчәлекле матур фасылы. Кышка әзерләнүче табигатьтә балкыган җете төсләр күз явын алып кына уйнакламый, алар әле китәргә өлгермәгән җәй халәте булып җанны иркәли. Шулай да кышкы суыкларга инде әзерләнә башлыйбыз, яраткан җәйге күлмәк-сарафаннарыбызны ераккарак алып куябыз. Тыгыз-кысан колготкиларны алып кияр чак җитә. Нишлисең бит, шунсыз булмый. Җылы да, уңайлы да булган эчке киемнәрдән, колготки-оеклардан йөри башларга вакыт.

Быелгы көзге-кышкы сезондагы төп юнәлеш – хатын-кыз матурлыгын тагын да калку итеп күрсәтү. Эчке кием җитештерүчеләр иң элек аларның уңайлылыгын, тукымасының табигыйлеген, киеп йөрергә җайлы булуын игътибар үзәгендә тоталар хәзер.

РЕКЛАМА

«Стильпарк» кибетләр челтәре быелгы сезонда өйдә киеп йөри торган һәм без яратып өлгергән кайбер киемнәр маркасын эксклюзив рәвештә тәкъдим итә. Өйдә кия торган киемнәрнең уңайлы һәм кер күтәрә торган булуы гына түгел, матурлыгы да мөһим шул. Ашарга пешереп, юып-җыештырып йөрүче хуҗабикә генә булып күренәсе килми, хатын-кыз матурлыгы да бөркелергә тиеш ул киемнән.

ТАРИХ

Татар милли киеменең үз тарихы бар. Өйдә, гадәттә, күлмәк-ыштаннан йөргәннәр. Гардероб үзгәреш кичереп торса да, төп үзенчәлек барыбер сакланган. Революциягә кадәр авылда яшәүчеләр эчке кием кимәгән, тәнгә күлмәк һәм ыштан гына киеп куйганнар. Оек-оекбашлар кәҗә йә сарыкның нәзек йонынннан кулдан бәйләнгән. Өй киеме гардеробта һәрчак аерым урын алып торган – аны фәкать йорт тирәсендә йөргәндә генә кигәннәр. Татарның модалы киеме, шул исәптән, ирләр һәм хатын-кызларның эчке киемнәре яңаруы XIX йөзгә карый. Татар буржуазиясе һәм богема катлавында модерн стиле революциягә кадәр популяр була.

2017 елның көзендә һәм 2018 елның кышында киемдәге төп девиз – хатын-кызларга хас җылылык, нәзакәт булсын! Хатын-кызга хас сыйфатлар контрастын саклап, ул нәфис һәм җитди дә булырга, йомшак-тыныч төсмерләр белән янәшә бераз эпатаж акцентларны да чагылдырырга тиеш.

Бу сезонда челтәр, гипюр, атлас, үтә күренмәле тукымалардан тегелгән эчке киемнәр комплекты модада. Декорлар яратучылар өчен төрледән-төрле ташлар белән бизәлгәннәре дә бар. Ләкин алар белән артык мавыкмаска кирәк. Модадагы эчке киемнәр хатын-кыз тәне белән бербөтенне тәшкил итсен. Аксыл көрән, сөт төсендәге һәм алтынсу төсмерләрдәге эчке киемнәр аеруча популяр, алар тән төсеннән артык аерылып тормый.

Күптән онытылган иске әйберләр һәрчак яңа күренә, диләр бит. Быелгы сезонда дизайнерлар безне ретро стильдәге эчке киемнәр белән шатландыра. Биле күтәртелгән трусиклар, пин-ап стилендәге бюстгалтерлар шундыйлардан. (Пин-ап – күз төшәрлек «тышлыктагы кыз» образы. Пин-ап стиленең туу тарихы 1890–1920 елларга карый. Авторы – рәссам Чарльз Дана Гибсон. Америка иллюстраторы 1880–1890 елларда, ватандашларының көндәлек тормышын патриотик, романтик һәм аеруча сатирик рәсемнәрендә тасвирлап, үз хроникасын алып бара. Шул хроника кысаларында хатын-кыз матурлыгы идеалын да тудыра. Соңрак «Гибсон кызы» дигән исем алачак бу рәсемдә тулы күкрәкле, нечкә билле, йомры янбашлы хатын-кыз сурәтләнә. Чәчләрен биек итеп артка өеп куя ул, озын итәктән, крахмалланган блузкадан йөри, көчле холкы исә иннек белән җетеләндерелгән иреннәрнең җор елмаюында чагыла.

Әлеге стильдәге киемнәр йомры гәүдәле кызларга бик килешә. Моника Белуччи фигурасын искә төшерегез. Беркем дә аны юан димәс. Мул күкрәкле, таза ботлы булу килешеп кенә тора бу талантлы актрисага, аңа хатын-кыз матурлыгы өсти.

Кызганычка каршы, күпләр, фанатларча фигура саклыйм дигән булып, үзләренең чын хатын-кыз матурлыгын югалталар. Табигатьне алдап булмый, алар шуңа да нәфис тавышлы, йомшак формалы, бәрхет тиреле, матур йөз чалымнары булган хатын-кыз, ана, гүзәл зат итеп яратылганнар. Табигать биргән матурлыгыгызны нәфис эчке киемнәр, матур да, тәнгә рәхәт тә булган колготки, оеклар белән тагын да күркәмрәк итеп күрсәтү мөмкинлеге бар бүген. Сезне бизәрдәй модалы эчке киемнәрне «Стильпарк» кибетләренең киң ассортиментыннан сайлап ала аласыз.

Безнең журнал укучылары өчен «Стильпарк» кибетләр челтәре эксклюзив мөмкинлек – теләсә кайсы товарны ташламалы бәяләрдән сатып алу мөмкинлеге бирә.

Рәмзия КАШАПОВА

СТИЛЬПАРК
белье • колготки
ПРЕДЪЯВИТЕЛЮ СКИДКА
10%*
*Скидка не суммируется со скидками, предоставляемыми по дисконтным картам и со скидками во время распродажи. Купон действителен до 30.11.2017

Милые дамы!

Сеть магазинов «СТИЛЬПАРК» предоставляет для читателей журнала «Сөембикә» эксклюзивную 10 процентную скидку на все товары.

Ждем вас по адресам в г. Казани:

- **ТРК Тандем пр-кт Ибрагимова, д. 56.**
- **ТЦ ЦУМ ул. Московская, д. 2.**

PRESSA.RU

Бу – көндәлеккә әзерләр өчен дә, кунакларны сыйлар өчен дә кулай ризык. «Сөембикә»нең бу сандагы кунаклары – җырчы пар Зинира һәм Ризат РАМАЗАНОВлар безгә корбан итеннән әнә шундый сый әзерләргә тәкъдим итә. «Күп кеше бәрән итен өнәп бетерми. Бөтнек белән лимон аңа үзгә тәм бирә. Искиткеч хуш исле булып пешә ул», – дип, үзләре генә белгән серне журнал укучылар белән дә уртаклашырга булды җырчы яшьләребез.
Аз гына үзләре белән дә танышып китик әле. «Болгар» радиосы һәм «TMTV» премияләре лауреатлары Зинира һәм Ризат Рамазановлар эстрадага «Бул үземә генә» җыры белән килеп керде дә, тиз арада халык мәхәббәтен дә казанырга өлгерде. Алар башкаруындагы «Сиреньнәр», «Үпкәләмә» җырлары күпләрегезгә инде таныштыр. Без киләсе көнне дә алар яңа җыр яздыру белән мәшгуль иделәр – татар эстрадасын сөючеләргә тиздән «Син икән ул» җырын тәкъдим итәчәкләр.



БӨТНЕКЛЕ БӘРӘН ИТЕ



Кирәк:

- Зур гына бер түтәрәм ит (кабырга яки сум ите);
- бер уч бөтнек;
- 1 лимон;
- 3 аш кашыгы чамасы зәйтүн мае (көнбагыш мае да ярый);
- 4 тырнак сарымсак;
- тәменчә тоз һәм кара борыч;
- кечкенә генә бер кисәк зәһәр борыч.

Гарнирга:

- 500 г вак яшь бәрәңге;
- 5-6 ваграк помидор;
- 3-4 данә вак суган;
- бер баш сарымсак;
- 1 данә кызыл борыч.



Эш барышы:

■ итне юып, суын саркытабыз.

■ Бөтнекнең яфракларын аралап, вак кына итеп турыйбыз яки кул белән өзгәлибез.

■ Сарымсакны пычак белән изеп, кабыгыннан арындырабыз, зәһәр борычны вак кына кисәкләргә турыйбыз. Боларның барысын да блендерга салып, бер лимонның сутын сыгабыз, үсемлек мае, тоз һәм борыч сибәбез дә, бертөсле масса булганчы ваклатабыз.

■ Бөтнекле массаны иткә ягып, ярты көн чамасы суыткычта тотабыз – маринадлыйбыз.

■ Итне алып, кашык очы белән генә бөтнекләреннән арындырабыз һәм бераз гына үсемлек мае тамызылган кайнар табада һәр ягын да кызарганчы кыздырып алабыз.

■ Бәрәңгене яхшылап юып, кабыгын әрчеми генә урталайга ярабыз. Эре бәрәңгеләрне түтәрәмләп турарга кирәк булыр. Помидор, суган, борычны да эре итеп турыйбыз. Сарымсакны чистартып, тырнакларын бөтен килеш кенә калдырабыз.

■ Яшелчәләрне иттән калган маринадка салып, яхшылап болгатабыз. Мае азрак булса, бераз гына май өстибез.

■ Итне табага салып, кырыена яшелчәләрне тезәбез һәм уртача кызулыктагы мичкә тыгып, йомшарганчы пешерәбез. Якынча сәгатьтән артык вакыт кирәк була.

■ Тәлинкә төбенә салат яфраклары, укроп, рәйхан, петрушка, суган кыягы түшәп, итне һәм яшелчәләрне тезәбез. Кунакларга дигән итне табында килеш турасаң әйбәтрәк.



PRESSA.RU

Бомбон техникасы белән тегелгән бу «бүртмәч» одеялны тегүе артык катлаулы түгел. Бер генә кыен ягы бар – вакытны күп ала, чөнки вак детальләрдән тора. Аның каруы, башкарып чыккач, күңелгә – никадәр сөенеч, йокы бүлмәсенә – ямь, тәнгә җылылык бирәчәк бит. Одеял итәсегез килмәсә, бәләкәчегезнең бәллүенә – борт, идәнгә – палас, урындыкларга көрпә сыйфатында тегә аласыз.





Мастер-классны Камилә ДИМӨХӘММӘТОВА үткәрә.






ЮРГАНЫМ – БОМБОН

Кирәк:

• өч төрле төстән һәм төрле бизәкле киҗе-мамык тукыма (ситсы, бәз). Безнең очракта – зәңгәрсу төстәге бизәксез тукыма 2 м;
• бөрчекле тукыма – 1 м;
• шакмаклы тукыма – 1 м;
• аксыл төсле тукыма – 2,40 м;
• аслык өчен тукыма (ничә метр кирәген одеялны теккәч исәплибез);
• синтепон (гадәти мамык ярамый, югач, төерләнерлек булмаска тиеш);
• тукыма төсенә туры килә торган тегү җепләре;
• чукмарбашлы энәләр, кайчы, карандаш, линейка.





Мөһим:

Тукыма үлчәме нәкъ без теккән бизәк өчен исәпләнгән. Башка төрле бизәк белән тегәргә уйласагыз, схемасын алдан сызып, күпме тукыма китәсен исәпләргә туры киләчәк).

■ Аннары тагын бер мөһим әйберне истән чыгармаска кирәк: югач, табигый тукымалар шактый нык керешә. Шуңа да, эшкә керешкәнче, тукыманы юып, киптерсәң яхшы.



Эш барышы:

■ зәңгәрсу, бөрчекле һәм шакмаклы тукымаларны иңе белән буе 20 см булган шакмакларга кисәбез. Зәңгәрсу төсле – 70 шакмак, бөрчекле белән шакмаклы тукымадан киселгәне 35 әр булырга тиеш.

■ Аксыл төсле тукыманы исә иңе-буе 15 см булган шакмакларга кисеп чыгабыз. Андый шакмаклар 140 данә килеп чыгарга тиеш.

■ Аксыл тукымадан киселгән бу шакмакларның кыл уртасыннан диагональ буенча кисем ясыйбыз *(рәсемдә)*. Ул безгә синтепон тутыру өчен кирәк.

■ Һәрбер зур шакмакны чукмарбашлы энәләр ярдәмендә кечкенә шакмакка беркетәбез. Тукыманың уң ягы өстә булсын.

■ Төсле тукымадан киселгән шакмаклар зуррак. Шуңа күрә аларның дүрт ягыннан да кара-каршы бөкләм (складка) ясыйбыз.

■ Һәрбер шакмакның дүрт читеннән дә, 2-3 мм эчкәрәк кереп, машина белән җөй салып чыгабыз.

■ Шакмакларны тегеп бетергәч, аларны схема буенча тезеп, бер-берсенә чукмарбашлы энәләр белән беркетеп торабыз.

■ Башта шакмакларны тасмага тегеп тоташтырабыз *(рәсемдә)*. Аннары тасмалар бер-берсенә тегелә. Одеялның иңе – 1,20 см, буе – 1,70 см.

■ Шакмакларны тоташтырганда, бизәккә игътибар итегез. Бөртөсле шакмаклар диагональ буенча урнаша.

■ Һәр шакмакның эченә синтепон тутырып, ачык калган кисемнәрне кулдан тегеп куябыз. Синтепон урынына синтепух, холлофайбер да ярый. Тыгызлыгын үзегез чамалагыз, каты да, артык буш та булмасын.

■ Одеялны тигезләп җәеп, иңен һәм буен исәплибез. Аслык тукыма шушы үлчәмнәр белән киселә. Одеял белән аслыкны бер-берсенә уң ягы белән каратып салып, дүрт читеннән дә машина белән җөй салабыз, әмма 20 см араны текми калдырабыз. Одеялны уң ягына әйләндергәч, аны кул белән генә тегеп куябыз.

PRESSA.RU

Дәваланырга яратабыз да соң инде! Чүт кенә берәр җиребез чәнчеп алдымы, дару кабарга ашыгабыз. «Дару» сүзенең грекчасы «агу» дигән сүз икәнен бик сирәк кеше генә белә. Теләсә кайсы даруга кушып бирелгән инструкция кәгазен игътибар белән укып чыксаң, күп кенә даруларның безгә ярамаган хикмәте барлыгы ачыкланыр.



Фото интернеттан алынды

БАВЫРЫҢНЫ САКЛА!

Организмны пычраткан нәрсәләрдән, даруларның калдыкларыннан чистарту эше белән бавырыбыз мәшгуль. Без даруларны күбрәк эчкән, дозаларны сакламаган саен организмга килгән зыян да зуррак. Дөньяда меңнән артык дару препаратының бавырга зыян салуы мәгълүм. Даруларны күп эчүдән организмга салына торган зыянның ун проценты аңа туры килә.

Бавыр өчен иң зарарлы дару – «Парацетамол». Бавырга зыян салучы дарулар рәтендә икенче урында ялкынсынуга каршы стероидлы булмаган дарулар тора. Аларны артритлар вакытындагы авыртуларны басу өчен кулланалар. Артрит ише чирләр хроник чирләрдән саналганга күрә, дарулар да озак вакыт эчелә.

Өченче урында – антибиотиклар. Шулай ук туберкулезга, яман шешкә каршы дарулар да агулы.

Бу гына түгел әле. Фитотерапия, хәтта кайбер витаминнар да бавырга авырлык китерә. Даруларны чамалап кына эчәргә кирәклеген беркадәр аңлау бар барын. Тик шулай да төрле үләннәрне, катнашмаларны халык файдалы гына дип белә. Иң элек авырлыкны киметү өчен эчелә торган препаратлар турында сүз бара. Хәтта аерым төр витаминнар да бавырга зыян сала ала. Мәсәлән, А һәм Е витаминнары кушылмасы тән тиресен матурлау өчен еш тәкъдим ителә. Әмма Е витамины А витаминының агулы тәэсирен көчәйтә.

Себерне яуларга барган беренче кешеләр бавырлары эшләмәүдән үлә торган булганнар. Чөнки алар шушы витаминнарга гаять бай ак аю бавыры белән сыйланырга яратканнар.

Әлбәттә, мондый тайпылышлар гел булып тормый. Алай да, кай тарафтан куркыныч янаганын белеп тору мөһим.

Дарудан зарар килгәнлеге биш көннән, ә кайвакыт берничә айдан соң гына ачыкланырга мөмкин. Шуңа күрә тәҗрибәле табиб хроник авыруларының бавыры ни хәлдә икәнлегең игътибарлап торырга тиеш. Иң дөрес юл – вакыт-вакыт «бавыр пробалары» алу.

Күп очракта дарулар зыянлы түгел. Тик шулай да әледән-әле бавырны тикшертеп торырга кирәк. Бавыр зарарлануын ALT ферментының артуы хәбәр итә. Кирәк дип тапкан очракта табиб УЗИ яки фибросканирование билгели.

Иң мөһим киңәш: үз белдегегез белән дәваланмагыз, иң гади даруларны да тиктомалдан гына капмагыз. Бавырның өч төп дошманы бар: алкоголь, чамасыз дару эчү, майлы ризык ашау. Шул дошманнарны гына җиңә алабыз бит инде.

Бавырның дошманнарын гына түгел, «ярдәмчеләрен» дә барлыйк.

Бетаин – бавыр күзәнәкләрен яңартучы матдә. Аны иң элек чөгендердә табалар. Ак күчәнле һәм чәчәк кәбестә, бәрәңге, кишер, суган, томат, кавын, алмада да күп.

Глюкозинолат – ферментлар синтезында катнаша, бавырга төрле агулардан арынырга ярдәм итә. Әлеге матдә әвернә чәчәклеләр семьялыгына караган яшелчәләрдә: кәбестәнең һәрбер төрендә, шпинат, кресс-салатта бар.

Монотуендырылган майлар – организмнан зарарлы холестеринны чыгара. Яшелчә-җимештән моңа аеруча арахис һәм авокадо бай. Шулай ук яхшы сыйфатлы үсемлек майлары составында да бар алар.



Кучкар. Күңелле вакыйгаларга бай ай булыр. Мәңге үзгәрмәстәй тоелган фикерләрегезне үзгәртердәй хәлләр көтелә. Активлыгыгыз, егәрегез артыр, илһам бөтереп алыр. Алай да игътибар үзәгеннән качарга тырышыгыз.



Үгезбозау. Җентекле исәпләүләр, ашыгыч карарлар, зур игътибар сорый торган эшләргә алынмый торсагыз яхшы. Киләчәк ниятләргә бераз үзгәрешләр кертергә туры килүе бар. Борчылмагыз, ул сезнең файдага булыр.



Игезәкләр. Талантыгыз ачыла, эчке егәрегез бәреп чыга торган вакыт. Моны үзегез дә тоярсыз. Зур эшләргә курыкмыйча алына аласыз, тормышның теләсә кайсы өлкәсендә уңыш елмаерга тора.



Кысла. Язмыш сезгә күңелле сюрприз әзерли. Тормышыгызның сөенечләргә никадәр бай булуына үзегез дә аптырарсыз хәтта. Күңел капкаларыгызны яңалыкларга, үзгәрешләргә киң итеп ачып куегыз.



Арыслан. Ачык ишекләр ае. Нинди генә мәсьәләне хәл итәргә алынсагыз да, киртәләрсез, артык матавыксыз башкарып чыгарсыз. Әйтерсең, язмыш сезгә барысын да алтын табакка салып, алдыгызга китереп куя, кулыгызны сузып алыгыз гына.



Сөмбелә. Күңелегезгә шатлык өсти һәм рухи дөньягызны баета торган кеше белән танышырсыз. Көндәлек тормышыгызга җете буяулар өстәлер, бәхет хисе керер. Хисләр ташкынына буйсынып, уйламаган карарлар кабул итүдән сакланыгыз.



Бизмән. Үз дигәнегездә нык торуыгыз күптәнге хыялыгызны тормышка ашырырга ярдәм итәр. Уңышка тиз ирешим дисәгез, кеше фикеренә колак салмаска кирәк. Сүзегезне бирмәвегез башкаларның ачуын китерсә дә, сезгә булган ихтирамны арттырачак.



Чаян. Яңа белем, мәгълүмат үзләштерү, яңа дуслар табу өчен кулай вакыт. Өстәвенә, яңа белемнең бик тиздән кирәге дә чыгуы ихтимал. Тормышыгызга яңалык кертергә телисез икән, курыкмыйча тотыныгыз – нәкъ вакыты.



Укчы. Сезгә бераз күрәзәче һәм бик игътибарлы булырга кирәк. Тирәгездә тормышыгызны үзгәртердәй вакыйгалар бара, алардан үзегезгә файда алып калырга тырышыгыз. Ашыгыч нәтиҗәләр ясаудан, вакыйгаларны ашыктырудан сакланыгыз.



Кәҗәмөгез. Үзегез өчен нәрсәнең мөһимрәк булуын ачыкларга туры килер. Тормышыгыздагы иң зур максатны тагын бер кат барлап, аңа ирешү юлларын эзләү белән мәшгуль булырсыз.



Сукояр. Финанс мәсьәләсендә тотрыклылык көтелә. Ниһаять, хыялыгыздагы әйберне сатып алу мөмкинлеге килеп чыгар. Өстәмә керем чыганагы булдыру ихтималы зур. Кулыгызга уйламаган җирдән акча килеп керер.



Балык. Эшегез күп, әмма кәефегез яхшы булыр. Нәрсәгә генә алынсагыз да, уңышлы башкарып чыгарсыз. Вәгъдәләр бирүдән сакланыгыз, башкаларның мәсьәләләре белән йөрергә вакытыгыз җитмәс.

Чит илләр сентябрь дә кабынган йолдызлар

Татарстан



Илсөя Төхфәтуллина (10.09.1967) – **Татарстанның халык артисты.**

Татарстанның Апас районы Дәвеш авылында туып-үсә. Әтисе – бик оста гармунчы булса, әнисе бик матур итеп өздереп җырлый. Унынчыны тәмамлагач, апасы Мәскәүдәге театр училищесына татар студентларын җыюларын ишетеп, сеңлесен шунда барырга үгетли. Талантлы һәм чибәр кызны Марсель Сәлимҗанов Казанда калдырырга тели, хәтта К. Тинчуринның «Зәңгәр шәл» спектаклендә Мәйсәрә ролен вәгъдә итә. Мәйсәрәне барыбер уйный ул, 1988 елда – Мәскәүдән кайтуга ук аны Камал театрына эшкә алалар, һәм иң беренче роле дә Мәйсәрә була. М. Фәйзинең «Галиябану»ында – Галиябану (2015 елда Илгиз Зәйни куелышындагы спектакльдә инде аның әнисен уйный), Н. Исәнбәтнең «Хуҗа Насретдин»ендә – Зөбәрҗәт, М. Гыйләҗевнең «Казан егетләре»ндә – Фәүзия... болар ул уйнаган рольләрнең берничәсе генә.

Россия



Ольга Остроумова (21.09.1947) – **Россиянең халык артисты, СССР дәүләт премиясе лауреаты.**

Оренбург өлкәсенең Богырыслан шәһәрендә туа. Бабасы – рухани, әтисе физика укытучысы була. Кызларының артист булам дигәненә алар бик гадәти карый, кесәсенә – билет, сумкасына ризык салып, берүзен туганнары да, дуслары да булмаган Мәскәүгә чыгарып җибәрәләр. Шулай да Ольга үз дигәненә ирешә – 1966 елда ГИТИСка укырга керә. Институтны тәмамлап, 1970 елдан Мәскәү яшь тамашачы театрында, үзенең укытучысы – режиссер Павел Хомский белән эшли башлый. Миллионлаган тамашачыга аны «Доживем до понедельника» фильмында башкарган роле таныта. Ә зур уңыш китергән икенче роле – «А зори здесь тихие» фильмындагы Женя Комелькова була.

Чит илләр



Кристен Джонстон (20.09.1967) – **актриса, ике тапкыр «Эмми» премиясе лауреаты.**

Вашингтонда туа. Мәктәптән соң Нью-Йорк университетында драматик сәнгать белгечлегенә укый. Актерлык карьерасын Нью-Йорктагы офф-бродвей театрлары (кечкенә театрларны шулай атыйлар) сәхнәсендә башлый. 1996 елда аны «Третья планета от Солнца» фильмында төп рольне уйнарга чакыралар. Фильм бик уңышлы килеп чыга. Шушы роле өчен ике мәртәбә «Эмми» премиясенә лаек була. «Секс в большом городе», «Скорая помощь» фильмнарында уйнаган рольләре исә дөньякүләм танылу алып килә.

PRESSA.RU





«СӨЕМБИКӘ», «ФӘРИДӘ», «МӘРЬЯМ»...


Чүлмәк дип кенә гомумиләштерергә ашыкмыйк әле – аларның һәркайсының үз исеме бар, һәм рәссам үзенең «Энҗе», «Нурсолтан», «Мәрьям», «Сөембикә», «Фәридә»ләренең һәркайсын «йөзеннән», килеш-килбәтеннән әллә каян танып тора. Инде шулкадәресе мәгълүм булгач, син үзең дә аларга башкача карый башлыйсың, һәрберсенең аның үзенә генә хас чалымнарын табарга тырышасың. Күр инде син аларны: берсеннән-берсе көяз, берсеннән-берсе сылу, нәзакәтле, затлылар! Элек-электән юкка гына чүлмәк савытларны хатын-кызның буй-сыны белән чагыштырмаганнар шул инде. Ә менә Татарстан һәм Россия Рәссамнар берлеге әгъзасы, Бакый Урманче премиясе лауреаты Зөфәр Сәит улы НИЗАМЕТДИНОВның савытлары җисеменең кулга ук ятып торуы белән бер отса, төсләренең тыйнак булуын, бизәкләренең җылылыгын, миллилеген дә инкяр итеп булмый.

90 нчы елларда аңа: «Бу бит шәрык!» – дип кабатларга яратсалар да, ул әлегәчә: «Бу – без! Бу – безнеңчә!» «Безгә инде күптән үзебезнең академик мәктәпне булдырырга кирәк. Юкса сәнгать мәктәпләрендә безгә әлегәчә көнбатыш Европа мәдәниятен өйрәтәләр. Без үз мәдәниятебезне укытырга, шуны өйрәтергә тиешбез», – дип тәкрарлый.

Болгарга елына бишәр, алтышар тапкыр баруының да үзенә күрә хикмәте бар. Юк, бу аның нидер эшләргә дип, этюдниклар асып юлга кузгалуы түгел, җан азыгы эзләп, күңеленә нидер сеңдереп кайту өчен баруы. Әгәр дә без останың керамик эшләнмәләрендә борынгы Болгар чүлмәкчеләренең гасырлар аша иңгән аһәңен тойгандай булабыз икән, бу, һичшиксез, әнә шул сәфәрләрнең кайтавазы булуы бик мөмкин.


Моннан күпмедер еллар элек Эстониянең Пярну шәһәрендә узган шәхси күргәзмәсендә аның нәкъ менә шушы чүлмәкләрен, керамик эшләнмәләрен күреп, хәтта калырга да димлиләр. Хуҗаларның ымсындыргыч тәкъдимнәре дә калдыра алмый аны чит җирләрдә. Чөнки җирсеп яшәүнең ни икәне – канында. Свердловскидан (Екатеринбург) ерак түгел Серов шәһәрендә туып-үскән, Түбән Тагил педагогика институтының художество-графика бүлекчәсен тәмамлаган оста Татарстанга да юкка гына кайтмый бит инде. «Учительская газета»да (1988 ел) Алабуга педагогика институтының сәнгать графика бүлегендә эш урыны булу турында язып чыгулары бөтен күңелен кузгата. Вәгъдә ителгән фатирдан битәр, 20 нче елларда репрессияләнеп сөргенгә сөрелгән бабасының туган ягына кайту теләге урыныннан кубара рәссамны. Кем әйтмешли, бу җирләргә җан да, кан да тарта милли тәрбия алып үскән Зөфәрне. Һәм менә бүген үз илемдә – үз көнем дип яшәве. Эшләренең Татарстанның «Иң яхшы товар»ы дип бәяләнгән чаклары да булмады түгел. Авиатөзелеш районының «Яшьлек» мәдәният йортында керамика дәресләре алып баручы остазның шәкертләре дә шактый хәзер. Башкарасы эшләре бихисап. Берсен дә үги итәсе килми үзенең: барысына да кулы да, күңеле дә җитә. Ара-тирә булса да, портретлар эшләргә дә, чүлмәкләргә тәмләп бизәкләр төшерергә дә, җиң сызганып, кызыл балчыкка тотынырга да җае табылып тора.

Расиха ФАИЗОВА









ЗӨФӘР НИЗАМЕТДИНОВ

PRESSA.RU

ПОЧТА РОССИИ

Подписные издания

Официальный каталог Почты России

Первое полугодие 2017

ИГЪТИБАР!

«Почта России»ның «Подписные издания» (ПАП) рәсми каталогы буенча ЖУРНАЛЫБЫЗНЫҢ ЯҢА ИНДЕКСЫ П2204



5–15 октябрь көннәрендә «Почта России»ның барлык почта бүлекләрендә «Абунәче декадасы» узачак. Ташламалар булганда, журналыбызга язылып калырга ашыгыгыз.

Өлкәннәр көненә бүләк эзләгәндә «Сөембикә»не сайлагыз!



Татарстаннан читтә яшәүчеләр «Роспечать» каталогындагы элеккеге индекс буенча языла алалар: 73002

Журналыбызга онлайн режимда : http://podpiska.pochta.ru сайтында (регистрация узып) яки безнең сайтыбызның онлайн язылу бүлегендә дә язылырга мөмкин



Электрон версиягә язылган очракта, яңа санны компьютерда, планшетларда, барлык мобиль җайланмаларда PDF форматта укырга була. **iPad** һәм **iPhone** кулланучылар «Сөембикә» журналының электрон версиясен App Storeдагы «Pressa.ru» киоскына кереп, хатын-кызлар өчен журналлар арасыннан таба ала.

Электрон версиягә язылу турында тулырак мәгълүматны «Сөембикә» журналының сайтында «Язылу» бүлегендә табып була (**www.syuyumbike.ru**).

16+